КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни җомга

№ 9
15 сентябрь
1995 ел

1913 елның июленнән башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы

БҮГЕНГЕ САНДА:

2 *Газинур МОРАТ.*

Без бүген төрмә законнары хакимлек иткән дәүләттә яшибез. Криминаль дәүләтнең башында да, кагыйдә буларак, криминаль хакимнәр утыра.

5 *Фоат ГАЛИМУЛЛИН.*

Аның гаиләсе язучылардан гына тора: үзе, хатыны, улы, кызы һәм кияве.

10 *Әхтәм ЗАРИПОВ.*

Безнең власть хыялдагы каһарманнар өстеннән хакимлек итүдән башкага ярамый.

12 *Габбас МӨХӘММӘТШИН.*

Татар милләтенең ачы һәм гыйбрәтле тарихын гәүдәләндергән алтын айлы Сөембикә манарасы һәркайсыбызга якын, кадерле.

18 *Тәүфикъ ӘЙДИ.*

Төркия архивларында халкыбызның тарихын дөрес яктырткан бик күп документлар саклана.

20 *Гомәр САТТАРОВ-МУЛИЛЛЕ.*

Исемеңнән, җисемеңнән нур-ядкарь калдыр син дөньяга.

Гомерләрнең алтын туенда да
Насыйп итсен бергә булырга...

МӘДӘНИ ҖОМГА

МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

Казан ханлыгы җимерелгәндә шәһит киткәннәрне инде ничә еллар рәсми булмаган шартларда искә алабыз. Элгәрләренең варисы саналган безнең бүгенге дәүләтебез дәүләтчелек сагында үлгәннәрнең истәлегенә ни өчен битараф? Үзен-үзе хөрмәт иткән халыкларда мондый гафиллеккә юл куелмый.

Мөхтәрәм депутатлар, халык хадимнәре! Хәтер көнен канунлаштыру мәсьәләсенә кире кайтып, бинаһая корбаннар рухы алдында йөзебезне пакьлыйк әле.

Мансуров / **Зиннур МАНСУРОВ** /

МИН ӘЙТТЕМ

Газинур МОРАТ

Җәяүле кошлар



Көзләр җитсә, авылларда казлар оча башлый. Йорт казлары... Без малай чагында чана, чаңгы шуып үскән чирәмле тау (!) башына авырайган гәүдәләрен алпан-тилпән сөйрәп менәләр дә, бераз чемченеп хәл җыйгач, оялары белән дәррәү кубып, йөгерә-чаба талпынырга тотыналар. Менә, ниһаять, авыл өстендә таранга барган истребитель-камикадзелар сыман казлар өере пәйда була. Ихтимал, бу – казларның иң бәхетле мизгелләредер. Алар да канатлылар кавеменнән ич. Тәңребез аларны да кайчандыр очар кошлар итеп яраткандыр лабаса... Ләкин казларга күктә озак юанырга туры килми, берничә йөз метр очуга, алар кайсы кая мәтәлеп тә төшәләр. Кайвакыт араларында оядан аерылып калып адашкан-югалганнары, имгәнгәннәре дә була. Шуңа күрә авыл кешесе аларның болай «чыгырдан чыгып» йөрүләрен өнәп бетерми, кайберәүләр үз казларының канат очларын да кисәли. Болары инде иң бәхетсез мәхлуклар. Болары очыш дигән бөек ләззәтне кичереп карамыйча да дөньядан китеп баручылар... «Кошларда да – кеше язмышлары», – дип язган шагыйрь бу очракта да хаклыдыр, мөгаен. Әйе, кулга ияләштерелгән кошлар кешенең үзенә охшап кала. Адәм баласы да төшендә ара-тирә үзенең күктә очып йөргәнен күрә ич. Әллә без дә кайчандыр кулга ияләштерелгән, канат очлары киселгән кошлар кавеменнән микән?

Кыр казлары артыннан
Очарга дип талпынам.
Тик очалмыйм, карап калам
Кыр казлары артыннан.

Белмим, шагыйрь әлеге юлларны язган чакта йорт казларының геннарында сакланып калган, күккә әйдәгән зәгыйфь сигналлар турында уйлагандырмы-юктырмы, әмма ул безләрнең бүгенге рухи халәтен шактый төгәл тасвирлаган. Безләр дигәнем – ике башлы сәмруг кошның канат астыннан үрмәләп чыгып очарга азапланган җәяүле кошлар була инде.

Дөрес, заманында бөтен дөньяны дер калтыратып торган сәмруг кош бүген үзе дә хәл эчендә. Аның томшыкларыннан да, канат очларыннан да кан тама. Кан исеннән исерешкән ике баш, мәхәллә бүлешә алмаган әтәчләр шикелле, үзара сугыша. 1991 елның август, 1993 елның октябрь фетнәләрендә шулай булды. Ике башның үзара кан коешы дәвам итә. Хәзер ул Кавказда, вайнахлар илендә бара. Анда бөтен дөньяның күз алдында Кремль «демократлары» тарафыннан XX гасырдагы иң зур җинаятьләрнең берсе кылынды. Каф таулары арасына сарыклар көтүе кебек куып кертелгән солдатлар, көтүче булырга да яраксыз илбашларының хәмер исе аңкып торган әмерен үтәп, тыныч кына яшәп яткан шәһәр-авылларны тупка тота-тота, ниндидер «конституцион тәртипләр» урнаштырып йөрде. Шулай итеп, Русиядә шоу-маскарадлар чоры узды. Ниһаять, чырайлардан битлекләр алып ташланды. Хәер, аның шулай булуы хәерлерәк тә. Бер акыллысы әйтмешли, халык үз каһарманнарының кем икәнлеген чырайларыннан танып белергә тиеш ләбаса!

Русиянең тарихыннан да, бүгенгесеннән дә кан исе, көек исе килә. Империянең агония сәгате якынлашкан саен, күңелне отыры курку хисе били бара. Бүген Ичкерия илендә кылынган коточкыч җинаятьләр турында уйлыйсың да үзеңне, ирексездән, бинаһая сугым сараенда яшәгән кебек хис итә башлыйсың. Ә сугымчыга вайнахың ни дә, татарың, башкортың ни – аңа тере чимал булсын да, кем әйтмешли, сәмәне килеп торсын.

Бүген Ичкериядә 1552 ел кабатлана. Анда да тулы бер халыкны кырып бетерү, җир йөзеннән юк итү сәясәте алып барыла. Ни аяныч, чәчәннәрнең дә үз Шаһгалиләре, үз Камай морзалары бар. Алар бүген империянең марионеткалар театрында шамакай ролен башкара. Ләкин шулай да чәчәннәр, безнең бабайлардан аермалы буларак, үзләренең бик күпкә бердәмрәк икәнлекләрен күрсәттеләр. Ихтимал, дөнья илләре иртәме-соңмы Ичкериянең бәйсезлеген танырга да мәҗбүр булыр. Тик шунысы гаҗәп: ни өчен соң әле бәйсезлек шулкадәр зур югалтулар бәрабәренә яуланырга тиеш?! Ни өчен соң әле дөньяның иң демократик илләре дә кайсыдыр дәүләтнең бәйсезлеген таныганчы, башта анда кан коелуын, шәһәр-авылларның хәрабә хәленә килүен көтеп-күзәтеп тора? Әллә бәйсезлек хакына кан кою БМО карарларында мәҗбүри шарт итеп куелганмы?

Урыс армиясе Ичкериягә басып кергәч тә, Гарәп илләренең бериш җитәкчеләре, бу – Русиянең эчке эше, без чит дәүләтнең эчке эшләренә тыкшынмыйбыз, дип белдерделәр. Ә менә бер ата кешенең башка чыгарга теләгән улын үтергәнче кыйнавын читтән көлеп күзәтеп тору әхлак кануннарына сыешыр иде микән? Юк, сыешмас иде. Хәер, ата – улны, ана кызны белми башлаган бер заманда әхлак турында нинди сүз булырга мөмкин?! Кемгә хаҗәт ул синең әхлагың? Үз халкына каршы геноцид сәясәте алып баручы илбашларгамы? Тыныч халыкны бомбага тотарга әмер биргән генералларгамы, әллә мөнбәрләрдән халык бәхете турында зур сүзләр сөйләп тә, гамәлдә үз кәнәфие өчен җан калтырап торучы, үз кесәсен генә кайгыртучы эреле-ваклы түрә-караларгамы? Элекке Союзда башланып киткән «бөек криминаль инкыйлаб» (С.Говорухин билгеләмәсе) җәмгыятьне шул хәлгә илтеп җиткерде ки, бүген әхлаклы булу үзе әхлаксызлыкка әйләнеп бара. Һәртөрле идарә структураларына криминаль элементлар үтеп керде һәм алар үзләрен теләсә кайда паханнарча тота башлады. Һәм, әлбәттә, паханнар тирәсендә койрык болгап йөрүчеләр дә табылды. Болары – паханның һәр әмерен карусыз үтәп, аңа тастымал тотып торучылар. Ни гаҗәп, Русиядә тормыш дәрәҗәсе көннән-көн начарая, җитештерү көннән-көн кими, ә шул вакытта халыкның мәгълүм бер катлавы отыры байый, ниндидер юллар белән табылган байлыкны үз хисабына күчерә бара. Асылда без бүген төрмә законнары хакимлек иткән дәүләттә яшибез. Билгеле, бу дәүләт кичә генә барлыкка килмәде. Аның нигез ташлары моннан күп гасырлар элгәре, ушкуйниклар заманында ук салына башлаган.

XIY гасырда Идел буйлап йөзүче сәүдә корабларын һәм Төньяк җирләрен талау өчен оештырылган юлбасарлар өере тора-бара илбасарлар дәүләтенә берләшкән. Кыскасы, Русия карында чакта ук криминаль дәүләт буларак формалашкан. Югыйсә, соңгы вакытта Русиянең бөтен бәхетсезлеген Лениннан, Сталин, Горбачев, Ельциннан күрә башладылар. Бәхетсезлекнең башын ерак тарихтан эзләргә кирәк. Криминаль дәүләтнең башында да, кагыйдә буларак, криминаль хакимнәр утыра.

Ихтимал, 1991 елгы сайлаулар вакытында халык Русия җитәкчеләре соңыннан бу кадәр үк җинаятьләр кылыр дип башына да китермәгәндер. Ул чагында Ельцин совет гаскәрләренең Балтыйк буе дәүләтләренә каршы агрессиясен гаепләп чыкты. Сахаровның җәсәде өстендә демократия турында ләчтит сатып лаф оручы да ул булды. ГКЧП көннәрендә үтә дә саксызлык аркасында гына һәлак булган өч егетнең гомерен саклап кала алмаганы өчен Русия халкыннан гафу үтенергә дә онытмады Президент. Безнең ише йокылы-уяулы автономияләргә дә җылы сүзен кызганып тормады ул: «Суверенитетны йота алган кадәр алыгыз», – дип җөмһүриятебез җитәкчеләренең башларыннан сыйпады да, татар түбәтәен киеп, кире Мәскәвенә кайтып китте. Аның канатлы булып киткән әлеге сүзләрен кайберәүләр чынга алып, үзләренең шактый ук аппетитлы икәнлекләрен дә күрсәтә башладылар. Бигрәк тә генерал Җәүһәр Дудайның талканы коры булып чыкты: ул, ике башлы сәмруг кошның канат астыннан үрмәләп чыгып, үзе дә биек кыяларның башында яшәүче бөркеткә әверелергә теләде. Әгәр дә дөнья илләре Ичкериянең бәйсезлеген шул чагында ук таныган булса, кем белә, бүген Кавказда мондый ук вәхшилек кылынмас та иде, бәлки.

Хәер, ул заманнарда безнең Татарстан да кайнап торган казанны хәтерләтә иде. Без дә, кыюланып китеп, «Русия белән ассоциацияләшкән дәүләт»кә, «халыкара хокук субъекты»на әйләнеп куйдык. Эшләр шуңа барып җитте ки, хәтта Русия Президенты Татарстанда вәкаләтсез үк булып чыкты (нәкъ Ичкериядәге кебек). Ләкин, кызганычка, Мәскәү белән Казан арасында төзелгән мәгълүм шартнамәдә боларның берсе дә теркәлмәде. Алай гына да түгел, Татарстан үзе өчен кабалалы килешүгә кул куярга мәҗбүр булды. Кайбер мәгълүматлар буенча, гамәлдәге шартнамәне вице-премьер С.Шахрай белән экс-вице-президент В.Лихачев эшләгән, диләр. Ә без инде Шахрайның милли мәсьәләләр өлкәсендә нинди «зур белгеч» икәнлеген яхшы беләбез. Яшь кенә килеш империя тәхете тирәсенә менеп оялаган бу каракош токымы бүген Русияне кабат губерналарга бүләргә тәкъдим итә. Шулай ук Ичкериягә гаскәр кертүне оештыручыларның да берсе ул иде, диләр. Шушы ук кеше соңыннан, чәчән сугышы башлангач, ни гаҗәп, Татарстанны мактап сөйләргә тотынды. Янәсе, Татарстан җитәкчеләре, вакытында акылга килеп, дөрес юл сайлады; янәсе, Чечняга да шундый ук шартнамә төзеп, Мәскәү ихтыярына буйсынырга кирәк иде һ.б. һ.б. Кяшки, агай-эне, бөтен халыклар да безнең татар кебек «бәйнәлмиләл», күндәм, буйсынучан түгел шул. Дөрес, Казан белән Мәскәү арасында шартнамәгә кул куелганчы, Татарстанга да гаскәр кертү куркынычы булуы турында соңыннан матбугатта ара-тирә хәбәрләр ишетелгәләде аның. Мәскәүгә ышаныч юк, билгеле, аның бөтен тарихы агрессияләрдән, кан кою һәм җан кыюлардан тора. Инде килеп, әгәр шундый хәвеф була калган очракта да (Аллам сакласын!), безгә Ирек мәйданына бәреп кергән танкларны, кем әйтмешли, ипи-тоз белән чәк-чәк тотып каршы алудан башка чара калмас иде, мөгаен. Ни аяныч, әлегә без барыбыз да чарасызлыктан гаҗиз булып яшәргә хөкем ителгән шул. Хөкем карарын безгә 1552 елны ук укыганнар.

Дөрес, тарихта моннан озынрак гомерле карарлар да булган. Мәсәлән, «Изге Рим империясе» карамагындагы Швейцариянең урман кантоннары (легенда каһарманы Вилгельм Теллне исегезгә төшерегез) илбасарларга каршы туктаусыз җиде (!) гасыр дәвамында көрәш алып барган һәм 1499 елда империя тырнагыннан котылуга ирешкән. Ләкин, бәйсез дәүләт буларак, Швейцария 1648 елда, ягъни Вестфаль солыхы төзелгәч кенә, халыкара танылу алган.

Ә бүген исә, Татарстан туфрагыннан да бәләкәйрәк Швейцарияне оҗмахка тиңлиләр. Халыкның тормыш дәрәҗәсе буенча әлеге дәүләт дөньяда беренче урында тора. 6,5 млн. халкы дүрт дәүләт телендә аралаша һәм, ни гаҗәп, Швейцария Конфедерациясен федеральләштерү, яисә телләр белән бәйле матди чыгымнарны киметү уе берәүнең дә башына килми.

Русия (урыс халкы дип укы – Г.М.) дөнья халыкларына ничек яшәргә ярамаганлыгы турында гыйбрәт бирер өчен яралган, дигәнрәк фикер әйтеп калдырган бөек Чаадаев. Ә мин һич тә үз халкымның мондый Русиядә яшәвен теләмәс идем. Кайчандыр бәйсез дәүләт корып, очар кош хокукына ия булып яшәгән халыкка Швейцария кебек ил-дәүләтләрдән сабак-гыйбрәт алу мәгъкульрәк түгелме икән?!

Җидегән 5 6 7 1 2 3 4
вакыйгалар хәбәрләр яңалыклар

Эш хакы арта, ләкин ул бәяләрне куып җитә алмый

Атна башында Премьер-министр урынбасары Равил Моратов матбугат конференциясе үткәрде. Ул республиканың социаль-икътисади сәясәтенә багышланган иде. Июль аенда республикада уртача хезмәт хакы 234 мең сум булды, бүген яшәү өчен кирәк булган минимум хезмәт хакы 180 мең сум дип билгеләнә. Аеруча бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең матди хәле начарайды. Гыйнвар аенда аларның тормыш дәрәҗәсе 4,2 процентка төшсә, бүген ул 22,2 процент тәшкил итә.

Шушы хәлләр Татарстан хөкүмәтен хезмәт хакын, пенсияләрне күтәрү, кайбер категорияләргә компенсацияләр бирү мәсьәләсен яңадан карарга мәҗбүр итте. Чөнки алда хәлләр тагын да кыенлашачак: октябрь аенда инфляция 8-10 процентка җитәчәк, дип фараз кылына, ә бу азык-төлек һәм иң кирәкле тормыш-көнкүреш товарларына бәяләр тагын да артачак дигән сүз. Шуларны истә тотып, Татарстан хөкүмәте, промышленность предприятиеләре ассоциациясе һәм профсоюзларның каршы килүенә карамастан, бюджет оешмаларында хезмәт хакын күтәрү турында карар кабул итте.

— Сентябрь аеннан, компенсацияләрне кушып исәпләгәннән соң, — диде Р.Моратов, — беренче разрядлы хезмәткәр 200 мең сум хезмәт хакы алачак. Ә минималь хезмәт хакын 200 мең сумга җиткерү турындагы мәсьәлә Дәүләт Советының октябрь сессиясендә кузгатылачак. Бүген 105 мең сум пенсия алып, очлы-очка ялгап яшәүче пенсионерларның өстәмә түләүләр хисабына пенсияләре 210 мең сумга җитәчәк.

Р.Моратов тагын бер күңелле хәбәр әйтте: эшләүче кешенең 440 мең сумга кадәр булган кереме салымнан азат ителә.

Матбугат конференциясендә тагын шунысы да мәгълүм булды: бүгенгә кадәр икмәк өчен хөкүмәт 12 миллиард сум дотация биреп килә иде, моннан соң бу дотация булмаячак. Хөкүмәт түләве икмәкнең кайбер аерым төрләренә генә калачак. Шулай итеп, яңа оннан пешерелгән икмәкнең бәясе 3-4 тапкырга күтәрелер дип көтелә.

Кайту

Симферопольдә Татарстанның танылган фоторәссамы Рифкать Якупов әсәрләреннән Кырым татар рәссамнары берлеге күргәзмә оештырды.

Күргәзмәнең исеме «Кайту» дип атала, ягъни Кырым татарларының туган җирләренә кайтулары нәфис фото сәнгатендә тасвирлана.

Рифкать Якуповның И.Гаспралы укыткан «Зынҗырлы мәдрәсәсе», «Ханҗәми», «Үзбәк мәчете» (Иске Кырым шәһәрендә) дигән хезмәтләре сәнгать әһелләре югары бәя бирде.

Якшәмбе мәктәбендә татарча да укыячаклар

Казан консерваториясе каршында эстетика буенча якшәмбе мәктәбе яңадан эшли башлаячак. Бирегә дәресләр ике юнәлештә алып барылачак: музыка нигезләре һәм тел күнекмәләре, ягъни 5-6 яшьлек балалар музыканы, ритмны тоярга һәм татарча, инглизчә матур итеп сөйләшергә өйрәнәчәк. Дәресләрне тәҗрибәле педагоглар алып бара.

Бу уку елыннан мәктәптә педагог-психолог булып укытучыларның белемен күтәрү институтының өлкән фәнни хезмәткәре Людмила Блинова да эшли башлый. Бу өлкәдә ул — шәһәребезнең иң абруйлы белгечләреннән берсе.

Музыка һәм телләр өйрәнүдән тыш, балалар эстетика, халык авыз иҗаты, әдәбият, рәсем, бию һәм гимнастикадан да дәресләр алачак.

Укулар 17 сентябрьдә башлана.

ТАИС хезмәткәрләре киңәш-табыш итә

Чаллыда авторларның хокукларын яклау мәсьәләсенә багышланган зона киңәшмәсе булып узды. Аны Татар интеллектуаль милек агентлыгы (ТАИС) һәм Чаллы мэриясенең мәдәният идарәсе оештырды.

Киңәшмәдә Чаллы, Түбән Кама, Алабуга, Менделеевски, Минзәлә һәм Зәй шәһәрләреннән язучылар, сәнгать әһелләре, мәдәният бүлеге мөдирләре, театр һәм мәдәният сарайлары директорлары, концерт һәм иҗат төркемнәре җитәкчеләре катнашты.

Җыенда ТАИС хезмәткәрләре чыгыш ясап, очрашуда катнашучыларның күпсанлы сорауларына җавап бирде.

ТАИС хезмәткәрләре киләчәктә мондый киңәшмәләрне җөмһүриятебезнең башка төбәкләрендә дә үткәрүне күздә тота.

Милли сәнгать язмышы кем кулында?

Габдулла Тукай музеенда «Татар сәнгатен үстерүдә дәүләт һәм иҗат берләшмәләренең эшчәнлеге» дигән темага мәдәният һәм әдәбият әһелләренең фикер алышуы булды.

Анда сүз хәзерге милли сәнгатьтәге проблемалар, мәдәният өлкәсендә химаячелек һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең милли ядкярләребезне саклауда һәм өйрәнүдә тоткан роле турында барды.

Соңыннан фикер алышуда катнашучыларга һәм кунакларга «Туран» фонды үз коллекциясеннән яңа үрнәкләр күрсәтте.

Петербург татарлары ният кыла

Санкт-Петербургта татар һәм башкорт диаспораларының киңәшмәсе булды. Анда Санкт-Петербургта һәм Ленинград өлкәсендә яшәүче татарларның милли мәдәниятен, телен һәм гореф-гадәтләрен кире кайтару, үстерү программасы проекты буенча «Нур» җәмгыяте рәисе Мөдәррис Каюмов чыгыш ясады. Ул киңәшмәдә катнашучыларны татар мәдәни җәмгыятьләренең алдагы елларга билгеләнгән эш планнары белән таныштырды.

Ә киләчәккә ниятләр зурдан. Шәһәрдә дә, өлкәдә дә Шәрык һәм Көнбатыш телләрен, милли һәм мөселман мәдәниятләре нигезләрен өйрәнүне максат итеп куйган мәктәпләр ачу, милли кадрлар әзерләү көн үзәгендә тора. Шулай ук Петербург дәүләт университетының Шәрык телләре факультетында һәм Петербург педагогия университетында татар-башкорт телләре һәм әдәбиятлары бүлеген булдыру, шәһәрдә олылар өчен дә, балалар өчен дә милли театрлар оештыру киләчәккә билгеләнгән планнарның бер өлеше генә.

Киңәшмәдә шулай ук Санкт-Петербургта һәм Ленинград өлкәсендә яшәүче татар диаспорасы вәкилләре шурасын оештыру турында карар да кабул ителде. 20-25 кешелек әлеге шура төбәктәге татарларның эшчәнлеген координацияләп торачак.

Чуваш мәгърифәтчесе — Татарстан улы

1998 елның апрелендә танылган чуваш язучысы, педагогы һәм мәгърифәтчесе Иван Яковлевның тууына 150 ел тула. Алда торган юбилей уңае белән Татарстан һәм Чувашстан республикаларының Мәдәният һәм Мәгариф министрлыклары тарафыннан күп төрле чаралар үткәрү күздә тотыла.

Юбилейга әзерлек йөзеннән мәгърифәтченең туган авылы — Татарстанның Тәтеш районы Кошки авылында — Яковлев салдырган мәктәп реставрацияләнде, соңыннан монда чувашның мәшһүр улының тормыш юлы һәм эшчәнлегенә багышланган музей оешачак.

Шушы арада бирегә Татарстан Республикасының мәдәният министры М.Таҗиев, Чувашстан Республикасының мәдәният министры В.Иванов, мәгариф министры Р.Миронов, белгечләр килде. Тәтеш районының хакимият башлыгы М.Фазлыев һәм хезмәт ветераннары белән очрашу булды.

Юбилейга... «Пики дамасы»

Моннан ике ел элек Казан дәүләт консерваториясендә опера студиясе оештырылган иде. Нигаять, 15 сентябрьдә М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры бинасында студиянең беренче спектакле була. Ул — урыс композиторы П.Чайковскийның «Пики дамасы» дигән операсы. Спектакльдә унга якын төп партияне Казан дәүләт консерваториясе студентлары башкара.

Опера студиясенең җитәкчесе Гүзәл Хәйбуллинаның әйтүенә караганда, бу спектакльне консерваториянең 50 еллыгына багышлыйлар икән.

Казан консерваториясенең 50 еллыгына багышлардай бернинди татар әсәре дә юк инде алайса?!

Сырхаулар өчен кибет

Газетабызда шикәр чире белән авыручыларга Казанда махсус ипи кибете ачылуын хәбәр иткән идек.

Кибетнең адресы: Горький урамы, 17 нче йорт. Тел.: 38-45-37.

Әл-ГАДЕЛ

ТАТАР ЙӨРӘГЕ

Республикада рәис — публика*,
Халыкның рухы, янар йөрәге!
«Азатлык! Хаклык!» — шушы ике сүз
Әйтер дә бирер татар теләгеН.

Әй, суфый, миңа: «Син оныт!» — димә.
Ничек онтыйм ди бабамнар санын?!
Каберләреннән торып басырлар, —
Ни дип тотармын шунда җавабын?

Юк, түгел таныш — синә ул язмыш:
Ни кылган алар, нәрсә корганнар...
Янчелгән чаңнар, чәчелгән таҗлар,
Чәчәгән инде ул каһарманнар!

Без бит шул заттан, шуларга дәвам,
Ә дәвам һаман итә ул дәвам
Гасырлар, чорлар, дәверләр аша
Тарихның хаккый түренә табан.

«Азатлык! Хаклык!» — шушы ике сүз
Әйтер дә бирер татар йөрәген.
Килсә беләсең аның серләрен, —
Татар булып син кара әлгәре.

* Публика (латинча) — халык.

Җомгадан — җомгага

Җөмһүрият елъязмасына җөмләләр

Президент М.Шәймиев Кремльдә Австралиянең Русия Федерациясендәге Гадәттән тыш һәм вәкаләтле илчесе Җеффри Бентлины кабул итте.

Татарстан Республикасы Президенты М.Шәймиевнең Казанда Татарстан хатын-кызлар корылтае үткәрү турында фәрманы чыкты.

Премьер-министр урынбасары И.Хәйруллин республикабызга эш визиты белән килгән бертөркем Америка кардиохирургларын кабул итте.

Дәүләт Советы Рәисе В.Лихачев инициативасы белән 24 сентябрьдән башлап Татарстанда Берләшкән Милләтләр Оешмасының 50 еллыгына багышлап айлык үткәрелә.

Татарстан Премьер-министры Ф.Мөхәммәтшин Франциянең авыл хуҗалыгы проектларын эшләү фирмасы — «Сюкден керри»ның генераль директоры Мишель Гаринуаны, шулай ук чөгендерчеләрнең бөтендөнья ассоциациясе рәисе Жорж Гаринуаны, «Сюкден керри» директоры Жан Дориноны кабул итте.

Татарстанның тышкы икътисади элемтәләр министры Р.Ахунов журналистлар белән очрашты.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе В.Лихачев Мәскәүдә Русия Федерациясе Премьер-министры В.Черномырдин белән очрашты.

Татарстан Республикасы Президенты М.Шәймиев Анталиягә (Төркия) ялга китте.

«Татар-Информ», авторларыбыз һәм башка чыганакларның хәбәрләре файдаланылды.

Бу юлы Мәскәү үрнәгенә иярсәң дә ярый

РФ Президенты Б.Ельцин Русия алдындагы аерым хезмәтләре өчен бер төркем әдәбият һәм сәнгать әһелләре – Ватан сугышы ветераннарына 10 ар минималь хезмәт хакы күләмендә айлык акчалата ярдәм бирү турында фәрман чыгарды. Өстәмә рәвештә билгеләнгән «гомерлек пенсия» алучылар исемлегендә А.Ананьев, Э.Асадов, Ю.Бондарев, В.Карпов, Б.Окуджава, Н.Старшинов кебек дистәләгән мәгълүм әдипләр дә бар.

Шушы игелекле гамәл уңаеннан бик табигый сорау туа: Татарстанның Илбашы моңа охшаш карарны кайчан чыгарыр икән? Югыйсә, бездә дә Г.Бәширов, Ә.Еники, Р.Ишморат, А.Расих, Х.Камалов, Ә.Кәримуллин, М.Насыйбуллин, Г.Паушкин, М.Садри, Г.Шәрәфи кебек фронтовиклар — җөмһүриятебез мәдәниятен үстерүгә зур өлеш керткән күренекле әдипләр байтак. Белүебезчә, Президентыбызга мондый үтенеч белән мөрәҗәгать итүләр булган. Әмма әлегә нәтиҗәсе генә күренми. Югыйсә, элеккерәк елларда «Мәскәүдәге һава торышы» Казанга бик тиз әйләнеп кайта иде.

Артист гаиләләре ишәя

Гадәттә, артист тормышын чегән тормышына тиңлиләр. Әмма гаҗәп — безнең хәятебездә гаилә бәхете дигән нәрсәгә карата төрле карашлар яшәп килә. Юк шул, үз язмышын сәнгатькә багышлап, дөнья гизәргә мәҗбүр булган артист та гаилә учагын булдыру турында хыяллана. Кем генә булсак та — Президентмы, министрмы, артистмы, балта остасымы — без барыбыз да балалар, хатын, ир назына мохтаҗ.

Күптән түгел Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә шатлыклы вакыйга булды. Яшь җырчылар Динарт Закиров белән Нәсимә Дәүләтова үз язмышларын бергә бәйләргә булдылар. Күрдегезме, сизәсезме, сез чегән тормышы белән яши дип уйлаган безнең артистларыбыз да киләчәгебез; аның татарлыгы, дәвамлылыгы турында кайгырта беләләр. Әйе, бүгенге көндә артистларыбыз арасында бәхетле парлар ишәйгәннән-ишәя бара. Хәер, татар артисты турында төрле имеш-мимешләр тараткан кешеләр шуны белсеннәр иде: алар элек-электән татар милләтенә, мәдәниятенә ихластан хезмәт иттеләр, аның данын бөтен дөньяга тараттылар. Һәм ышаныгыз, татар артистлары һәрчак әхлакның үзе, милләтнең күзе булып яшәделәр. Зөһрә Сәхабиева һәм Хәйдәр Бигичев, Зәйнәп Фәрхетдинова һәм Зөфәр Билалов, Зөлфия Шакирова һәм Җәмит Шакиров корган матур гаиләләр безнең өчен үрнәк түгелмени?

Бу яңа артист гаиләсе дә, элеккеләре кебек үк, гомерле һәм бәхетле булсын иде. Амин!

Кардәшләребез бәйрәмгә әзерләнә

Польшадагы тарихчы һәм җәмәгать эшлеклесе Муса Канапацкийның хәбәр итүенә караганда, ЮНЕСКО тарафыннан «реликтив халык» дип бәяләнгән Польша—Литва татарлары үзләренең Польшага, Литва, Белоруссия, Көнбатыш Украина җирләрендә төпләнеп яши башлауларының 600 еллыгын бәйрәм итәргә әзерләнә.

Юбилей алдыннан Польшадагы татар җәмгыяте бу истәлекле көнгә һәм караимнәргә багышлап конференция үткәрергә җыена. Анда Татарстан вәкилләре дә катнашыр дип көтелә.

«Гармун-шау»ның шабы кайда?

Мәркәзебездә сентябрь аеның беренче көннәреннән «Казан кичләре» дигән җыр, бию, музыка, юмор фестивале башланып киткән иде. 12 көн дәвам иткән бәйрәмне Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе оештырды. Фестиваль күркәм генә ачылып китте. Тамашачылар фестивальне алып баручы Алмаз Хәмзиннең юмор осталыгын, Фәдис Ганиев һәм Фирзәр Мортазин концертларын, «Биш татар» тамашасын карап кинәнделәр.

Фестивальнең бишенче көнендә «Гармун-шау» концерты булырга тиеш иде. Шуңа күрә бу көнне фестиваль барган Г.Камал исемендәге театр бинасына гармун моңына гашыйк тамашачылар җыелды да инде. Тик тамаша «Гармун-шау» дип аталса да, концертта нибары ике гармунчы — Татарстанның атказанган артистлары Кирам Сатиев һәм Рөстәм Вәлиев чыгыш ясый, ә калган программа танылган артистларыбыз башкаруындагы җыр һәм биюләрдән гыйбарәт булып чыкты. Концертны алып баручы Алмаз Хәмзин үзе генә дә тамашачыларны күңелле җырлары, шаян хикәяләре белән шактый ял иттерде.

Гармун сөйгән кеше җыр-биюне дә ярата инде ул. Бу җәһәттән караганда, концертка килүчеләр бередә иркенләп ял иттеләр, чыгышларны карап кинәнделәр.

Дөрес, Рөстәм Вәлиев белән Кирам Сатиев «махы» бирмәскә тырыштылар, концертның исемен җисеменә туры китерү өчен мөмкин булганның барысын да эшләделәр, халык алдында бөтен осталыкларын ачып салдылар. Тамашачылар Рөстәм Вәлиевнең берьюлы өч гармунда бии-бии уйнавына, шырпы кабы кебегеннән дә көй чыгаруына, бияләй кигән бармакларының да җитез йөгерүенә, Кирам Сатиевның гармуныннан түгелгән моңнарга чын-чынлап сокландылар, уйнауларын тыңлап ләззәт алдылар. Тик шунысы гына ачыкланмыйча калды: концерт әллә «Гармун-шау», әллә «Кирам белән Рөстәм-шау», әллә «Алмаз-шау» булды шунда.

Сөембикә КАШАПОВА.

Казан химия мәктәбенең даны бөтен дөньяга танылган. Мәркәзебездә Бутлеров, Зинин, Камай, аталы-уллы Арбузовлар кебек мәртәбәле галимнәр яшәгән, иҗат иткән һәм химия фәнен яңа ачышлары белән баеткан. Һәм, әйтергә кирәк, хәзерге галимнәребез дә мәшһүр элгәрләренә лаеклы булырга омтылалар. Сез рәсемдә химия олимпиадасында (сулда) җиңүчеләр арасында шундый талантлы химикларыбызның берсен күрәсез. Ул — Илсөя Дәүләтбаева. Илсөя ханым Казан дәүләт технология университетында укыта, зур гыйльми тикшеренүләр алып бара. Тиздән, 19 октябрьдә, Мәскәүдә И.Дәүләтбаева докторлык диссертациясе яклаячак. Без аңа уңышлар телибез.

Тәмле дә соң бәйрәм күчтәнәче

Республикабыз халкы дәүләт мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул итүнең 5 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә мәркәзебез Казан каласыннан килгән «Моң» иҗат берләшмәсе Кайбыч районы авылларында концертлар белән чыгыш ясады. Бу бәйрәм күчтәнәченнән миңа да «авыз итү» насыйп булды. Авылыбызга артистлар киләчәк, дигән хәбәр таралгач, әбиләр читекләрен майлап, сандык төбендәге затлы чуклы шәлләрен кояшта киптереп, җилләтеп куйдылар. Кыз-кыркын ярты көн бизәнеп-ясанып очрашуга әзерләнде.

Кечке якта тирә-юнь авыллардан килгән автобуслардан да дөнья кадәр яшь-җилкенчәк, үсмерләр коелышты.

Нәфис сүз остасы Илдус Сафин сәхнәгә чыгуга, аны алкышларга күмделәр. Бу җор телле, бәрхет тавышлы сөйкемле сәякне без инде күптәннән беләбез. Аны күргәч үк авызлар ерыла башлый, пиндидер куанычлы хәл булачагын көтеп, күңел рәхәтләнә. Бу юлы да алданмадык. Илдус әфәнде туган җиргә, табигатькә, ана телебезгә, яшәешкә мәдхия җырлаучы әдәби әсәрләрне гаять оста итеп башкарды, шаянлык-шуклык ташып торган мәзәкләре дә күздән яшь чыкканчы көлдерде, авыр һәм мәшәкатьле уйлардан арындырып, җандагы юшкыннарны юып төшерде.

Соңгы елларда авылга килгән кайбер кала артистлары: «Ярамаган тагы бу сала халкына, алар бит арыш басуы белән сыер абзарыннан башка берни дә күрмиләр», — дип җыен тузга язмаган мәзәкләр укыйлар. Аларның сәхнәдә үз-үзләрен тотышлары да ташка үлчим генә, ә Илдус Сафин тамашачыны хөрмәт итә, ярата.

Авыл кешесе табигатькә бик якын бит ул. Чишмә чыңы белән сандугач җырын оригиналда тыңлап үскәнгә күрә сәнгатьне йөрәге белән тоя, яхшыны яманнан бик тиз аера.

«Моң» берләшмәсенең чыгышы җанга сары май булып ятты. Яшь җырчы Венера Галиеваның беренче чирканчыгы да бик уңышлы булды.

Рәсимә Мөхәммәтшинаның дәртле шәрык, татар биюләре исә егетләр йөрәгенә ут салды.

«Татар җыры-95» бәйгесендә гран-при яулаган яшь музыкант һәм композитор Ринат Вәлиевнең табигый сәләте дә һәммәбезнең күңеленә хуш килде. Ул концерт баянында да, курайда да, тальянда да өздерә генә. Гомумән, концертның музыкаль бизәлеше бик күркәм иде.

Билгеле ки, Габделфәрт Сафин да тамашачыларның мәхәббәтен яулап алды. Ыспай гына гәүдәле, сөйкемле Арча егете чыгышының беренче минутында ук тамашачыны үзенеке итте дә куйды. Бик уйлап, зәвык белән төзелгән аның репертуары.

Концерт күктә йолдызлар кабынгач кына тәмамланды. Таңда йолдызлар сүнәр, ләкин безнең күңелләрдә артистлар уяткан якты нурлы бизәкләр бик озак сакланыр әле.

Хәмидә ГАРИПОВА.
Кайбыч.

Евг. Евтушенко Русиядән китмәкче

Беләсездер инде, агымга каршы бару Евгений Евтушенконың холык-фигыленә һәрвакыт килешеп торды. Менә хәзер дә, мөһаҗирлек мәсьәләсе көн тәртибеннән төшерелеп, күпчелек русиялеләр туган илләрендә яшәүне хуп күргәндә дә, 60 нчы еллар буынының символы һәм намусы булган урыс шагыйре бүтәнчәрәк уйлый, күрәсең. Мәскәүдәге әдәби җәмәгатьчелеккә шундый хәбәр мәгълүм булды: Евтушенко әфәнде Америка гражданлыгын дәгъвалап үтенеч язган һәм әле күптән түгел генә шушы кыйтгада яшәргә рөхсәт алу бәхетенә ирешкән.

Бер уйласаң, гыйбрәт инде. Татар әдипләренең күпчелеге Рейхстагка байрак эләргә баргагда гына Аурупа илләрендә «яшәп» алганнар.

Татар әдәбиятының ахуны бар

Татарстанның халык язучысы
Гариф АХУНОВка 70 яшь

«Балкып яшәвең сөендерә...»



Гариф Ахунов... Шушы ике сүзне яздым да тукталып калдым. Мин әлеге исем-фамилияне йөрткән шәхес һәм күренекле әдип, алай гына да түгел, Татарстанның халык язучысы турында сүз әйтергә алынам түгелме? Дөрес, бу әдибебезнең иҗаты мине байтак еллардан бирле кызыксындырып килә, аның һәр язганын укып барам, хәтта уй-фикерләрем белән матбугатта да чыгыш ясарга туры килгәләде.

Нәрсәсе, кайсы ягы белән игътибарны җәлеп итте бу иҗатчы? Мона бер вакыйга сәбәп булды, ахры. 1975 елда Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укучы яшьләр, ниндидер җаен табып, Г.Ахуновны очрашуга чакырганнар иде. Тегесе дә әйтүдә вәгъдә биргән, яшьләр чакырган җиргә ничек бармыйсың инде, бик барам, дигән. Андый вакытта, үзегез беләсез, мәхшәр куба, тыз-быз киленә, йөзгә кызыллык китермәслек итеп хәзерләнергә тырышыла. Бу юлы да бинаны әр-яңадан юып чыктылар, очрашу буласы аудиторияне әллә ниләр ялтыратып бетерделәр. Карап торган кешегә үзе бер тамаша инде. Ник дисәң, инде ул вакытта Г.Ахунов — җөмһүриятебезнең Г.Тукай бүләге иясе, ил парламентының депутаты, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе. Кыскасы, студент халкын каушатырлык нәрсәләр юк түгел.

Менә, ниһаять, Г.Ахунов килде. Зур гына дип исәпләп йөргән аудиториябез тап-тар булып калды, чөнки язучының сүзен тыңларга теләүчеләр күп иде. Дөресен әйтим, студентлардан бигрәк мин дулкынланам. Чөнки миңа язучының иҗаты турында кереш сүз әйтү бурычы тапшырылган.

Гадәттә, андый зур урыннарга сайланган кешеләр олпат кыяфәтле, үтә җитди булалар, сүзләрен дә авыз ике теш арасыннан чыкканчы миенең әллә кай төшләреннән сайлап кына алалар. Г.Ахунов исә бөтенләй андый түгел икән. Аудиториягә килеп керде дә: «И-и, күпме яшьләр җыелган, болын чәчәкләре кебек нинди матурлар», — дип әйтеп куйды. Яшьләр исә моңа көлешеп алу белән җавап бирделәр. Гариф абый, аудиториянең шактый бөркүләнгәнен чамалап, пиджагын урындык артына элеп, ак күлмәктән генә калды, галстугын бераз бушаткандай итте.

Без җиңел сулап куйдык. Чөнки беләбез, рәсми кешеләр, битеннән тире чишмә булып акса ага, тиешле кыяфәтне саклар өчен, пешеп утырса-утыра, әмма халык алдында болай «туарылып» ташлауны башына да китерми. Гариф абыйның мондый «прастуйлыгы» безне әлеге киеренкелекне дә юып алгандай булды. Очрашу гади генә башланып китте. Бу кичәдән без Г.Ахуновны тәмам үз итеп таралыштык. Сихерләде безне бу җор телле язучы.

Моның белән әйтәсе килгән сүз шул: Гариф Ахунов — гади кеше, самими кеше, ачык кеше. Ул — кешеләрне яратучы җан. Кешеләрне ярату һәркемгә дә кирәкле сыйфат, язучы исә шуннан башка кәгазьгә ике сүз дә төшерә алмый. Чөнки аның төп сурәтләгәне — кеше. Үзең сокланмаган, олылап карамаган нәрсә турында илһамланып язып буламы? Юк, мең тапкыр юк. Аның барлык каһарманнары иң әүвәл автор үзе сокланган кешеләр. «Хәзинә», «Хуҗалар», «Чикләвек төше», «Ардуан батыр», «Идел кызы» һ.б. әсәрләре белән таныш кешеләр моның шулай икәнен әйтмәсәң дә беләләр. Әйтик, «Яшьлек яме»ндәге профессор Мохтаров образын иҗат итүгә күренекле галимебез Латыйф Җәләй илһам бирсә, андагы Гөлнур исә Гариф абыйның сабакташы, соңыннан хатыны Шәһидә ападан алып язылган. Таһир дигән егеттә Гариф Ахуновның үз чалымнарын күрәбез.

Г.Ахунов турында байтак авторларның мәкаләләрен укырга туры килгәне бар. Шулар арасында аның холкына бәрабәр итеп язылганнары күп түгел, шуларның берсе аның иң якын каләмдәшләреннән булган Мөхәммәт Мәһдиевнең «Замандашым турында бер сүз» дип аталганы («Азат хатын», 1975, №9). «Без аның белән бер төбәктә туып үстек, авылларыбыз арасында йә күк чәчәкле җитен басуы, йә җилдә бөтерелеп утырган бодай басуы гына иде. Безнең авылдан чыгып басу түбәсенә күтәрелсәң, тәгәрәшеп дулкынланган иген басуын кичсәң, Гарифлар авылы — безнең өчен кечкенәлеге белән мәңгелек сер булып калган алты өйле генә Өчиле авылы күренә иде. Шуның өстенә безнең авылда, безнең бала вакытта ук «Өчиле Ахун» дигән кеше турында сөйлиләр иде, чөнки Өчиле Ахун безнең авыл кызы Бибинур апаның кияве булган икән». Юбилей мәкаләсен (бу мәкалә Г.Ахуновның 50 еллыгына язылган) 1975 елгы шартларда әнә шулай гади генә итеп язу М.Мәһдиевнең егетлеге иде. Шуның өстенә болай язу өчен ихласлык һәм, әлбәттә, Г.Ахуновны үз күрү кирәк. Әйе, Г.Ахуновның үзенең дә ниндидер сөйкемле сөяге бар, аны якын итмәү гайре табигый булыр кебек. Әйдәгез, замандашы турында М.Мәһдиевнең гади генә иттереп тагын ниләр язганлыгын укыйк әле. «Авыр вакыт иде, әмма Ахуновның борын салындырып йөргән, зарланган чагын күрмәдек. Аның белән сөйләшкәндә, аралашканда, тамак ачлыгы да, авырлыкта онытыла иде, аның тирәсендә тормыш кайный иде. Чөнки Гариф тик торуны, бушка вакыт уздыруны белмәде. Ул гел хәрәкәттә, гел шау-шу эчендә иде, күңел төшенкелегенә бирелергә аның вакыты калмый иде. Ул вакытта кемнең кем буласын шайтан белгәнме? Гариф әдәбиятны ярата, ул фәннән гел «бишле» ала. Җор телле Яхья Халитов белән дус иде. Алар әдәби темаларга бәхәсләшкәндә, тулай торакның начар ягылган салкын бүлмәләре җылынып киткәндәй, карточкага алган биш йөз грамм ипи бер килога әйләнгәндәй була, дөньялар ямьләнеп китә иде». Әгәр М.Мәһдиев якташы Г.Ахуновның әлеге бәйрәменә кадәр яши алса, бүген аны тагын да гадирәк, табигыйрәк сурәтләп матбугатта чыгыш ясамый калмас иде. Аның каләменнән моннан егерме ел элек төшкән сүзләрне шактый мул китерәбез, рухы шат булсын. Алар Г.Ахуновның бүгенге шәхесен аңлауга да ачкыч булып хезмәт итәләр. «Мин флоттан хезмәт срогын тутырып кайтканда, — ди М.Мәһдиев, — Гариф инде күтәрелеп килә торган язучы, өметле яшь тәнкыйтьче иде. Аның Федосеевская урамындагы тар бүлмәсен хәтерлим: бердәнбер чөйгә аның кыршылган пальтосын, минем кара шинель белән фуражканы элдек тә идәнгә тәгәрәдек. Гариф миңа үзенең беренче әсәре «Яшьлек яме» повестеның ничек язылуы турында сөйләде. Соры одеал ябылган тимер карават, какшау аяклы иске өстәл өстенә 20—30 блокнотын чәчеп ташлады да, повестена материалны, сүзне, геройны каян алганын, ничә еллар җыйганын сөйләде. Озак сөйләде, керосинка өстендә кыздырырга куйган вермишелебез яна башлаган иде. Шунда, әдәбият дөньясыннан бик еракта гомер уздырган кеше буларак, мин уйлап алдым: бу кеше тормышта үзенең юлын тапкан, үзен шуңа багышлаган... Чөнки әдәбияттан башка ул берни дә сөйләмәде, зәңгәр төтен чыга башлаган табасын да мин әйткәч кенә читкә алып куйды, аны да аңлап түгел, болай гына...»

Г.Ахуновның «Соңарып килгән бәхет» дигән хикәясе бар. Аның каһарманы Рәхим Сөбханкулов — гомер буе сәнгатьтә үз сүзен әйтә алмаган биюче. Инде лаеклы ялга да чыккан. Әмма очраклы рәвештә генә ул нефтьче яшьләр белән бер күмәк бию иҗат итә, анда әлеге егет-кызларның хезмәтен, хис-кичерешләрен моңа кадәр беркем дә эшли алмаганча гәүдәләндерүгә ирешә. Бу исә аны чиксез бәхетле итә. Әсәрдә шундый сүзләр бар: «Бик соң килгән бәхет түгелме бу? Сәнгатьтә дөрес юлны яшьрәк чакта тапкан булса, ниләр генә эшләмәс иде әле ул». М.Мәһдиев мәкаләсен укыгач, менә шушы сүзләр хәтеремә төште. Дөрес, М.Мәһдиев тә үзенең әдәбияттагы урынын алай артык соңарып тапмады, аның каравы, бер тапкач халкыбызга әнә нинди энҗе-гәүһәрләр бирде. Г.Ахунов исә, әдәбияттагы урынын иртә тапты һәм бу юлда «ниләр генә эшләмәде!» Үз гомерендә 55 китап кына чыгарды, аларның 17се — урыс, 15е башка халыклар телләрендә. Хәзер исә мәгълүм тәрҗемәче М.Өнәр аның «Идел кызы» романын «Габбас хәзрәт» исеме белән төрек теленә тәрҗемә итә. Димәк, ул озакламый кардәш ил укучыларына барып ирешер. Җитмеш яшьнең кырык өче иҗат белән үткән икән, димәк, кайбер елларда елга икешәр китап туры килә дигән сүз. Әйтергә генә ансат, китап чыгарып караган кеше белә, аның берсен генә укучы кулына ирештерү никадәр күп хез-

(Дәвамы 6—7 нче битләрдә).

● Арча районы, Казанбаш урта мәктәбендәге әдәбият укытучым Хәнифә апа Абдуллина — минем өчен иң кадерле кеше.

Гариф АХУНОВ. Декабрь, 1987.

алга килеп баскач, Г.Ахунов — роман авторы — моны башкарып чыгуда кыенлыкларга очрады. каләме аңа буйсынырга теләмәде. Аның каравы, бу эшне Мансур Шиһапов әйбәт эшләп чыкты. 1983 елда Татар дәүләт драма һәм комедия театры (хәзер К.Тинчурин исемен йөртә) Ташкенттагы гастрольләрен шушы әсәр белән башлап җибәрде. Спектакль «Кошның да үз канаты була» дип исемләнде. Шәвәли образын башкарган Н.Шәйхетдинов аеруча югары бәя алды. СССРның халык артисты А.Талипов әсәр һәм аны сәхнәләштерүчеләргә соклануын белдерде. Шулар өстенә без «мемуарчы Г.Ахунов» дияргә дә әле яңа гына күнегеп киләбез. Дөрес, «Йолдызлар калка» китабын укып, без инде моңа байтак еллар элек инанган идек. Хәзер бу китапның икенче кисәге матбугатка әзерләнде дип ишетәбез. Без аннан Г.Ахунов тормышындагы аеруча катлаулы бер чор белән танышырбыз дип өметләнәбез.

Г.Ахуновның каләм байлыгы турында сүз алып барганда тагын бер зур катлам бар. Яшь чагында

Әгәр дә бу язмаларның авторы ун ел Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе, «Казан утлары» журналы мөхәррире, Әлмәт язучылар оешмасының беренче җитәкчесе, зур җәмәгать эшлеклесе икәнен исәпкә алсак, аларда никадәр бай мәгълүмат тупланганлыгын күз алдына китерү кыен түгел. Дөресен әйткәндә, Г.Ахунов кырык биш-илле еллык тарихыбызны кәгазьгә беркетеп барган. Шуңа күрә бу язмаларның дөнья күрүе әдәбиятыбыз һәм, гомумән, мәдәниятебез, тулаем җәмгыятебез тарихына күпме ачыклык кертер иде.

Татар кино сәнгатен күпмедер дәрәҗәдә урыныннан кузгатып җибәрүгә дә аның өлеше керде. Свердловски киностудиясендә «Хәзинә» романы буенча нәфис фильм төшерелде. О.Воронцов режиссерлыгында эшләнгән б... фильмда Г.Шамуков (Шәвәли), Ш.Биктимеров (Нуришанов), В.Минкина (Мәгыйшә), Д.Ильясов (Габбасов), Р.Шәрәфиев (шаян нефтьче) һәм башка артистларыбыз катнашкан иде. Ул гына да түгел, кино сәнгате белән әнә шулай турыдан-туры очрашкач, безнең ар-

«Балкып яшәвең

мәт һәм киеренке эш сорый. Аның янына газет-журналларга чәчелгән йөзләрчә мәкаләләрне өстә. Ул — иҗат эшчәнлеген тәнкыйтьче булып башлаган кеше. Б.Брайнина, А.Тарасенков аны тәнкыйтьче буларак югары бәяләгәннәр. Татарстанның яшь язучылары семинарында М.Максуд Г.Ахуновны әдәбиятка зур әзерлек белән килүчеләр арасында атый, аңа өмет баглавын белдерә. Ләкин кулланылышта нигездә язучы Гариф Ахунов дигән төшенчә генә бар, аны тәнкыйтьче дип атаучыны сирәк очратырга туры килә. Ә бит бу каләм әһеле бөрөзлексез соңгы илле елдагы әдәбият тарихын, аның эстетик үсеш кануннарын күзәтеп-күрсәтеп, шуларга үз карашын белдереп бара. Ул хезмәтләренең байтагы 1985 елда «Чишмәләр белән сөйләшү» дигән калын китапта бергә тупланып дөнья күрде.

Алай гына да түгел, без «шагыйрь Г.Ахунов» дип тә әйтмибез. Аның бүгенге көндә ике том әзер шигырьләр җыентыгы бар. Дөрес, алар әлегә басылмаган. Әмма көндәлек матбугатта дөнья күргәннәре дә җитәрлек Үткен күзле, нечкә хисле композиторларыбыз безгә караганда сизгеррәк. Алар Г.Ахуновның унбиштән артык шигыренә көй яздылар. Ф.Әхмәт язган «Якты көн» җыры дога булып яңгырый. Безнең борынгы бабаларыбыз иртән Кояшны сәҗдә кылып каршы алганнар. Г.Ахунов та бу җыры белән ил-көнебезгә тынычлык, бәхет, җимешле хезмәт тели. Р.Дәминов, З.Сәхәбиевалар башкаруында бу әсәр безнең күңел түрләребезгә үтеп керә. С.Ибраһимовның «Һәйкәл салыйк Сәйдәшкә», М.Имашевның «Ил сагында калды шагыйрьләр», «Башым салыйм таңда кемнәргә» җырлары белән дә шул ук хәл. «Утлар яна учакта» әсәре буенча куелган спектакльгә җыр текстларын язуны Г.Ахунов Әлмәттә яшәүче шагыйрә С.Сөләймановадан үтенә. М.Имашев аларны музыкага сала. Әнә шулай өч кешенең иҗат дуслыгы белән туган «Гүзәлия», «Сәләхи җыры», «Нефтьчеләр маршы» ничә еллар инде безнең яшәешебезне матурлап яңгырыйлар. Без «драматург Г.Ахунов» та димибез. Ә «Утлар яна учакта» әсәре үз вакытында нинди зур уңыш казанды. Г.Ахунов Ш.Камалның «Акчарлаклар» повестен сәхнәдә кую өчен нинди күркәм итеп эшләде! Ул байтак еллар буе театр сәнгатебезнең иң абруйлы сәхнәсендә — Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында уйналды. Шунысы кызык, «Хәзинә» әсәренең сәхнә вариантын язу бурычы ук Гомәр ага Бәширов аңа амбар кенәгәсе ачарга һәм шунда көндәлекләр язып барырга киңәш иткән икән. Бу шөгыль тора-бара Г.Ахуновның көндәлек бер мәҗбүри үтәлергә тиешле эшенә әверелгән. Чыннан да, кая гына барса да, сез Г.Ахуновны әлеге амбар кенәгәсеннән башка күрмәссез. Ул, җыелышта катнашамы, әллә берәр очрашудамы, күргәннәрен-ишеткәннәрен язып утыра. Юк, хәтере начар булганнан түгел аныcы, Аллага шөкер, яхшы, хәтта бик яхшы! Әллә кайчангы хәл-әхвәлләрне нечкәлекләре белән түкми-чәчми сөйләп бирә. Хикмәт каләм эшенә үтә җаваплылык белән карауда. Чөнки әлеге амбар кенәгәсе тора-бара әсәрләргә, мәкаләләргә ризык бирәчәк, анда теркәлгәннәр әдәби образлар, детальләр булып әвереләчәк.

Амбар кенәгәләренең кайберләрен минем дә кулыма тотып караганым бар, күпме хәзинә теркәлгән ул саргаеп беткән кәгазь битләрендә. Г.Ахунов анда үзе турында язмый бит. Ул башка кешеләр хакындагы каләмгә әлегердәй нәрсәләрне бөртекләп туплап бара.

тистларыбыз тагын да яңадан-яңа образлар тудыру уе белән яна башладылар. Г.Шамуков, мәсәлән, болай диде: «Мин татар әдәбияты классигы Г.Ибраһимовның «Безнең көннәр» романының экранлаштырылуын күрергә хыялланам». Бу урында шуны әйтәсе килә: и мәрхүм Габдулла агай, Сезнең бу уйларыгыз әле хәзер дә хыял гына булып кала шул. Татарстан киносы һаман да тәпи атлап китә алмыйча газаплана.

Аның каравы, Казан телевидение студиясе бу яктан уңышлы гына адымнар ясады. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әхтәм Зариповның «Идел кызы» әсәре буенча 1989 елда фильм-спектакль әзерләве үзе генә дә зур вакыйга булды.

«Идел кызы» турында сүз чыккан икән, әлеге әсәр күп яктан Г.Ахуновның новатор язучы булуын раслады. Ул совет хакимияте елларында бездә кешеләрнең гаять авыр язмышларга таруларын күрсәткән беренче әсәрләрдән булды. А.Гыйләҗев, Ә.Еники юл салган бу мәүзугның яңа катламнарын ачуга Г.Ахунов җитди өлеш кертте.

● Әлмәт язучылары Гариф Ахунов, Рафаил Төхфәтуллин, Әдип Маликов.

Әлмәт. 1963.

● Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим һәм Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов «Азат хатын» журналы редакциясендә.

Август, 1977.

● Алгы планда: авар халык шагыйре Рәсүл Гамзатов, казакъ язучысы Жубан Мулдагалиев, Гариф Ахунов, «Татнефть» берләшмәсенең генераль директоры Әкълим Мөхәммәтҗанов.

Мәскәү. 1982.

● Русия Язучылар берлеге идарәсенең проза буенча күчмә утырышында С.Залыгин, В.Гусев, Г.Ахунов.

Карелия. Петрозаводски. Сентябрь, 1981.

сөендерә...»

Социалистик реализм теориясе коммунизм идеаллары өчен көрәшчене генә уңай каһарман дип таныды һәм аны гына әсәр үзәгенә куеп сурәтләүне таләп итте. Г.Ахунов исә бу романында бөтенләй башка юлдан китте. Әсәрнең беренче кисәгендә бөтен вакыйгаларны Габбас мулла тирәсенә җыеп бирде. Ходай тәгаләнең изге бер бәндәсе булган Габбас мулла гаиләсенә ничарадан бичара гына килеп керә. Ул – бөтен барлыгы белән җир кешесе. 1917 елгы вакыйгалардан соң Габбас, мулла булуы сәбәпле, йортсыз-җирсез, мал-туарсыз калдырыла. Кызы Нурия . аның фаҗигасен тагын да тирәнәйтү өчен кертелгән образ. Югары уку йортында укучы Нурия, үзен университеттан чыгармасыннар өчен, мулла дип аталучы әтисеннән, ягъни Габбастан баш тарта. Димәк, Габбас иң якыннарыннан да мәхрүм кала. Мондый хәлдәге кеше төрле хәлиткеч адымнарга сәләтле буладыр. Шулай килеп чыга да. Яңа дип аталган кешелексез җәмгыятьнең аны читкә этәрүен, ихтимал, ул әле, авыр булса да, күтәрә дә алган булыр иде. Әмма газиз баласының атасыннан баш тартуы аны үз-үзен һәлак итүенә китерә. Беренче кисәк Габбас мулла фаҗигасен күрсәтүгә багышланган. Ул аның исеме белән аталырга тиеш иде дә. 1978 елда «Ил язмышы» дигән мәкаләмдә мин әнә шулайрак дип язып чыккан да идем. Гариф абый, мәкаләне киссп алып, аның кырыена болай дип язып куйган: «Идел кызы»на, журналда басылганнан соң бер ел тулгач, рецензия чыкты Соң булса да, уң булсын. Әсәрне тәнкыйтьче дөрес аңлаган. Рәхмәт аңа. Г.Ахунов. 15.X.1978» Бу үзе өчен генә дип язып куелган берничә җөмләдә Г.Ахунов шәхес буларак та ачыла. Шундый киң күңелле, сүзен кызганмыйча, мул итеп әйтә белә торган әдип ул. Бу ягы аның иҗат үзенчәлеген дә билгели. Образларны сурәтләүдә дә ул аларның үзләренә «ирек бирә», гамәлләрен-сүзләрен тыеп тормый Менә шул хасият аның каһарманнарының әсәр мәйданында «үзаллы» яшәүләрен тәэмин итә дә Аның Халикъ Саматов («Чикләвек төше») һәм Галинур Айтуганов («Гомер юлы») образларын гына алыйк. Аларның иҗат ителүләре арасында егерме еллап вакыт аралыгы ятса да, автор нигездә бер үк мәсьәләне, ягъни тоталитар тәртипләр вакытында коммунистлар фиркасе һәм җитәкче кеше язмышы мәүзугын яктыртга. Юк, бу кабатлану түгел, бәлки төрле чорларда бер үк эш стиленең (катып калганлыкның) бөтенләй башка нәтиҗәләргә китергәнлеген тормышның үзеннән чыгып сурәтләү. Әйе, Г.Ахуновны, язучы буларак, тормышның барометры дип атап булыр иде. Ә бу язучы өчен гаять кирәкле сыйфат

Партиянең кадрлар мәсьәләсендәге төп хаталарыннан берсе, Г.Ахунов әйтмешли, аңа «тырышып ярамый кеше, койрык болгап ярый». Әгәр дә партиягә күпчелекнең карьера, түрә булып үрмәләү өчен кергәнлеген искә алсаң, бик куркыныч әйбер иде бит ул. Алар эшнең рәтенә төшенү, кешеләргә игелекле булу, үзләре җитәкләгән коллективларны үрчемле эшкә оештыру урынына «болай итсәм, райком, обком нәрсә әйтер икән?» дигән үлчәм белән эш иттеләр. Төп тырышлык партия түрәләре алдында яхшы атлы булып күренүгә юнәлде. Моның бәрабәренә гомуми эшкә бармак аша карау алар өчен берни дә тормады.

Г.Ахунов ике әсәрендә дә, шушы мәүзугны тирәнәйтеп, әлеге хәлнең афәтле якларын ачуга язучылык сәләтен туплый. Укучы белә: «Чикләвек төше»ндә, дүрт меӊ центнер ашлыкны күгәрткән дигән сылтау белән, райком секретаре Байназаров колхоз рәисе Саматовны эшеннән алу мәсьәләсен куя һәм моңа ирешә дә. «Гомер юлы»нда да шул ук хәл. Утыз җиде яшьлек колхоз рәисе Галинур Айтуганов ашлыкны райком таләп иткән вакытта чәчмәве (җир өлгерүгә карап эш итүе), икмәкне дәүләткә киптереп тапшыруы (чи тапшырсаң, план үтәү өчен бермә-бер артык бирергә кирәк) сәбәпле, районның планны үз вакытында үтәвен өзгән булып чыга Гомумән, аның үз акылы үзендә, шуңа күрә колхоз елдан-ел ныгый бара. Болар, әлбәттә, «райкомга бар җирдә дә буйсыналар, бар җирдә дә партия җитәкчелек итә» дип катып калган райком секретарьлары Байназаров, Тимергалиев ишеләр өчен гадәттән тыш хәлләр. Халикъ, Галинурлар мондыйларга тамак төбенә утырган балык кылчыгы иде.

Г.Ахунов исемен телгә алдыңмы, әлбәттә, аның «Хәзинә» романы хәтергә килә. Соңгы вакытта нефтьчеләр тормышыннан алып язылган завод-фабрика эшчеләре, әсәрләргә ясалма рәвештә ниндидер бер өнәмичәрәк карау кебек нәрсә сизелә башлады. Ләкин барлык әсәрләрне дә бер чыбыктан гына сөрү ярап бетмәс. «Хәзинә» — кешеләр һәм аларның язмышлары турындагы әсәр. Дөрес, әсәр эпик колачлылык белән башланып китеп тә, сюжет сызыкларының тараеп калуы, аерым образларның камиллеге җитмәве турында үз вакытында сүз булды Аның каравы, «Чикләвек төше», «Ардуан батыр», «Идел кызы» әсәрләре инде бу яктан да тел-теш тидерерлек түгел. Алар — безнең прозабызның үсешен, камилләшүен күрсәткән әсәрләр булдылар. Мәрхүм И.Нуруллин да иң соңгы язмаларының берсендә «Гариф Ахунов булу да кечкенә дәрәҗә түгел. Аның «Идел кызы» романы һәм андагы Габбас мулла образы Ахуновның үз яктысы белән яктыртырга сәләтле язучы икәнен күрсәтте. Мәгълүм булганча, ...русларда алдынгы карашлы дворян яшьләре башкарган эшне татарларда руханиларның намуслы һәм талантлы өлеше башкарды. Кайбер галимнәр курка-курка гына, теш арасыннан чыгарып кына әлеге хәл турында сүз кузгата башласалар да, бу закончалыкка Гариф Ахуновка һәм аның Габбас мулласына чаклы әдәбиятыбызның игътибары булмады. Гариф Ахунов әлеге закончалыкны җанлы образларда тормышчан итеп гәүдәләндерде һәм укучыга тарихыбызның үзенчәлеген аңларга ярдәм итте. Димәк, Гариф Ахуновның үз яктысы белән балкырга сәләте һәм мөмкинлеге бар». Каләмдәшләренә уңай сүзне бик талымлап кына әйткән мәрхүм Ибраһим Зиннәт улының бу фикерләренә игътибар итмичә һич мөмкин түгел.

Гомәр ага Бәширов Г.Ахуновның бу сыйфатларын әле 1968 елда ук билгеләгән иде. «Китабында (сүз «Хуҗалар» романы турында бара) тагын бер нәрсә ачык сизелә: фикер хөрлеге. Бу кыюлык кына, вакытлы батыраю гына түгел, бәлки туган илеңне, халкыңны сөюдән килеп туа торган, догмаларга буйсынмаска көче җитә торган гражданлык сыйфатларыннан берсе». Менә ничә дистә еллар инде Г.Ахунов шушы сүзләргә лаеклы булып иҗат итә.

Гариф абыйның гаиләсен дә язучылардан тора дип әйтергә мөмкин. Хатыны Шәһидә апа — «Минем кала алуым» исемле повестьның авторы, байтак кына әсәрләрне татарчага тәрҗемә иткән каләм әһеле. Ул — Гариф абыйның әсәрләрен иң беренче булып укучы һәм аяусыз «өй» тәнкыйтьчесе. Улы Рәшит исә татарчадан урысчага тәрҗемә итү буенча байтак хезмәт куйган кеше. Ш.Маннурның «Муса» романын «Современник» нәшриятында чыгаруда аның хезмәте зур булды. Р.Ахуновның «Әдәби тәрҗемәдә компенсация методы» дигән мәкаләсе тәрҗемә теориясенә кертелгән әйбәт өлеш дип карала ала. Язу эшенең кадерен белгән шундый гаиләдә иҗатның үрчемле һәм җимешле булуы бик табигый. Кеше өчен иң мөһиме аны гаиләдәгеләрнең аңлавы, аңа теләктәшлек итүләре бит. Хәер, гаиләдәге мохитне дә кеше үзе барлыкка китерә. Гариф абыйның кечкенә генә язу бүлмәсендә иң абруйлы урында ике татар карчыгының портретлары эленеп тора. Берсе — Гариф абыйның әнисе Бибинурныкы, икенчесе — Шәһидә апаның әнисе Йөзлекәйнеке. Шәһидә апаның әнисе байтак еллар бирердә яшәгән. Шәһидә апа кинәнеп болай ди:

— Гарифҗан белән әни бик дуслар иде.

Шушы урында Шәһидә апа мәхәббәт тулы күзләре белән иренә карап куя. Үз әниеңне хөрмәт итеп яшәгән кеше белән гомер кичерү аңа бик рәхәт икәнлеге әллә каян күренеп тора. «Ә мин, — ди Шәһидә апа, — Гарифҗанның әнисе белән сердәш идем. Гарифҗан берәр ярамаганрак эш эшләсә, хәзер әнигә әйтәм дип куркыта идем.» Шулай дигәч, ирле-хатынлы Гариф абый белән Шәһидә апа рәхәтләнеп көлешәләр.

Гариф абыйны минем төрле шартларда күзәткәнем бар. Идарә утырышларында ул — бик таләпчән кеше. Фикерен кистереп әйтеп чыгышлар ясый. Өендә ул — йомшак күңелле ир, ата һәм оныкларын өзелеп яратучы бабай. Язудан арса, кулына пумала алып, табигатьнең матур күренешләрен киндергә төшерүче рәссам. Әңгәмә вакытында җор телле сүз остасы. Аның туйларда, күңелле мәҗлесләрдә тамадалык итүе үзе бер сәнгать. Бу шәхеснең күпкырлылыгын В.Распутин да әйтми кала алмый. «Еллар уза, мин әле һаман төньякка сәяхәт кылуыбызны оныта алмыйм. Мин табын янындагы шат күңелле, мәзәкчән тамаданы, президиум өстәле һәм чыгыш ясаучылар өчен куелган мөнбәрдәге җитди (тик сүз өчен кесәгә тыгыла торган җитдилек дип әйтмим) дәүләт эшлеклесен гел искә төшерәм». Г.Ахунов белән бер очрашып сөйләшкән кешеләрнең күбесе аны яратмый калмыйдыр. Шуннан соң аны хатлар белән күмәләр. Аның архивында язучыларның гына меңнән артык хаты саклана. Ярый, боларның байтагы ниндидер йомыш төшеп язылган булсын, ди. Әмма Г.Ахунов аларның һәрберсенә җавап биргән, җавапларның күбесе ике-өч биттән алып алты-җиде биткә кадәр сузыла. Димәк, аның хатлары гына да томнар тәшкил итәрлек. Ә укучылардан килгән ун меңнән артык хат! Болары инде әсәрләрен укыгач, күңел кузгалу нәтиҗәсендә язылганнар. Г.Ахунов аларны бик кадерләп саклый, кат-кат укый. Шулардан үзенә иҗатка илһам ала. Үзең кешеләрне яратсаң, мәхәббәттән мәхрүм калмассың, диләр бит. Хәсән Туфан сүзләре бу фикерне тагын да ныгытып куя: «Өметебез, шатлыгыбыз булуың өчен яратам мин сине, Гариф: гүзәл һәм бай йөрәгеңне әдәбиятыбыз эшләренә фидакарьләрчә багышлап, балкып яшәвең сөендерә минe». Бер Х.Туфанны гына түгел, безне дә сөендерә. Г.Ахуновның үз уты, башкаларга охшамаган яктысы бар. Аның Казансуга карап торган иҗат бүлмәсенең тәрәзәләрендә иртәнге биштә һәрвакыт балкып ут кабынсын. Ул ут безгә — укучыларга кирәк. Чөнки андагы яктылык, җылылык, миһербанлылык безнең йөрәкләргә дә күчә.

Фоат ГАЛИМУЛЛИН.

Әдипнең алтын хәзинәсе

Шәһидә МАКСУДОВА: «Мин студентка кияүгә чыктым»

— Шәһидә ханым, Гариф абыйга кияүгә чыкканда, башыгызда шулай матур итеп, чукердәшеп гомер кичерербез, сәләтле балалар үстерербез дигән уй-хыял бар идеме?

— Өйләнешкәндә гаилә тормышының нечкәлекләре, серләре турында бөтенләй уйлап, киләчәккә планнар корып бетереп буламыни ул?! Икебез дә авыл балалары: мин — Әгерҗедән, Гарифҗан — Арчадан, университетта укыйбыз, IY курста, бер группада. 1951 елның сентябрендә тәвәккәлләдек. Группадашларыбызның туй бүләгән — шикәр савытын бүген дә кадерләп саклыйбыз.

Ул чакта хәзерге көнне күз алдына китерергә мөмкин идемени соң? Мин бит язучы Гариф Ахуновка түгел, студент Гарифҗанга кияүгә чыктым. Гаилә тормышыбыз шул еллардагы меңнәрчә яшьләрнеке кебек башланып китте, фатирдан фатирга күчеп.

— Гариф абый каһарманнарны, вакыйгаларны үзе уйлап чыгармый, тормыштан алып яза. Шулай булгач, Шәһидә Максудовага хас сыйфатлар аның кайсы әсәрләрендәге геройларда чагыла?

— Үземне ирем әсәрләреннән эзләмим. Сүз иярә сүз чыкканда, җае килгәндә, дус-ишләрем болай дип әйткәлиләр: «Яшьлек яме»ндә — Гөлнур, «Идел кызы»нда Шәфика нәкъ үзең инде, кискән дә каплаган», диләр. Бәлки шаярта торганнардыр?

— Гариф Ахуновның хатыны татар әдәбиятының кайсы өлкәсендә хезмәт итә?

— Мин — тәрҗемәче. Укучы тәрҗемә аша дөнья әдәбияты китапларын ача. Үзем тәрҗемә өлкәсендә эшләгәнгә күрәдер инде, аны халык өчен кирәкле жанр дип саныйм.

— Сезнең ирегезгә иң зур теләгегез нинди?

— Гарифҗанны татар халкы олылады, аңа зур кадер-хөрмәт күрсәтте. Ул шушы олы дәрәҗәне язучы буларак та, кеше буларак та гомер буена тап төшерми сакласын иде. Шул чакта Ахуновларның бөтен нәселе бәхетле булыр.

Рәшит АХУНОВ: «Әтинең җиде китабын тәрҗемә иттем»

— Рәшит энем, син өченче көн — әдәбиятта, кичә — бизнеста идең, бүген — министр. Иҗади эштән коммерциягә күчүне, икътисад белән бөтен бер министрлык башында торып җитәкчелек итүне авыр кичермисеңме?

— Юк. Мин һәр эшкә, зурмы ул, кечкенәме, тулы бер иҗади процесс итеп карыйм. Бу процессны көн саен тәгаен эшләр белән тулыландырып, баетып торырга кирәк. Ниндидер бер вакытка үз алдыма куелган максатка ирешүне әдәби әсәр язып бетерү белән бер дәрәҗәдә күрәм. Һәр икесеннән дә мин зур канәгатьләнү хисе кичерәм.

— Министр Рәшит Гарифҗан улына язучы Гариф Ахуновның һәм тәрҗемәче Шәһидә Максудованың нинди сыйфатлары күчкән?

— Әти — жаны-тәне белән эшкә бирелгән кеше, ару-талуны белми. Язучы буларак, ул тормышта һәр нәрсәдән уңай сыйфатлар табарга тырыша һәм моңа ирешә дә. Әтием шуның белән бик бәхетле. Эшне зурга, кечкенәгә бүлми. Һәрберсен күңел биреп, намус белән эшли. Юморны ярата, аңа шаярту хас. Болар Ходай Тәгалә тарафыннан һәркемгә дә бирелми. Һәр сүзнең, фикернең мәгънәсен секунды-минуты белән тотып ала, аларга җавабы әзер.

Әни һәр мәсьәләне төбенә төшенеп, уйлап, матур итеп хәл итәргә ярата.

Мөстәкыйль тормыш юлым башында тәрҗемәче эшен сайлавым, һичшиксез, әти-әни йогынтысы. Минем тәрҗемәдә әтинең җиде китабы урыс телендә басылып чыкты. «Хәзинә» һәм «Идел кызы» да урыс укучыларына минем тәрҗемәдә барып ирешә.

Әтиемнең бүгенге көндә иҗат ялкыны дөрләп торуга мин бик шат. Ул иҗат иткән әсәрләр — халкыбызның рухи хәзинәсе.

Шәһидә МАКСУДОВА
һәм Рәшит АХУНОВ белән
Мәгъсүм ГӘРӘЕВ сөйләште.

Наилә АХУНОВА: «Минем гаиләм — туган-үскән оям...»

Юк, бу һич кенә элек кемнәрдер тарафыннан тудырылган «космонавтлар гаиләсе»н «яңарту» да, «Алма агачыннан ерак төшми» дигән сүзләрне раслап маташу да түгел. Бу — бары тик чынбарлыкны, үз халкыбыз табигатендәге матур бер күренешне барлау. Әйе, Гариф ага Ахуновның гаиләсендә без әдәбиятка, иҗатка мәхәббәтне, дөньяны иҗат аша танып белүгә чиксез омтылышны күрәбез. Гариф абыйның җәмәгате Шәһидә ханым, уллары Рәшит — алар икесе дә Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары. Кызлары Наилә исә Мәдәният институтын тәмамлаган, китапханәдә, мәгариф өлкәсендә эшләгән. Бүгенге көндә ул — Казан медицина университетының «Казанский медик» газете мөхәррире. Наилә шигырьләр, әкиятләр яза. Бүген без аның берничә шигырен укучыларыбызга тәкъдим итәбез. «Әтиемә бүләк булсын алар», — диде Наилә редакциябезгә шигырьләрен китергәндә.

Нияз АКМАЛ.

* * *

Дөньяларым гик шатлыктан тормас,
Жыйганнарым чәчәк кенә булмас,
Юлларыма йолдыз коелмас.
Йөрәккәем сулык-сулык килер,
Мәхәббәтен җуйганлыгын белер,
Сагышларга дөньям күмелер.

Бәхет – китәр, өмет — куркып калыр,
Аңысын да ятлар тартып алыр,
Төннәремнән Аем югалыр.
Тик күз яшем мине ташлап китмәс.
Хатирәләр мине ялгыз итмәс,
Аһ-зарымны ятлар ишетмәс.

Бәхет мине кабат табып алыр.
Эзләремнән килеп табып алыр.
Күзләремнән үбеп юаныр.
Төннәремә сабый чагым килер,
Төшләр күрер ~ изге төшләр күрер,
Ай нурына төнем күмелер...

Язгы манзара

Барлык төсләрдән дә өстен
Ак төсләр әлегә.
Актан әле агачларның
Ябынган шәле дә.
Тик март-рәссам юмарт сибә
Яз башы төсләрен:
Зәңгәр буяуларга мана
Ап-ак кар өсләрен.

Минем йортым

Минем йортым ~ минем ярты дөньям,
Минем гаиләм ~ туган-үскән оям,
Жылы назын аның һаман тоям.
Минем гаиләм ~ минем таш кыям.
....
Читкә китсәм, сагынып ярь коям,
Таш кыяма кайтып баш куям.

Салават күперенең сигезенче төсе

Әйе, әлеге рәсемнәр аның өендә, дусларында-туганнарында саклана. Язучы аларны үзе иҗат иткән. Күп кенә картиналарын ул, әйткәнебезчә, дусларына-каләмдәшләренә бүләк итеп биргән.

Гариф Ахуновның өендә булганда фотохәбәрчебез Ә.ШӘФИГУЛЛИН нәкъ менә шул картиналарга карап сокланган һәм аларның берничәсен фоторәсемгә дә алган. «Гариф абыйның рәсем ясавын белми идем. Менә, башкалар да белсеннәр, махсус төшердем әле», — диде ул.

● Маляр булып эшләгән чаклар. Август, 1950.





● «Җимерелгән бастион»
● «Туган авыл».

Тимерханның авыл юллары

(Шул исемдәге документаль хикәяттән өзек)

Гариф АХУНОВ

«Карга карганың күзен чукымый»

Баш өстендә кояш балкып торганда, зәңгәр күктә сабан тургайлары сайраганда авыл юлларыннан йөрүе рәхәт, бик рәхәт. Ләкин гел җәй булмый, гел кояш кына балкып тормый шул. Бәйләнчек салкын яңгырлары белән көз килә, күз ачмаслык бураннары белән синең өскә кыш ябырыла.

Кыш ябырылу бер хәл — синең өскә күңелсезлекләр ябырылса, эшең харап була.

Мөслим районының авыл хуҗалыгы бүлегендә инструктор-бухгалтер чагында күңелсезлекләр аз булмады. Урлау, әрәм-шәрәм итү, малын үзләштерү кебек тайгак хәлләрне күргән чагында җаннары гасабилана иде Тимерханның. Райбашкарма рәисенең урынбасары белән киңәшеп, ул бер колхоздагы урлау-үзләштерү фактын прокуратурага тапшырды.

Район прокуроры Исрафилов аны якты йөз белән кабул итте. Тимерхан язып алып килгән актны укыган чакта аның күперенке кара мыегы гел дерелдәп торды. Димәк, җинаятькә ул битараф түгел. Җинаять аны да гасабилайдыра.

Актны укып бетергәч, Исрафилов урыныннан торды, читлеккә ябылган арыслан кебек, ишекле-түрле чаба башлады.

— Кара син аларны, мошенникларны, колхоз милкенә кул сузалар диген, ә?! Без аларны, безме аларны... сагайский биетербез! — Исрафилов ике кулының да бармакларын җәеп, баш өстенә күтәрде, шапылдатып, учын-учка куйды. — Күрәсеңме моны, Борһанов?

Тимерхан күрде: аркылы-торкылы куелган бармаклардан рәшәткә ясалган иде. Төрмә! Прокурор колхоз мөлкәтенә кул сузучыларны төрмәдә черетәчәк.

Тимерхан җинаятьчеләрнең җәза алачакларын хәтфәне Миңлеасиягә сөйләп бирде. Хатыны кул гына селекте.

— Нигә селтәнәсең? — диде Тимерхан, ачуы килеп.

— Юк белән йөрисең, — дип Миңлеасия самавырга нарат күркәсе сала башлады, иренә чәй кайнатып эчертергә кирәк иде.

— Туктале, җан кисәгем. Нигә дип син «юк белән йөрисең» дидең әле?

— Слушай, Борһанов! Әйт әле миңа, кайчан соң синең карга карганың күзен чукыганын күргәнең бар?

Гомер буе гаделлек ягында торган Тимерхан Борһановка бу сүзләрне ишетү гаҗәплек иде, әмма хатынының хаклы икәнен белгәч, ул тагын да ныграк гаҗәпләнде.

Атна узды, ун көн узды, көтә-көтә көтек булып, бер ай узды. Карак рәис тә, аның белән бергә урлашкан бухгалтер да урыннарында утыралар, дөньясына төкереп тә бирмичә яшиләр. Әле Тимерханның кулыннан эш төште. Колхозларга чыгуының, болай булгач, ни мәгънәсе бар, тикшерү-барлауның кирәге юк икән ич?!

Нишләргә соң? Нишләп карарга?

Уйлый торгач, вәсвәсәләнеп йөри торгач, Тимерхан ныклы бер карарга килде. Беренчегә кереп карарга түгелме икән? Ул чагында Мөслим райкомының беренче секретаре булып Салих Искәндәров эшли иде. Тыныч табигатьле, йомыш белән килгәнне тыңлый белә. Тимерхан игътибар итте: Искәндәров урамда тук тагып, йомыш әйткәннәрне дә тыңлый, эш урынына килегез, дип борып җибәрми. Менә ул чакта, Искәндәровка керергә дигән карарга килү белән, ничектер каушап калган иде Борһанов. Әгәр ул «Ник берничә инстанция үтеп, турыдан-туры беренче секретарьга кердегез?» — дип шелтәли башласа? Ни дип җавап бирергә? Хәер, Тимерханның җавабы әзер иде. Ул бит прокурор чаклы прокурорга барды! Шулай булгач, ул бит инде үзе төсле инструкторлар белән киңәшеп йөри алмый.

«Беткән баш беткән!» — дип Тимерхан көннәрдән бер көнне Искәндәров кабинетының ишеген шакыды. Искәндәровның секретаре, сары чәчле яшь, кеңә кыз, — аның ни йомыш белән керүен белергә бик теләсә дә, кертмәскә теләсә дә, Тимерханга ана серне чишмәде.

— Безнең сүз хуҗаның үзе белән генә була ала, — диде.

Хуҗа аны кешечә кабул итте.

— Кереп бик дөрес эшләгәнсез, иптәш Борһанов. Үзем дә әле сезнең белән кара-каршы утырып сөйләшергә ниятләнеп йөри идем, — диде. — Йә, сөйләгез, ни йомыш?

Борһанов мөмкин чаклы кыска итеп йомышын әйтте.

Искәндәров, кулы белән ияген таянып, аны сүзсез генә тыңлады. Тыңлап бетергәч:

— Аңлашылды, — дип бер генә сүз әйтте.

Бәхәсләшмәде дә, җинаять кылган рәис турында сүз дә куертмады.

— Иптәш Борһанов, шәхси йомышыгыз бармы миңа? — диде.

Тимерхан аптырап калды.

— Юк... — диде ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.

Шәхси йомышы бар иде аның. Аларның фатир яклары бик кысен иде. Кеше өстендә яшиләр. Өйдәш булып, дигәндәй! Ул хакта сүз кузгатсаң ярар иде дә, ләкин бит ул шәхси йомыш белән кермәде, җәмәгать эше белән керде. Хуҗаның киң күңеллелегеннән файдаланып, үз мәнфәгатен кайгырта башласа, ул ни уйламас! Әһә, дияр, тикшерү-барлау дигәне моның сылтау гына икән, керүенең төп максаты — үз тормышын көйләү өчен икән!

— Ярый, алайса, — диде Искәндәров, кул биреп саубуллашкан чакта. — Сезне миңа гадел кеше, үзе өчен тырышмый, уртак эш өчен янып йөри, дигәннәр иде, дөрес икән. Сез әле яшь кеше, сезне алда зур язмыш көтә, эшлисе эшләрегезне куркып-нитеп эшләмәгез, кыю булыгыз.

Искәндәровның үзе кабул иткән кешеләр



● Җитмештә дә җегет бемен Ахун.

хакында ике-өч җөмлә белән генә бәяләмә язу гадәте бар иде. Борһанов ишектән чыгып китүгә, ул әлеге гамәл дәфтәрен алды:

«Бүген миндә инструктор-бухгалтер Борһанов булды. Намуслы егеткә охшаган. Фатир ягын, хатынын эшкә урнаштыруны уйларга кирәк».

Тимерхан исә бу вакытта Мөслим урамы буйлап атлый һәм күңеленнән Искәндәров турында «Ул мине дөрес аңлады», — дип уйлый иде.

Район башлыгының Тимерханны дөрес аңлаган булуы эш-гамәлендә дә күренде. Ике атна чамасы вакыт узуга, карак рәис белән бухгалтерны эшеннән алдылар, беренче секретарь ул колхозга яңа кешеләрне сайлатты.

Әмма Тимерхан әлеге колхоз рәисен Мөслим урамында күреп шаккатты. Күн пәлтәдән, тубал чаклы бүре бүректән, кошовка чанага киерелеп утырып, кара туры айгырны җилләр уйнатып бара иде. Бераздан билгеле булды, Тимерхан нинди зур көч куеп урыныннан алдырткан рәис җинаятьче Мөслимнең кулланучылар җәмгыятенә эшкә урнашкан булып чыкты.

«Карга карганың күзен чукымый!» — дип Миңлеасия әйткән сүзләр исенә төште Тимерханның.

Көрәшче батырның гаебе

Илленче еллар башында колхоз уставын бозучыларга каршы кискен көрәш игълан ителде. Бәләкәй генә кимчелекне дә бик хәтәр күпертәләр, зурдан кубалар иде. Моны, бер уйласаң, акларга да була. Чөнки халык бик фәкыйрь яши, кайда ни күрә, шуны чәлдерә, колхоздан алган азык-төлеккә акча түләми, колхозныкын урлау гомумән дә урлауга саналмый башлаган иде инде.

Өлкәдә колхоз уставын үтәүне тикшерү оешмасы төзелде. Байтак еллар узган бит инде, шул дәвернең кайбер кыйпылчыклары Тимерханның күңелендә әле дә саклана. Устав бозуларны тикшерү оешмасы үз эшен бик аяусыз башкарды, шуның озакламый нәтиҗәләре дә күренде.

Сугыштан соң авылларда Сабан туе үткәрү гадәте әйләнеп кайтты. Көрәштә, чабышларда, башка төр уеннарда катнашучыларга халыктан җыелган әйберләрне бирәләр иде. Сөлге сыман нәрсәдән башка әйбер юк. Ә көрәштә җиңеп чыккан, мәйдан тоткан батырга сөлге нәрсә ул!

Шундый Мөслимгә якын гына урнашкан Катмыш дигән авылда Сабан туе батыры булып районның финанс бүлеге мөдире Павел Демидов кала, керәшен егете. Нишләргә, беренче батырга нинди бүләк бирергә? Бирер әйбер юк. Карттардан төзелгән Сабан туе комиссиясе, уйлаша торгач, баш батырга фермадагы зур бер тәкәне бирергә дигән карарга килә. Авыл кешеләре барысы да «Якты юл» колхозыннан, барысы да Павел яклы, өстәвенә үз авылларын кимсетәселәре дә килми. «Баш батырга нинди бүләк бирдегез?» — дигән чакта, «Киндер тастымал бирдек!» — дип торып булмый бит инде. Ичмасам, авыз тутырып «Тәкәнең иң зурысын сайлап бирдек!» — дияргә була.

Мәйдан батыры Демидов тәкәне җилкәсенә салып, мәйданны бер әйләнеп чыга да, шул күтәргән көе өйләренә юнәлә.

Ул чактагы законнарның гаделсезлегенә Тимерхан әле менә хәзер дә шакката. Берничә көннән райкомга Демидов өстеннән шикаять керә. Имеш, Демидов, җитәкче булуыннан файдаланып, Сабан туенда батыр кала, гади халыкка тиешле суым малын эләктерә, бер гөнаһсыз колхоз тәкәсен суеп ашый.

Шикаять райком бюросына куела. Бюро әлеге фактны колхоз милкенә кул сузу дип бәяли. Демидовны бик каты партия җәзасына тарту һәм эшеннән алу турында бюро әгъзалары ярсынып-ярсынып сөйлиләр. Искәндәров бюро әгъзаларын берничек тә уйлаган уйларыннан кире чигендерә алмый. Шул ук вакытта бюро әгъзаларына каршы япа-ялгызы гына торып кала да алмый. Демидовның язмышы аяусыз хәл ителә — чигенү юлы юк!

Демидов үзен-үзе аклау өчен әйтә:

— Хөрмәтле бюро членнары! Мин бит сарыкны урлап алмадым, хәләл көчем белән көрәшеп алдым. Хәзер инде гаебемне таныдым, көрәшкә керү кирәк булмаган икән миңа. Инде мин бик олы бер сарык сатып алып, фермага илтеп тапшырдым. Бәлки, боларны искә алырсыз, миңа карата каты җәзаны киметерсез.

Ул заманнарда ике төрле сөйләшү юк иде. Бюро әгъзалары кырт кисәләр:

— Баштарак уйларга иде аны, Демидов. Астына су кергәч, инде үкенә башладыңмыни?

Демидов башын түбән иеп бюродан чыгып китә.

Тимерхан күрде: Павелны берәү дә кызганмады, гаделлекнең үзен табарга да тырышмады, барысы да үзләрен ак көрәннән дә гөзрәк дип саныйлар, барысы да гаделлек өчен көрәшәбез дип күкрәк сугалар иде.

Ярый әле Павелның бәхетенә — хатынының бертуганы кайсыдыр бер өлкәдә җитәкче эштә эшли икән. Ул махсус самолет җибәртеп, Демидовны һәм аның гаиләсен алдыртып, эшкә урнаштыра.

Күкрәк суга-суга ярсынган бюро чаклы бюроны бер җитәкче шул рәвешле төп башына утыртты да куйды. Ярсыну шаукымына бирелгән райком бюросы финанс өлкәсен биш бармагы кебек белгән затлы бер хезмәткәреннән колак какты!

КҮЗГӘ-КҮЗ КАРАП

Язмышны

Шәхес, сәнгать, җәмгыять кебек олы төшенчәләр турында режиссер Әхтәм ЗАРИПОВ белән шагыйрь Зиннур МАНСУРОВ әңгәмә коралар.

Язмыш. Петрарка. Бирү-алу

— «Язмышыңны узыйм, дисәң — уз соң, узам, диеп кенә сөйләнмә!» Әхтәм абый, имеш, Сез шушы гыйбарәне сөйләмегездә еш кулланасыз икән. Хакмы?

— Куллануымны белмим, әмма гел ишетеп торам. илаһи бер тавыш һаман шуны кабатлый кебек.

— Ә, гомумән, язмышлардан узмыш буламы соң?

Ә нигә узарга кирәк язмышны? Узу нәрсә дә. узмау нәрсә? Узсан ни дә, узмасан ни була?

— Сәнгать хадиме булуыгызга 40 ел, ә үзегезгә 60 яшь. Шатлыкмы бу Сезнең өчен?

— Кырык ел буена иҗат эше белән шөгыльләнелгән икән, димәк, мона ихтыяҗ булган Ихтыяҗ булган икән,димәк,мин аны канәгатьләндерә алганмын. Шатлыкмы бу? Шатлансаң, һәрбер нәрсәдән шатлык табарга була. Әмма еллар саны башкарылган эш-гамәлләрдән күбрәк. һәрхәлдә. бизмән еллар ягына тарта. Чынлыкта кеше үзе эшләгәннән бик күп тапкырлар артыграк нәтиҗәләргә ирешер иде, ләкин аның көч-куәте, барыннан да бигрәк, шул эшне башкарыр өчен... рөхсәт алуга сарыф ителә. Мондый хәл үз гадәтләрен каныбызга сеңдергән системаның бер үзенчәлекле ягы иде. Зинһар өчен ялгыш аңлый күрмәгез. «Мин күбрәк тә эшләгән булыр идем, әмма ирек бирмәделәр», — дип, кайберәүләр кебек булдыксызлыкка сылтау эзләп мактанырга теләмим. Әгәр кеше бар көченә эшли алмаган икән, мона ул ин элек үзе гаепле. Димәк, эшен оештыра белмәгән. Димәк, ул үз хезмәтенең мөһимлеген кемнәрдер каршында куя да, күтәрә дә алмаган. Һәркемнең язмышы. асылда, үз кулында. Шуңа күрә мин 40 еллык хезмәтемә бәһа куйганда: «Их, таләпчәнрәк буласы калган! Күндәмлек — сәнгатьнең, иҗатның көндәше икән!» — диясем килә.

— Әгәр сәнгатьтәге юлыгызны кабат башлау мөмкинлеге булса, үзегезгә «корал» рәвешендә нәрсәләрне алып, нәрсәләрдән азат булыр идегез? Әйтик, күндәмлекне кире кагуыгыз турында әйттегез инде...

— Урыны белән күндәмлек тә кирәк. Мин аны холык-фигыльнең нигезе итүдән һәм итүчедән куркам. «Нәрсәне алыр идең?» дигәндә, тормышта барысы да фарыз. Иҗатта да шулайдыр. Ничек инде ачу-нәфрәтсез. үпкәләү-рәнҗүсез, тәкәбберлек-горурланусыз кеше булсын?! Барысына да ия бул! Шушы әйтелгәннәрнең кайсы да булса берсе холкыңда хакимлек итсә, бу инде, әлбәттә, начар күренеш. Чама белән генә булганда көнләшү дә кирәк. чөнки ул ярышу тойгысын уята. Ә ярышу исә алга этәрүче бер әмәл ич ул!

Тәкәбберлек түбәнсенүдән саклаca. түбәнчелек тәкәбберлектән саклый. Әмма инде кемдер гел түбәнсенеп. гел түбәнчелек күрсәтеп йөри икән. бу бәндәдән дә тәкәббер кеше юк: ул тәкәбберлеген яшерә генә. яисә аны күрсәтергә генә курка.

Әйе, мин «яңадан башланган иҗат юлы»ма чыкканда кешенең холык-фигылендә ни бар — барысын да үзем белән алыр идем. Үзендә булган кайсы «кораллар» белән эш итә — кешенең кешелеген шулар билгели Мәсәлән, көнчелек колы булган кеше өчен башкаларның уңышы. башкаларның бәхете — бәхетсезлек. Гадәттә. андыйларның бөтен уй-гамәле шул бәхетсезлекне җиңүгә юнәлгән була.

Кыскасы, болганчык су эчәргә яраксыз булган кебек. иң саф. дистилляцияләнгән су да эчәргә ярамый. Кешеләр дә шулай ук: «дистилляцияләнгән» кешеләр иҗатка гына түгел. яшәүгә дә яраксызлардыр.

Заман сулышын тойган. шул һаваны сулаган, чордашлары белән бергә михнәт һәм рәхәтлекләр кичергән кеше генә алар турында һәм аларга нидер әйтә аладыр, минемчә.

— Әгәр замандашлары аны аңламаса һәм аннан берни дә көтмәсә?

— Иҗат кешесенең бөтен хезмәте замандашлары белән аңлашуга юнәлгән. Аңлашырга һәм үзенчә үзгәртергә! Чордашлары аңламаган иҗатчы — иҗатчы түгел. һәм аның киләчәге дә булмый.

— Алай дисәң, күренекле бик күп шәхесләрне замандашлары аңламаган, ә бүген исә алар — классиклар.

Бу очракта: «Туры әйткән — туганына ярамаган». дигән мәкальне кулланырга кирәктер. бәлки Аннары... Кайсы гына классикны алып карасак та (сәнгатьнең һәр төрендә), ул үз дәверендә яналык алып килүче. ягъни новатор булган. Яналык беркайчан да һәм беркайда да көрәшсез генә үзенә урын ала алмаган.

Петрарку короновали. Завистников было предостаточно. Одни громко выражали недовольство, другие пожимали плечами. утверждая. что ныне вообще нет поэтов, достойных такой славы и таких почестей. Они были в те времена, когда жили Вергилий. Гораций, Овидий.

«Как было. так и будет, — отвечал на это. Петрарка и за себя, и за всех поэтов. которые когда-либо появятся на свете и будут удостоены награды. — вечно одно и тоже: древним временам сопутствует слава, а нынешним — зависть».

— Мактаулы исемнәр, дәрәҗәләр, бүләкләр... Кирәкме алар иҗатчыга?

— Кирәк булмаса, уйлап чыгармаслар иде.

— Кем уйлап чыгарган соң аларны?

— Бирүчеләр.

— Сез — алучылар рәтеннән. Тиешлесен алдым, дип саныйсызмы?

— Тиешлеме, тиешсезме — бирүче билгели.

— Бирүчеләр һәрчак хаклымы, ялгышмыйлармы алар?

— Һәрвакыт хаклы. Алар беркайчан да ялгышмыйлар.

— Шулай уйлап, сез һәм без, алучылар, ялгышабыздыр, бәлки?

— Моңа мин бер сүз белән генә җавап бирә алмыйм. Сүзем озынга китсә — бүләрсез. Бирүчеләрнең күбесе холык-фигыльләре белән бер-берләренә нык охшаса һәм омтылышлары да бер генә юнәлештә булса, алучылар, киресенчә, бик күп төрле. Күп төрле, әмма аларны да төп ике төркемгә бүләргә мөмкин: а) үз эшләренең осталары, б) кәсепчеләр.

Кәсепче үз иҗатында чынбарлыкны — дөньяны бизәп (бозып) чагылдырса, оста исә булганынча күрсәтергә тырыша. Кәсепче нинди генә бинИһая эш башкармасын, аның мәгънәсе игътибарга алынмаслык кечкенә була. останың кечкенә генә эшендә дә заманның каршылыклы зур мәгънәсе чагыла. Шул рәвешле оста киләчәккә хезмәт итә.

Кәсепче тормыштан ни таба һәм ни ала? Әлбәттә, үзенә кирәкне! Үзе корган корамасы җимерелмәслек фактлар гына кирәк аңа. Оста да тормыштан бары тик үзенә кирәкне генә эзли, ләкин аңа һәрнәрсә чынбарлыкның үзенә хаҗәт күләмдә кирәк.

Кәсепчеләр өчен бирүчеләр бирә торган һәр нәрсә. аның тормыш-яшәеш конструкциясендә терәк булса. осталар өчен — бер очраклы буяу-бизәлеш кенә. Оста ясаган нәрсәләрнең гомерләр узу белән буявы купса да. асылы үзгәрешсез саклана. Үзләре дә шулай ук — алганнарын җуйган очракта да җисемнәре шул ук кала. Хәтерегездәме икән. Пастернакның бернәрсәсен дә калдырмый алып бетерделәр — Пастернак тагын да бөегрәк затка әверелде! Әйтерсең лә тутык-юшкыннардан чистарттылар!

Күрәбез, «бирүчеләр һәм алучылар» мәсьәләсенә үзенә күрә бик катлаулы фәлсәфә салынган.

— Әхтәм абый, сүзегезне ефәк бау белән бүлеп әйтим әле: Сез бу мәсьәләдән чишелмәслек олы проблемалар ясыйсыз түгелме?

— Проблема-мәсьәләләрне чишүгә караганда, аларны табу һәм куя белү мөһимрәк. Чөнки беренчесенә бары тик мәсьәләне чишә белү хәйләсе яисә формула гына кирәк булса, икенчесенә, хыял-акыл-уйлану зарур. Мин үземне хыялый дип исәплим. Ләкин күп вакытны һәм көчне тән асрау өчен көрәш ашый. Хәер, бу каһәрләнгән заманда миндәйләрнең күпчелеге тәшкил итүен белгәч, алай артык көяләнмим дә.

Уен. Власть. Гумус катламы

— Әйдәгез әле, мөмкин булса, иҗат турында тәфсилләбрәк сөйләшик. Сезнең эшчәнлектә нинди принциплар өстенлек итә?

— Тамашачы синнән-миннән һәрчак акыллырак. Шуңа күрә, бөтен нәрсәне әйтеп, аңлатып бетермәскә, гомән-хыялга, уйланырга — ачышка, табышларга мөмкинлекне иркенрәк калдырырга кирәк. Яшәсен кинаяле сөйләм, кинаяле уен!

— Ягъни мәсәл теле?

— Хикмәт сүздә түгел, сүз артындагы мәгънәдә, тел төбендә... Сүзе берәү — мәгънәсе меңәү! Сүзгә һәркем үзенчә мәгънә сала.

— Иҗат юлыгызда төрле киртәләр дә, сикәлтә-чалулар да, ялгышулар да булгандыр. Үзегез таныган кайбер хаталарны атап үтә аласызмы?

— Хата табу хакыйкать табудан күпкә җиңелрәк. Гомер буе һәрнәрсәдән мәгънә эзлим — ялгышсам да, хаталансам да мәсләк-юнәлешем шуннан гыйбарәт. Ихтимал, хаталанамдыр.

— Сез үзегезне көрәшче итеп беләсезме?

— Ихтимал. уенчыдыр. Чөнки мин күп чак җиңү түгел, отыш телим. Хәтта җиңелү бәрабәренә дә отып була ич! Аннары шунысы да мөһим: гадәттә отыш — кан-яшьсез. үлем-төшемсез була...

— Отарыгызны алдан күрәсезме?

— Күзләрем әйбәт күрсә дә, алдан күрүчәнлегем дә, күрәзәлегем дә юк.

— Шулай да, отышларыгыз күпме, әллә оттырышларыгызмы?

— «Оттым», дип шапырыну киләчәк өчен бик зыянлы булса, «оттырдым», дип уйлау киләчәк өчен дә, бүгенге көн өчен дә куркыныч.

— Көрәшләрегездә, үзегезчә әйткәндә, уеннарыгызда Сез ялгызмы, әллә дусларыгызга таянасызмы?

— Кем соң ул дуслар?

— Әйтик, Сезне һәрчак яклаучы якыннарыгыз...

— Андый дусларым юк.

— Кызганыч. Җырда да бар ич: «Дус-иш кирәк гомер итәргә...»

— Ни өчен кирәк?

— Ник, дип, дуслык һәр җирдә мактала ич. Халык әйтмешли, дусы күп кеше дала кебек киң, дусы юк кеше уч төбе генә. Ә ялгызлыкны, гомумән, яман нәрсә, диләр бит.

— ... Ялгызлык иҗат кешесе өчен төп яшәү шарты. бәла дә түгел, каза да түгел — норма.

— Шулай да, һәркемнең ышанычлы бер кешесе, дусты, ахирәте булырга тиеш. Бу — бәхәссез.

— Мин хакыйкатьне тапкан кешегә түгел; аны эзләүчегә ышанам һәм иярәм. Минем чын дустым, мөгаен, эзләнүчедер.

— Тәгаенрәк әйткәндә, кем ул?

— Алар күпләр.

— Сез... йә бик сак кеше, йә...

— Куркам.

— Куркаклык та мактала торганнардан түгел бит, абзый?

— Куркынычны тоя белеп сагаю — куркаклык түгелдер ул.

— Шулай да, Сезне нәрсә куркыта? Сезнең өчен бүген ни куркыныч нәрсә?

— Бернәрсәдән дә һәм беркемнән дә курыкмаучы! Андыйлар өчен ата да юк, ана да юк, Алла да, закон да...

— Әхтәм абый, инде күпме сөйләшеп утырабыз, власть-хакимият, түрәләр турында, законнар хакында бер сүз дә әйтмисез. Сәбәбе?

— Ә мин тагы гел шулар турында гына сөйләшәбез дип утырам. Нәрсә әйтим икән өстәп?

— Бу җәһәттән элек ничек иде дә, хәзер ничек?

узып буламы?

— Кем?

— **Власть...**

— Элек власть тормыштан мөмкин булганны бушлай алырга юл куйса, хәзер властьны кулдан ычкындырмас өчен акча эшләргә мөмкинлек бирә. Әлбәттә, властьте булганнарга ..

— **Акчаңы күп эшлисезме соң?**

— Зиннур туган, безнең власть кыялдагы геройлар өстеннән хакимлек итүдән башкага ярамый ич. Алары да буйсынмый әле, үз тормышлары, үз логикалары белән яшиләр. Шулай булгач, элекке белән хәзерге арасында минем өчен әллә ни аерма юк. Юкны югалтып булмаган кук, югалмаганны табып та булмый.

— **Аерма күрмәү — күзләрнең томанлана баруыннан түгелме?**

Һәртөрле иҗатның төп этәргеч көче — тормышта булганнар белән генә канәгать булмау. Уйлап табучы механик, мәсәлән, үзенә кадәр булган механизмнардан канәгать түгел, шуна күрә, яңа җайланмалар уйлап чыгара, аларны тормышка ашыра. Галимнәрге исә гамәлдәге теорияләр генә җитми – яңаларын ачалар.

Чынбарлыктан канәгать булмаган тынгысыз, борчулы, эзләнүчән шәхесләр теләсә нинди системада да күндәмлеккә иялөнергә теләмиләр. Аларның коршы, уен кагыйдәләре генә үзгәрә.

Күп җигелгән күндәм алаша белән җир сөрү, тирес түгү җайлырак, әмма бәйгеләрдә печелмәгән юргаклар яисә колынламаган биаләр беренчелекне ала. Без үзебез, шәхсән, бәйге-чабыш атларын түгел, эш атларын якынрак күрәбез. Парадокс. Ниһәл итәсең.

— **Эш атлары — шул үзегез әйткән алашалар бит инде ул. Ә, гомумән, эш атлары күбрәк түгелме? Ир даньин ат күтәрсә, ил даны — ирләр кулында...**

— Җирнең уңдырышлылыгы гумус катламының калынлыгыннан килә. Җәмгыятьнең үсеше һәм тәрәккыяте дә аның гумус катламына бәйле. Җәмгыятебездә ул, кызганыч ки, гел юкару-бетүгә бара. Большевиклар революциясе иң яхшы нәсел шәхесләребезнең бер дулкынын үзенә йотса, утызынчы еллары колхозлашу шаукымы икенче дулкынын, шәхес культы репрессияләре өченче дулкынын, 1941-45 еллардагы Ватан сугышы үзе генә күпме асыл затларыбызны тартып алды. Аннан соңгы чорлар да яшәр һәм үсәр өчен халкыбызга җайлы бишек, теплица булмады. Һәрдаим сыгылса да, кавемебез сынмады. Тамырлары тирәндә, күрәсең, туфрагы тотрыклы. Ягъни, кирәк чакта бәйгеләргә чыгарлык юртакларыбыз житәрлек. Тормышны эш атлары тәзи, юртаклар бизи.

— **Бирсен Ходай.**

Бирмәсә, мәсьәләне шулай куярга кирәк, бирүче тәкать таба алмаслык булсын.

— **Сизеп торам, мәгыйшәт сәфәрендә байтак хаксызлыкларга очрагансыз. Әйтсәгезче: Сез үпкәчелме, үчле кешеме?**

— Үпкәчеллек — начар гадәт. Ул кешене кимсетә. Әмма хаксызга рәнҗетелгәндә ачу килә һәм күп очракта җавапсыз калу бик читен була. Бер яңагына суккач, икенчесен куеп торучыларны өнәмим.

Кеше үзен үзе хөрмәт итмәсә, башкаларга да гел кимсетеп карый. Кешеләргә хөрмәт үз шәхесеңне кимсетмәүдән һәм кимсеттермәүдән башланадыр.

— **Тыйнаклык — кеше шәхесен олы итүче сыйфатларның берсе. Үзегезне «тыйнак» дип атый аласызмы?**

Әгәр тыйнаклыкны тыелуның шәхестәге чагылышы итеп кенә карасак, мин мондый тыйнаклыкка каршы. «Әрле әрләнгәнче, әрсез ашап туйган», диләр. Бездә әдәп-әхлак кагыйдәләре нык җимерелгән, ә яңалары әле тамыр ныгытмаган. Шуңа күрә, хакыйкатькә бару-килү юлында киртә булырдай тыйнаклыкны кабул итә алмыйм.

— **Сезнең остазларыгыз, укытучы-хәлфәләрегез кемнәр?**

Әткәй, әнкәй, күршеләр, авылдашлар... тормышымда очраган һәркем! Инде кемне үземә үрнәк итеп алам, дигәндә, миңа Александр Довженко иҗаты якын. Мин әлеге шәхес алдында баш иям. Бигрәк тә аның куярга әзерләнгән, әмма төшерә алмый калган фильмнары өстендә эшләве гыйбрәтле. Аннары Василий Шукшин. Әйе, әйе, «остазым», дип әйтер өчен аның кул астында өйрәнү узу мәҗбүри түгел.

Шулай да «укытучы» төшенчәсен аңларга ярдәм иткән беренче шәхес Гомәр абзый Калинин — Минзәлә театрының үзенчәлекле бер өлкән артисты булды.

«Шәхес, — диде ул, — колларча «Ни боерасыз?» дигән таякка таянмый, ә тәвәккәлләп «Мин үзем!» — дигәннән башлана».

Нәкъ менә шушы хәлдән соң «Мин үзем! Һәр кайда, һәр эштә — мин үзем!» чоры башланды, дисәм, бераз ялгышрак булыр, әмма ялган килеп чыкмас.

- «Җанының ваклыгын сылтама заманга!»

— **Әхтәм абый? Шулай да, әгәр сайлау мөмкинлеге булса, кайсы заманда иҗат итәр идегез: киләчәктәме, әллә узганындамы? Ни өчен?**

— Ата-ананны, туган илеңне сайлап алып булмаган кебек. Вакыт та безнең ихтыярда түгел. сайлатмый. Бары тик аны ничек кичү генә күпмедер дәрәҗәдә безгә бәйле.

— **Сезнең өчен иҗат процессы кайчан башлана? Кулга сценарий килеп кергәчме? Тормыш агышында берәр проблема тотып алынгачмы? Пәкләмә билгеләнгәчме?**

— Гомумән, бу мәсьәләгә минем карашым мондыйрак. «иҗат процессы башланды», «иҗат процессы тукталды», дип сөйләшү бөтенләй дөрес түгел. Иҗат процессы йә бар ул, йә юк. Бар икән — ул тукталмый, кеше исән чакта һаман дәвам итә. Аның башланышын да «фәләненче числода башланды», дип тәгаен күрсәтеп булмый.

Бәлкем, сөйләшүне тегеге яки бу спектакль концепциясенең туу ясалышына күчерергәдер? Алай дисәң, теләсә кайсы спектакльнең концепциясе үзең хезмәт иткән тамашачы мохитендә яши. Безнең бурыч шуны үз вакытында тотып ала белү, тамашачы белән шул концепция арасында илче-тылмач булудан гыйбарәт. Яхшы әсәр чын җәүһәр кебек бит ул: кай яклап һәм ничек яктыртасың. Ул зәңгәр дә булып күренә, яшел дә, кызыл да... Аны кайчан, нинди итеп күрсәтү режиссерлар, артистлар, рәссамнар кулында.

Үземә килгәндә, мин менә ирештем, дип әйтә алмыйм.

— **Китегез инде... Бу ялган тыйнаклык түгелме?**

Түгел! Чөнки һәр режиссер башкарган эшен бердәнбер һәм иң бөек эш дип игълан итә алса, ни дә булса китереп чыгара ала.

— **Инде тамашачылар турында. Сез алардан канәгатьме?**

— Канәгать булсам, мин режиссер булмас та идем. Минем хезмәтем, минем иҗатым — бөтен дөньяны кешеләрне (димәк, тамашачыларны) үзем теләгән юнәлештә яхшылыкка таба үзгәртергә теләүдән башлана. Шулай булгач, мин, тамашачылардан канәгать, дип әйтә аламмы? Юк! Мин аларны яратам, ләкин кешеләрдәге кимчелекләрне күрмичә, аларга каршы көрәшмичә дә булдыра алмыйм.

— **Режиссер кем ул?**

- Инану! Позиция! Принциплар (мораль, эстетик, рухи)..

— **Ә талант?**

- Талантның бер канаты — кыюлык, тәвәккәллек! Талант куркак була алмый. Талант — максатка юнәлгән чаялык! Талант — намус һәм вөҗдан!

— **Тормышыгыз һәм иҗатыгызда нәрсәгә таяну Сезгә көч бирә?**

Гаҗәеп хәл: кайчак хәтергә таянам, кайчак тиз опытка алуыма.

— **Нәрсәдән, кемнәрдән куркасыз?**

- Тиз үзгәрүчеләрдән, кичә үзенең ипташен «кулак малае», дип кимсеткән кешенең бүген «кулак малае мин», дип күкрәк сугуыннан, кичәге дәһринең бүген, түбәтәй киеп, намазга йөрүеннән.

— **Сезнең спектакльләр өчен иң зур мактау?**

- Әгәр дә тегеге яки бу спектакльнән соң бәхәс купса..

— **Менә сез 40 ел дәвамында театр сәнгатенә, телевидениегә хезмәт итәсез...**

Мин халыкка хезмәт итәм.

— **Авырмы?**

Сәнгать дөньясына керү үзе бик авыр эш. Анда яшәү, анда хезмәт итү тагы да читенрәк. ә инде сәнгать дөньясында озакка, мәңгелеккә калу бик сирәкләргә өлешенә генә тия торган язмыштыр.

— **Каласыгыз киләме?**

- Шулай булмаса, яшәүдән ни мәгънә?

— **Сезне нәрсә үрти? Нәрсәләргә ачуыгыз чыга?**

- Бездә шулай куелган сүз, вәгъдәләр — елганың бер ярында, эш-гамәл, нәтиҗәләр елганың икенче ярында.

— **Үзегез куйган кайсы спектаклегезне уңышлы дип әйтер идегез?**

«Уңышлы булды» дигән билгеләмәне, минемчә, очраклы, көтелмәгән хәлләрдә генә кулланырга ярыйдыр. Әйтик, урманга утынга барасың. Агач кискәндә, гөмбә табасың. Шулкадәр күп, уйламаган, көтмәгән җирдә кул астында булган барлык савытлар тула. Хәтта утын арасына, машина әрҗәсенә дә гөмбә тутырырга туры килә. Менә моны, әлбәттә, уңышлы сәфәр дип әйтергә була. Очраклы табыш, ләкин дөньяда булмас гайре-табигый эш түгел.

Спектакль турында сүз алып барганда, бәлкем, аларның кайсысы көткән нәтиҗәне бирүе, кайсысы көтелмәгән нәтиҗәләр китереп чыгаруы турында гына сөйләшергә кирәктер. Ихлас әйткәндә, бер спектакль дә уйлаганча булып чыкмый. Режиссер хезмәте, бер яктан, компромисска бармаудан, үз дигәненә тулысынча ирешүгә омтылудан башланса да, икенче яктан карaганда, гел килешүләрдән генә тора сыман.

«Кайсы спектакльдән соң тамашачы хатлары күбрәк килде?» дип сораганда, хатлар саны да куелышның сыйфаты хакында сөйләми. Әгәр спектакльдән соң, инде әйтә күрем
немчә, тамашачылар арасында бәхәс купса — моны мин теләккә ирешүдә бер адым дип карар идем. Әмма һич тә «уңыш» итеп түгел... Уңыш — очраклылык җимеше ул.

(Ахыры 12 нче биттә).



● Әхтәм ЗАРИПОВ: «Ә нигә узарга кирәк соң язмышны?»

Заман. Тамашачы. Очраклылык җимеше

— Заман мәсьәләләренә кереп киткәндә, хәзер күпләребез заманны сүгүдән сүз башлый...

Язмышны узып буламы?

(Ахыры. Башы 10 — 11 нче битләрдә).

Кораб. Тау.
Алмаш кәчтүм

— Әхтәм абый, көндәлек матбугат битләрендә чыккан тәнкыйть сүзләренә Сезнең карашыгыз ничек?

— Төрлечә инде: шатландыргапнары да, көендергәннәре дә булгалады. Нигездә, һәр мәкаләне мин аны язган кешенең теге яки бу мәсьәләгә шәхси карашы дип кабул итәм. Хәтта ул язманың язылуында яшерен сәбәпләр булса да. Кайбер мәкаләләр хакыйкатьнең соңгы баскычы булуга дәгъва рәвешендә языла. Боларга мин, әлбәттә, каршы позициядә.

Мин — юлчы. Кая барырга, кайда туктарга кирәклеген мин үзем хәл итәм. Миңа маршрут та, расписание дә кирәкми. Үземнең иҗат корабымда мин капитан да, лоцман да, ишкәкче дә. Адашып, комга утырган, ташларга бәрелеп, көймәм тишелгән чакларда да башкаларга үпкәләмим. Үз юлым, үз тирәнлегем, үз тизлегем, үз комфортым. Мин үзем маршрутлар тәкъдим итәм ич! Теләге булган кешене үз корабыма чакырам: «Рәхим итегез — пәкъ менә шушы юл бәхеткә илтә!» дим.Ә утыру, утырмау — алар ихтыярында.

— Чынга әверелмәгән проектларыгыз күпме?

— Гамәлгә ашмаган проектлар турында сүз дә алып барылырга тиеш түгел, минемчә. Димәк, ул проектлыктан узмаган, димәк, аның кирәге дә булмаган. Ә тормышка ашканнары турында... Әллә алары да юкмы соң?! Күрәсең, күпчелек уй-теләкләр өлешчә генә чынга аша. Хыял чынбарлыктан баерак.

— Бераз гына фараз итеп алырга иде: иртәгә без нинди булачакбыз?

— Кичә нинди булуыбызны онытсакмы? Тагын агач башына менәр идек, әмма бездә банан үсми. Бер генә юл кала: кичә кем булуыбызны бүген онытмыйча, иртәгәге көнгә әзерләнергә...

— Ә иртәгә?

— Ә иртәгә миңа 61 яшь...

— Карап-карап торам: Сезнең алты дистәгез тормыш тәҗрибәсеннән чын фәлсәфә корырга бик кулай вакыт икән. Инде яшәргә өйрәнеп беткәнсез бугай. Хәерле булсын, котлыйбыз!

Рәхмәт

— Ничек уйлыйсыз: безнең бу сөйләшү артык минорный булып чыкмадымы? Әңгәмәбезнең ахырында бераз шаярып алу, уен-көлке кирәкмиме?

Нишлим? Холкым шундый булгач. кеше көлгәннән кызык тапмагач...

— Профессиягезне биек бер тау дип карасак, сез хәзер шушы тауның кайсы өлешендә? Уртасындамы, түбәсендәме?

— Итәгендә. Мин аңа үзем менүгә караганда, башкаларның күтәрелүен артыграк күрәм. Шуңа менәргә юллар сызам.

— Ышандырмадыгыз. Сәнгатькә гомерен багышлаган иҗат әһеле шөһрәт яратмасын, имеш.

— Мин алай әйтмәдем.

— Тауга менәргә кызыкмыйм, дидегез ич!

— Чынлыкта иң биек тау түбәләренә кәлтә еланнар да менә икән, ә без аңа бары тик бөркетләр генә күтәрелә ала, дип уйлыйбыз.

— Шулай килеп чыга: Сез үзегезне бөркеткә, ә кемнәрнедер кәлтә еланга тиңлисез шикелле.

— Тагын кабатлап әйтәм: тауларны яратсам да, үзем аңа күтәрелүгә караганда тау түбәсендә башкаларның дөньяны, тормышны, тарихны тамаша кылуын өстенрәк күрәм.

— Имеш, Сез тау итәгендә гомерегез буе тавык кебек тырмашырга тиешме?! Ә икенче берәү — әйтик, карга, саескан, әтәч — Сез тырмашып гайканны ашап, тау түбәсенә күтәрелергә тиешме? Ышанасы килми.

— Бөркетләр тавыклардан да түбәнгәрәк төшәргә мөмкин, әмма тавык халкы беркайчан да болытларга кадәр күтәрелә алмый бугай. Ышандыра алмавым — минем гомерлек юлдашым.

— Сезне аңлау авыр.

— Кайчак мин үземне үзем дә аңламыйм. Минем эшем, хезмәтем, иҗатым аңлашылырга тиеш, шатлык китерергә тиеш. Шунда гына үзем хакында яшәдем, иҗат иттем, дип әйтә алам. Ә хәзергә без тау итәгендә, яңа бикләкләр эзлибез, күтәрелер өчен юллар салабыз һәм үзебезне кешеләрдән ким-хур күрмибез. Мин риза-бәхил.

— Теләкләрегез?

— Корылык булса, яңгыр телим, яңгырлар күпкә китсә — кояшлы көннәр...

— Барыбыз да шулай.

Минем башкаларныкыннан артык теләгем юктыр: 60 яшем тулуга алмаш кәчтүм алсаң иде, кышка туп тектергәндә дә зыян итмәс иде, бала-чагалардан аерылып, карчыгым белән генә яшәсәң иде...

— Теләкләрегез кабул булсын, Әхтәм абый!

Амин! Инде сезгә үтенечем шул: әгәр бу әңгәмәне бастырып чыгарасыз икән — шомартмагыз. Ничек бар — шулай. Аннары «Юбилей мөнәсәбәте илә» минпән каһарман эшләргә дә матамагыз. Юкны бар итеп булмый ул. Юнылган агачтан багана килеп чыккан кебек, мине дөресләбез дип, агач ясамагыз тагын. Кеше каршылык һәм кимчелекләре белән кызыклырак.

Без — замана балалары

АСЫЛЫБЫЗГА КАЙТЫП БАРЫШЛЫЙ

Рухыбызның аумас манарасы

1990 елның 26 сентябрендә алтын төрле чиркәүләр арасында моңаеп утырган мәһабәт Сөембикә манарасына алтын ай куелды. Татар милләтенең ачы һәм гыйбрәтле тарихын гәүдәләндергән әлеге гүзәл архитектура һәйкәле безнең һәркайсыбыз өчен якын, кадерле.

Бу изге эштә Татарстан Республикасы мәдәнияят министрлыгы төзелеш буенча урынбасары Габбас МӨХӘММӘТШИН аеруча зур тырышлык куйды. 26 сентябрьдә Сөембикә манарасына ярымай куелуга 5 ел тула. Шул уңайдан безнең хәбәрчебез Габбас әфәндегә берничә сорау белән мөрәҗәгать итте.

— Габбас әфәнде, Сөембикә манарасына ай кую тарихы турында берничә сүз әйтсәгез иде?

— Мәгълүм булганча, әлеге сөенечле вакыйга Татарстан Республикасы дәүләт мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул иткән көннәргә туры килде. Дөрес, бу турыда инде күптән сүзләр бара иде. Ул елны матбугат битләрендә Сөембикә манарасына урак белән чүкеч, ике башлы каракош, йолдыз янәә аждаһа куярга кирәк, дигән фикерләр дә әйтелде. Хәтта аерым татар маңкортлары арасында татарда аждаһа символы булганны раслауга кадәр барып житүчеләр булды. Ләкин тарихчылар, галимнәр һәм җәмәгатьчелек боларның барысына да каршы чыкты. Ник дигәндә, Сөембикә манарасы татар халкы тарихына карый. Без — мөселманнар. Ә Ислам дине кеше һәм хайван сурәтләрен ясауны тыя. Шулай булгач, бездә аждаһа символы булган, дип әйтү ахмаклык ул.

Менә шулай бәхәсләшә, фикер алыша, уйлаша торгач, без ярымайда тукталырга булдык.

— Хәтерем ялгышмаса, Сез ярымайны «Вакууммаш» фәнни-житештерү берләшмәсенең Казан механика заводында ясаттыгыз бугай?

— Әйе, эштә безгә шул заводның цех начальнигы Шамил Сәфәров һәм бер төркем эшчеләр ярдәм күрсәтте. Ай шактый саллы килеп чыкты. Диаметрының зурлыгы — 1 мең 200 миллиметр. Форсаттан файдаланып, Сөембикә манарасын төзекләндергән һәм аңа ай кую эшен башкарган махсус фәнни-реставрация идарәсенең участок начальнигы А.Костина, бизәүче-шомартучы Х.Галиева, Е.Викторова, Г.Якимова, Н.Хәсәнова, ташчылар Н.Христофоров, В.Куликов, балта остасы Х.Бикмуллин, монтажчылар Коклюшкин, Урусовка да рәхмәт хисләремне белдерәсем килә.

— Габбас әфәнде, ярымайны манарага куйган көннәр турында тәфсилләбрәк сөйләсәгез иде?

— Беренче тапкыр без аны шул елның 23 августында көндезге сәгать 2дә куйдык. Халык бик куанды. Ләкин бу бит әле үлчәп карау гына иде. Дәүләт мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул ителүнең икенче көнендә ул алтын йөгертү өчен махсус фәнни реставрация идарәсенә озатылды. Исегездәдер, 1990 елның көзе бик яңгырлы килде. Көтәбез, көтәбез, ә яңгыр һаман туктамый. Ниһаять, тәвәккәлләп, айны 26 сентябрь көнне куярга булдык. Һәм — гаҗәп — ул көнне ялтырап кояш чыкты. Әйтерсең, Ходай үзе безгә ярдәмгә килгән. Йөзләп мөхбир, кинооператорлар җыелды. Көндезге 12 сәгать 30 минутта Сөембикә манарасында инде ярымай балкып тора иде. Тагын шунысы кызыклы, ай куелуга ук көньяктан кечкенә генә бер болыт килеп чыкты да өч тапкыр яшен яшьнәде. Үзем сәгатькә карап тордым, ләйсән яңгыр пәкъ җиде минут дәвам итте. Әлеге изге эшне башкарган кешеләрнең исемнәрен, манарага ай куюны таләп итеп, Мәдәният министрлыгына һәм редакцияләргә килгән хатларны, ярымай кую турындагы хөкүмәт карарын, «Социалистик Татарстан» газетасының 26 нчы сентябрь санының 3 данәсен, Мәрҗани мәчете бүләк иткән Коръән китабын тарихка кереп калсын дип ярымай астындагы алтын шарлар эченә салып калдырдык. Ходай кушса, бу ядкарьләр киләчәк гасырларда яшәячәк оныкларыбыз тарафыннан XX йөз ахырында аларны дәүләтле һәм мөстәкыйль иткән ерак ата-бабаларының җылы сәламе булып кабул ителер.

Гамил АФЗАЛ,

Татарстанның халык шагыйре

Тәмле төш

Кул аркасына башым куйдым да йоклыйм, төш күрәм,
Төштә дә китап, каләм, дәфтәр белән мин эш күрәм

Бер китап чыккан икән дә, мин язган төсле, имеш;
Үзе калын, үзе матур, акыллы, хисле, имеш.

Бөтен татар шау киләдер, ошбу китапны алып,
Артистлар күккә чөяләр, әй, минс мактый халык

Хәтта КГБ елмайган, беркем өркетми өреп...
Ярты сәгать ял итәм мин, төрле тәмле төш күреп

Килеп кичмешләр әхвәле

Дәрдмәндкә

Нурлы язда, яшел җәйдә, иген уңган көздә
Килеп кичмешләр әхвәлен бәян иттек без дә,
Һай, болгавыр булды еллар егерменче йөздә,
Бара-бара төшәрбез күк нык иманлы эзгә.

Заман гаделсезлеге

Бу заманда ин әшәке
Гаделсезлек барын сиздек —
Түләп алган акылсызлык,
Теләп алган бәхетсезлек...

Сәяси авантюра

Политика – пакшы нәрсә,
Кулыңны тыкма, дустым,
Җаның теләгәнчә эшлә,
Намусың чиста булсын.
Сәяси авантюристның
Алдашып жаны чыксын!

Бер диалог

– Әнә, ирек алган якты көнең.
Ничек яшәү кирәк синеңчә,
Блат, ришвәт сүзен белмичә?
— Без сөйләргә өйрәнмәдек, энем,
Трибунага менеп тормадык,
Гомер буе доклад тыңладык.

Карусызлар

Сәяхәтләрдә йөрмәдек
Миклухо Маклай кебек.
Колхоз арбасын сөйрәдек
Карусыз бахбай кебек.
Киләчәктән бәхет көтеп
Яшәргә хакым да бар;
Кычытканда витамин күп,
Юам да, какым да бар.

Арыслапдай

Бер дөрес сүз чыгып сөйләдең дә,
Ярты гомер белән түләдең,
Тәмугларны күреп исән кайттың –
Арысландай икән йөрәгең.

Күзләрем боек

Әллә кемнәрне алдады тормыш,
Утларга салды, суларга.
Кимедс дуслар, кысылды сулыш,
Күзләрем боек шуңарга.

Гомер буе ялчы

Усал тәртип әйбәт иде, улым,
Каты өмер бирде каты вылач;
Ничек итеп мин демократ булыйм,
Гомер буе ялчы булгач!

* * *

Галиябану кебек кызлар
Фәрештә сыйлы, иркәм.
Аждаһа кебек хатыннар
Кайлардан килә икән!

Тар колач

Татарга тылмач кирәкми,
Татар үзе тылмач.
Татарга да акыл керә
Йөз ел уйлап торгач.

Жырыбыз бар, моңыбыз бар,
Тар булса да колач.

Чоры шундый

Кем узардан чабып, дапцар алып,
Туры сүз әйтергә ояласың,
Йөзең чалып, елмаюың фальшь,
Кызыксынган кебек кылапасың,
Чоры шундый диеп юапасың...

Вәкилләр

Авыздан ут чәчеп, нотыклар сөйләгән
Вәкилләр жилкетте йөрәкне.
Арышны бодайдан аера белмәгән
Вәкилләр килде дә өйрәтте,
Килде дә өйрәтте...

Мәҗүсиләр

Мәҗүсиләр яңа иман тапкач,
Искеләрен жиргә күмәдер;
Агач пәйгамбәрне йолкып аткач,
Табынасы килә кемгәдер...

Хокук турында

Йомышка йөр, житәкчеңә яра,
Гәжит күшәп, чәрем иткән ара;
Синең хокук турында сүз бара —
Баш эшләтеп, фикер йөртеп кара..

Алдап эшләтү

«Халык ихтыяжы», дисең, иркәм,
Власть тирәсенә елыцканда,
Бер эшең дә алга бармый икән,
Алдап эшләтергә тырышканда.

Белми торган кеше

Гайрәтле арыслан иде белми торган кеше,
Мин сезне өйрәтәм, диде белми торган кеше:
Кәгазьгә карап сөйләде белми торган кеше,
Кәкре каенга сөяде белми торган кеше.

Оптимист

Зур оптимист, шәп оратор иде.
Яньп-көеп эшләп йөргәндә;
Соңгы юлга тып-тын китеп бара,
Бер медале бара мендәрдә.

Аяз көндә ялтырап кояшта,
Шул медале калды мираска.

Шок терапиясе

Кабат-кабат шок терапиясе
Әзерләгән безгә Егор Гайдар.
Шок хәлендә безгә көн күрәсе –
Бик хәвефле айлар....

Бер манкортка

Татарча да сөйләшә белмисең,
Сөйләшә белмисен русча да;
Ни кырырга доньяга килдең син
Кара мунчада!

Пугачевлар

Утырасың посып биек постта;
Кычкырасың: план, план, план!
Пугачевлар балта тотып чыкса,
Кая барырсың син, Юха Елан!

* * *

Урманда йөз төрле агач үсә.
Имән эргәсендә нарат тора,
Барысын да сөеп жилләр исә,
Барысы да күккә карап тора,
Илгә-көнгә сөенеп, ярап тора

* * *

Буш эшләтеп, налог белән буган,
Бакыр акча биргән бурычка,
Гомер буе безгә түрә булган
Ак урыс та, кызыл урыс та.

Укыган кеше

Укыган кеше — чукынган кеше, диц,
Кайчан сөрән салган кемнәрдер.
Укымаган кеше, трай тибеп,
Доньз көтә белми бөлгәндер.

Һәлакәтле серләр

Елгалар да юлын алыштыра,
Иске юлы аңа тар кебек;
Елга кебек заман агышында
Һәлакәтле серләр бар кебек.

Кылган гамәл

Кемгә дача, кемгә кара мунча —
Үз файдасын каерып бара Мыштым,
Беркемнең дә сүзенә карамыйча,
Кылган гамәленә кара, дустым.

Ялган белән якалашу

Әдәп саклап елмаясың уйчан гына,
Жан күтәрми ялган сүзне бер тамчы да;
Баш бирмәскә дәлил кирәк, сәбәп кирәк,
Ялган белән якалашып жаның чыга.

Гайбәт

Җилпенәсең, жилкенәсең,
Эшләрең әйбәт килә,
Үрсәләнеп үр менәсең, —
Эзеңнән гайбәт килә,
Җаныңны чәйнәп килә

Кимсенмә

Ихтирам юк танау гартып торган,
Бүрек салып торган кешегә.
Кеше күңеле — чиксез кара урман,
Мин бәләкәй, диеп кимсенмә!

* * *

Тырышып, тырмашып ятасың,
Шүредәй әйләнеп сосада —
Ичмасам, бер гүрә мактасын,
Шыр надан булса да.

* * *

Дөнья кайный, жирләр селкенәдер,
Син жырлаган моңсу айларда,
Синең жырны ишетеп жилкенәдер
Әллә кемнәр әллә кайларда ..

Лаек ялга чыккач

Алла бирер, диеп тик тормадым,
Алла бирмәсә дә тик тормам,
Арты урамнардан биш урадым,
Тик торганда шайтан готтырган ..

1993-94 еллар.

ДАҺИ ШАГЫЙРЕБЕЗ ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ 110 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП

Рабит БАТУЛЛА

Кылдан нечкә, кылычтан үткер

(Дәвамы. Башы 8 нче санда).

Исхак Бикчурины җирләргә Тукай да барды. Исән чакта Исхакның Тукай артыннан, тагын әллә кемнәр артыннан шымчы итеп ялланганын белүчеләр аптырады. Тукай, монда нишләп йөри, янәсе. Исхакның җәсәден гүргә индерергә ул да сикереп төшмәкче иде, җинелчә генә хәрәкәт белән аны бу ниятеннән туктаттылар. Каберга Габдерахман Мөрсәлим сикереп төште.

Җеназачылар таралып беткәч тә, Тукай зираттан чыкмады. Ул, ялгыз калырга теләп, ыгы-зыгы вакытында тын гына читкә китте. Максатсыз гына каберләр арасында уйланып йөрде, әйтерсен лә шагыйрь үзенә урын сайлый иде. Шулай байтак йөргәннән соң, ул кайтыр якка борылды. Зират капкасы төбендәге теләнчеләр, кулларын сузып, аннан хәер эстиләр. Ул кесәсендәге бар акчасын теләнчеләргә өләшеп бетергәч, кызурак атлап китте. Хәерчеләр сугыша-талаша артта калды, ләкин араларыннан берсе Тукай артыннан иярде. Тукайның акчасы беткән иде, ул адымын тизләтте, ләкин хәерче дә тизрәк атлый башлады. Бөкере йолкыш аны куып җитте дә:

— Мияу! — диде.

Тукай бу сәер тавышка борылып караган иде — Шәүләне танып алды.

— Пөрес, хайван! — дип кычкырды Тукай. — Сиңа клоун буласы гына калган, Шәүлә. Кырык кыяфәткә керә беләсең.

— Мин — актер! — диде Шәүлә, турая төшеп. — Мин — гений перевоплощения. Сәхнәдә әверелеш даһие мин!

Алар янәшә атлап китте. Тукай бераз алтарак чыкты, чөнки Шәүләнең янына теркелдәп баруы читтән караган кешегә хуҗасы артыннан иягән эт кебек күренгән булыр иде.

— Син зерә укымагансың, Шәүлә, — диде Тукай. — Синнән менә дигән театр белгече чыгар иде. «Актерское перевоплощение» гыйбарәсен ничек матур тәрҗемә иткәнсең: актерның сәхнәдәге әверелеше. Бәлки, алмашынышыдыр?

— Алмашынуның башка мәгънәсе бар, әфәндем, — акыллан язу.

— Ә «герой любовник»ны ничек әйтер идең?

— Мәхәббәт каһарманы!

— Дөрес бит, әй! — диде Тукай көлә-көлә. — Ә героиня?

— Мәхәббәт гүзәле!

— Афәрин! Дөрес бит. Ә безнең театр тәнкыйтьчеләре «әсәрнең төп герое, героинясы», дип авыз суын корыталар.

— Надаяннар! — диде Шәүлә теркелди-теркелди. — Әйтем исә кайттым, әверелеш сәхнәдә генә түгел, тормышта да тел булып тора ул. Сине дә зур әверелешләр көтә, Тукайҗан. Кайгы көтә сине, шагыйрь.

Тукай туктады. Шәүләнең ин башыннан умырып тотты да:

— Нинди кайгы? — дип сорады.

Шәүлә бер дә исе китмичә генә:

— Беренчесе-соңгысы түгел, кайгырма! — диде.

Тукай Шәүләне кагы итеп этеп җибәрде:

— Бәгырьсез син, Шәүлә! Кешегә кайгы килүен каркылдыйсың.

Шәүлә яңа Тукайга елышты, кесәсеннән бер төргәк газет чыгарды.

— Минем эшә бәгырь комачауламый гына ул, Тукай, — дип, ачып бөкләнгән бер газетне сүзсез генә Тукай күзләренә якын китерде.

Тукай газеттәге таныш рәсемне күреп, туктады. Газетне тартып алып, укый башлады. Уку дәвамында ул агарды, хәле китте, артка таба чигә башлады.

— Тукай! — дип кычкырды Шәүлә. — Тукай, сиңа ни булды?

Шәүлә Тукайны култыклап алып, якындагы калку җиргә утыртты.

— Кабахәт син, хәерче! — диде Тукай.

— Кабахәт, кабахәт, килешәм! Тик син егылма гына.

Тукай хәл җыйгач, тагын газеткә бакты, бераз укып карады.

— Хөсәен Ямаш вафат! — дип ыңгырашты. — Хөрмәтле Хөсәен дустыбыз үлгән... Ничек үлгән? Ни өчен?

Тукай газетне тәфсилләп укыр дәрәҗәдә түгел иде, Шәүлә, иплән кенә аның кулыннан газетне алып, салмак кына укый башлады:

«... мәшһүр революционер Хөсәен Ямашев әфәнде вафат итте. Хөсәен Ямашевның гаять серле һәм шикле шартларда вафат итүен газет идарәсе әгъзалары бәян итә. Үләргә ике минут кала мәрхүм почмактагы лавкадан бер стакан жимеш суы эчкәнлеген әйткән. Бу шикле эшне тикшерү өчен докторлар китертелде һәм жимеш суы сатучы янына тикшерүчеләр озатылды...»

Тукай инде Шәүләне тыңламый иде. Бетә, кырыла татар зыялылары. Күз алдында ничә кеше китте. Берсе дә үз үлеме белән түгел. Хәзер кем чираты? Тукайгамы, Фатихкамы? Бөҗра кысыла, тарая. Ике башлы Каракош канатларын җәя бара. Сәер үлемнәр, сәер җинаятьләр белә тулган Казан...

— Беләм мин аны, — диде Шәүлә. — Ул революционер иде.

— Уйларыма керме, Шәүлә!

— Үлгән артыннан үлеп булмый, дим... Бүген син — бар, иртәгә — юк...

— Карылдама, карачкы! — дип кычкырмакчы булган иде дә Тукай, кинәт ютәлли башлады. — Күземнән югал! Эттән туган дуңгыз баласы, син яман хәбәр белән генә йөрисең, кит!

Ләкин әрсез хәерче китмәде. Киресенчә, ул Тукайның ике култык астыннан тотып торгызды да:

— Әйдә, өйгә кайтабыз, монда салкын, җил, — диде.

Әле генә Шәүләгә нәфрәтле булган Тукайның аңа буйсынмыйча хәле юк иде. Алар икәүләп әкрен генә шәһәргә таба кузгалды.

Эттән күбәйгән дошманнар... Нишли алар? Нишли халык? Халык упкынга бара, саф тамырларга богау салалар кабахәтләр. Күпме калгандыр гомер? Шул мизгелләрне тулысы белән файдаланып калыйм, дисәң, төрле яклап изәләр. Кая барыйм? Нинди мохит бу? Кайда шат табәссемле хәят? Авыр уйлар сыгты такылымны. Агуланган тәнем җир куенына тарта. Артыма борылып карасам, сызланам. Юк майтарган эшем. Алга карыймын да үксеп җылыйм. Бетте көчем...

Зират дымтылымы, җәяү кайтканлагы салкын җил ме, әллә бер-бер артлы ишелеп төшкән кайгыларымы изде Тукайны: ул тәмам хасталанып ятакка ауды. Бер атна өзлексез ютәлләп, ашамый-эчми, саф һава суламый бүлмәдә аунаганнан соң әкренләп торып йөри башлады. Бераз рәтләнгәч Шул көннәрнең берсендә аның бүлмәсенә Зәйтүнә туташ килде. Тукай итән генә бер сөенде, бер көенде. Зәйтүнәне күрү бәхет булса, шушы зәгыйфь кыяфәттә кызлар алдында утыру читен хәл иде.

Туташ бүген аеруча гүзәл. Ул матур итеп киенгән, кулына чәчәк бәйләме тоткан.

«Гаҗәп, — дип уйлады Тукай. — кыш азагында бу тере чәчәкләрне кайдан ала икән бу туташ».

— Минем сөенчем бар! — диде туташ, Тукай каршына килеп утыргач. — Сөенчем шул: бу арада матбугатта сезнең шигырьләрегез бик еш басылды. Гаҗәп истибдатлы әсәрләр, әфәндем. Бер якта куәтле сатирагыз, шаян әсәрләрегез халыкның рухын күтәрә. Икенче якта мәхәббәт лирикагыз гаҗәеп бер омтылыш белән яшьләрнең күңеленә кереп урнаша. Алар бер укуга күңелгә сеңә.

Тукай тарсынган кыяфәттә иде, ул теләр-теләмәс кенә сүзгә кушылды:

— Сез укыйсыз, алар сезнең күңелгә хуш килә, халыкның бер өлеше шул әсәрләрем өчен мине каргый.

— Сез андыйларга игътибар итмәгез! — диде туташ. — Кизәнгәнсез икән — сугыгыз. Суккансыз икән — үкенмәгез. Кәефегез юкка шул гына сәбәп булса, ташлагыз. Сезгә курку харам...

Туташ туктады. Тукай сүзсез. Сөйләшергә яна тема кирәк иде.

— Мин атам белән анама сезнең белән һәр күрешү хакында сөйли барам, — диде туташ. — Борчылмагыз, минем алардан яшерен серем юк. Алардан сер чыкмый. Беләсезме, җәй уртасында мин сезне авылга алып китәрмен. Кызык булыр. Безнең якта кымыз да бар. Кызык та бар. Казы да бар. Кубыз да бар. Кыз да бар.

Зәйтүнә туташ яңгыратып көлә башлады. Тукай да елмая иде. Нинди самимилек. Хәтта сабыйлык дияргә була. Бу сафлыкка карап сөенмәү мөмкин түгелдер. Тукайның кәефе күтәрелә башлаганын күреп, туташ тагын да җанлана төште, ул, ак чәчәк алып, Тукайның күкрәгенә калап куйды.

— Матур! — диде туташ. — Сезгә килешә.

Тукай да, савыттан зәңгәр чәчәк алып, туташның түш якасына беркетте.

— Кайгыларымны таратучы зәңгәрсу чәчәк! — диде Тукай, ләкин ул инде тагын сагыш эченә чумган иде. — Чәчәк үзенең көче җиткән вак кайгыларны гына тарата ала. Кичерегез, туташ.

Тукайның кәефе киткәнен күреп, туташ хафага төште:

— Сезгә нәрсәдер булган, Тукай әфәнде. Сөйләгез, әфәндем, сөйләгез. Мин аңлармын. Зинһар, яшермәгез миннән!

Тукай күңеленнән ниндидер олы карар кабул итте кебек, ул, савыттагы чәчәкләргә карап, сүз башлады:

— Алайдагы чәчәкләр өстендә үрелгән пәрәвездәге бихисап асылташларны мин тагын күрдем бүген. Әз генә ятып торган идем. Йокыга китәргә дә өлгермәдем шикелле, тирә-юнем мең төсле асылташлар белән тулды. Җыеп сезгә бүләк итәрмен, дип үрелгән идем, күктән ике башлы каракош килеп чыкты да, канатлары белән давыл чыгарып, сәйләннәрне коеп бетерде... Туташ! — Тукай кинәт аягүрә басты, гадәтендә булмаганча, туташның күзләренә туры карап, кычкырыр дәрәҗәдә көчле тавыш белән: — Туташ... зинһар... безнең танышлыкны онытыгыз! — диде.

Туташ торагайка әйләнде:

— Мин һич нәрсә аңламадым, Тукай әфәнде!

Тукай сабырлана төште.

— Кичерегез дорфалыгымны, зинһар. Миңа рәнҗемәгез. Мин алга таба сезнең белән күрешә алмыймын!

Туташ әле һаман Тукайның тел төбен аңламый иде.

— Берәр яры китәсезме? Әстерханга, әллә Җаеккамы?

— Еракка, туташ!

— Ерактан да кайтырсыз. Тагын Питербургкамы? Хат язарсыз. Мин дә сезгә язармын.

(Ахыры киләсе санда).

Шагыйрь һәм Шигырь

Лена ШАГЫЙРЬҖАН

(Дәвамы. Башы 8 нче санда).

Шигырьләр серләштерә дә, берләштерә дә.

Шигырь — күңел бушануы, хисләр һәм сүзләр энергиясенең билгеле бер рәвешкә керүе. Шигырьдә Сүз энергиясе — аның семантик, интонацион, график һәм фонетик энергиясе бергә туплана. Рухың шикадәр бай булса, сүзеңнең энергиясе шулкадәр куәтлерәк була.

Шагыйрьнең һәрбер иҗтимагый вакыйга һәм күренешкә карата үз фикерен, тәэсирен, мөнәсәбәтен белдерергә, реакция ясарга ихтыяҗы да, хокукы да бар.

Сүз Хакыйкатьтән дә көчле була ала. Иң кирәкле чын Сүзне табарга гына кирәк.

Дөньяда шигърнятсез берни дә юк бугай...

Шагыйрь өчен аерым фиркаләрдә тору мәжбүри түгел. Аның төп идеологиясе — ИМАН. Ягъни — Ирек, Мәхәббәт, Акыл, Намус. Искәрегез әле: бу төшенчәләрнең баш хәрефләреннән ИМАН сүзе барлыкка килә. Менә кайда ул Сүзләр энергиясенең тәңгәллеге һәм тылсымы!..

Җан сафлыгын вөждан газаплары гына саклый. Шагыйрь — ут йотып яшәүче. Пакьләнү, чистару шуннан килә. Язганда, күңел тыпычлыгы ук булмаса да, вөждан сафлыгы, һич югында шуңа омтылу, үкенү, тәүбә итү, газапланулар, һай, бик кирәк!..

Иҗат — фантазия, хыял ул. Үз хыялыныы үзен куып җитәргә омтылу. Мине бөтен юклыклардан шигырем коткарды, бөтен бушлыкны шул тутырды булса кирәк. Кешене коры «реаль» хыял гына рухландырмый. Аңа шигърияте «җүләр» хыял кирәк... Шундый хыял гына реаль юкны «бар» итә... Кешеләр шигырьне шуңа күрә кабул итәләр дә. Ә артык «реаль» хыял — комсызлык һәм нәфес билгесе ул. Шигърнятсез генә хыялланучы — ул бик тә рациональ кешедер. Чөнки ул реаль юклыкны тутыру өчен чара күрә башлый, эт булып арыганчы дөнья куа, эш атына әверелә. Хезмәт түгел – михнәт... Чөнки үлгәнче эшләү иҗат-керми. Андый михнәт коллыкка әйләнә, хезмәтнең шигъриятен, ләззәтен урлый. Тормышның бөтен хикмәте — шигъриятле хыялда. Әкиятләр нәкъ менә шигърнятле хыялдан туган. Ә «реаль» хыял — куркыныч. Ул артык матдилеккә, конкретлыкка этәрә. Ә бит хыялның кайвакыт хыял булып кына калуы кыйммәтрәк тә... Реальлеккә генә омтылган коры, ягъни шигърнятсез хыял кешенең бөтен тормышын фаҗигале дәрәҗәдә мәгънәсезгә әйләндерергә дә мөмкин...

Шагыйрьнең үз әсәрләрендә үзенә үзе каршы килүе дә ихтимал. Бу тормыш парадоксларыннан килеп чыга. Шигырьләрдә, йөрәк тибүе шиканча, әледән-әле үзгәреп тору да була. Шагыйрь гел бер төрле генә язса, кызыксызга әйләнергә мөмкин. Хәтта үзе белән каршылыкка кереп бетүе дә аны «умырткасыз кеше» дип әйтергә нигез бирми. Чөнки шәхес бертуктаусыз үсештә, үзгәрештә, яңарышта. Тормыш үзе шундый.

Шигърияттә өстен итеп каралган һәммә нәрсә Шагыйрьнең әһәмиятен киметә. Шуңа күрә шагыйрь, җае чыккан саен, Шигырьне якларга, күтәрергә һәм аның мөһимлеген исбатларга тырышырга бурычлы. Беренче чиратта, әлбәттә, әсәрләре белән! Һәрбер трибунадан, һәр чыгышында, һәр басмасында. Шагыйрь шигырьне дә, шагыйрьләрне дә якларга тиеш. Бер философ «теләсә нинди фән минем әһәмиятемне киметә», дигән... Дин дә шулай дия ала. Әмма рухиятне саклау фарыз.

Шигырьне аңлау — шагыйрь сүзләре аркылы укучының үз-үзен таный баруы ул.

Шагыйрь ул — синең җаныңның бер кисәге. Аңа «суксаң», ул үзеңә әйләнеп кайта.

Психологик һәм философик трактатлар уку һәркемнең дә хәленнән килми. Шигырьләр укып, әнә шул бушлыкны тутырырга мөмкин.

Шагыйрьнең үз сагышлары да гомумкешелек сагышы белән кушыла...

Элегрәк мин шагыйрь — сүзләрне буйсындыручы, дип аңлый идем. Юк икән шул, алар шагыйрьнең үзен буйсындыра башлый икән. Сүзнең көче!..

Шигырь — җан вә рухның тәннән бәйсез булып, ниндидер бер рәвешкә керергә ашкынуы микән? Күңел нечкәрү, җан тирбәлешләре форма сорый: җыр, бию, музыка, рәсем, шигырь һ.б.

Башка шагыйрьләрдән өйрәнергә була. Әмма үз җаның да кыймылдасын, хәрәкәтләнсен. Кайберәүләр әйбәт шигырьләр укып чыккач алган тәэсирләре йогынтысында шунда ук шигырь язарга тотыналар һәм, әлбәттә инде, әлеге шигырьләрне кабатлый башлыйлар. Үзләре дә сизмәстән... Ләкин укучы яки «теге» автор аны бик тиз күреп ала. Кеше тәэсире белән генә тусырга ярамый. Меңнән берәү андый «шигырьне» барыбер танып ала... Дөрес, теге яки бу авторга охшаш рухи кичерешләр, ассоциацияләр булырга бик мөмкин. Ләкин чит тәэсирдән котылып, үз йөрәгеңне тыңларга кирәк. Охшашлыклар булган очракта да, шигырь үзен-үзе аклар дәрәҗәдә көчле һәм үзенчәлекле булса гына, укучы аны кабул итә; кичерә һәм ышана. Иң мөһиме — ихласлык һәм тагын ихласлык...

Болай гына шигырь язып йөргән бәндәдән чын шагыйрьнең аермасы шунда: бәндә әйтер шигырь язар идем, фәлән эшем кала, дип... Шагыйрь әйтер фәлән эшне бик эшләр идем дә, шигырем кала, дип...

Шигырьдә тапталып беткән рифмалардан сакланырга кирәк. Алар бертөрлелек, кабатлау һәм примитивлыкка китерә. Кабатланмау өчен, кабатланмас психологик кичерешләр кирәк. Дөрес, кешеләрдәге бик күп уртак сыйфатлар (тел бит әле үзе дә иң төп уртаклык) кабатлау куркынычын да арттыра. Шуңа күрә бөтен ышаныч — хисләр үзенчәлеге һәм формада. Күтелмәгән яңа рифмалар да бөек нәрсә Кайвакыт алар хәтта көтелмәгән образ һәм фикерләр дә тудырып куялар ..

Шигырь остасы шигырьләрне «ясый» да белә. Ләкин бу — ясалма шигырь, дигән сүз түгел. Мондый хәл шигырь техникасын, аның серен бик тирән үзләштерүдән килә Ясалма шигырь исә «оста ясалган» шигырь дигән сүз түгел. Ясалма шигырьдә салкын акыл, хиссез сүз күзгә бәрелеп тора Чын шигырьдә, сәнгатьчә «ясалган» шигырьдә акыл да, осталык та күзгә бәрелеп, чекрәеп тормый, ул бары тик үзеннән-үзе, су эчкән кебек, һава сулаган кебек кабул ителә Анда инде нәкъ менә затлы картиналардагы кебек, «пумала эзе» беленми, бары тик — төсләр генә...

Шигърияттә акыл иясе булудан бигрәк, хикмәт иясе булырга кирәк.

Үзең нинди — шигырең шундый.

Шагыйрьнең сүзе — аның эше ул.

Шигырь язу — үз-үзеңә яки кемгәдер зарлану сыман...

Нәкъ менә бала чакта. «Әтигә әйтәм мин сине!», «Әнигә әйтәм!» дигән кебек, «Шигырьгә әйтәм мин сине», дип бер яклаучы эзләгән шикелле...

Шигырьнең әйбәт булмаска хакы юк!.. «Юлга чыксаң, иптәшең үзеңнән әйбәт булсын», диләр. Мин исә «Иргә чыксаң, ирең үзеңнән яхшы булсын», дип әйтәм дә, «Шигырь язсаң, шигырең үзеңнән әйбәтрәк булсын!» дип тә өстим...

Шигырь культурасы — хисләр һәм тел культурасы. Шагыйрь иң укымышлы, иң сизгер, иң зыялы һәм таләпчән укучыга исәп тотып язарга тиеш.

Шигырь үзенә карата бик сак булуны һәм бер үк вакытта тәвәккәллекне дә таләп итә.

Гаҗәеп сурәтләүләр, сәер метафораларның да эчке логикасы булырга тиеш.

Шагыйрь, язган вакытта, иҗекләр басымын махсус осштырып утырмый. Ул эчке бер ритмнан, хисләр халәтеннән килеп чыга. Ә шигырьнең эчке хасиятләрен билгеләү — тәнкыйтьчеләр эше...

Нәрсә турында языйм икән дип йөргән кеше шагыйрь түгел. Шигырь үзе килә, тема үзе табыла.

Каләмгә тотынган көннән шагыйрь ялгызлыкка юл сала башлый.

Шагыйрь өчен шигырендәге һәр сүзе, һәр иҗеге, һәр ноктасы искиткеч мөһим. Укучы өчен — бигрәк тә! Шуңа күрә шигырьләрне бастырганда киткән һәрбер хата Шагыйрь күңелен үтә җәрәхәтли, ярсыта, үкендерә...

Шагыйрь ул культмассовик түгел...

Шагыйрьлек — ул бер эчке хөрлек халәте. Шагыйрь өчен «иң яхшысы» — ятим һәм ялгыз булудыр, бәлки... Болар аны бәйсез һәм ирекле итәдер сыман... Әмма — җавапсыз түгел!

Шигырь — ул төш күрү кебек... Анда мәгънә эзлеклелеге мәҗбүри түгел. Ниндидер ассоциацияләр, ишарәләр, билгеләр... Кайвакыт шигырь миңа күктән җибәрелгән билгеләрне «уку» ысулы булып тоела..

Күңелдә йөргән янсә кәгазьгә теркәп куелган шигъри образлар,сурәтләр яки юллар һәрвакытта да шигырь булып җитлекми. Алар тумый калган яралгылар шикелле. Күрәмсең, андый яралгылар үзләре дә шигырь булып бетәргә теләмиләрдер...

(Ахыры 16 нчы биттә).

Шагыйрь һәм Шигырь

Лена ШАГЫЙРЬҖАН

Шигырьләр — минем «яшен кайтаргычларым».

Шигырь теорема түгел. аны исбатларга кирәкми. Гәрчә исбатлап булса да.

Шигырь «уйнаштан» түгел. мәхәббәттән туа.

Озын яки кыска язу талант күрсәткече була алмый. Чөнки, Энгельс әйтмешли, «кыска язарга вакыт юк», диярга дә мөмкин. Ягъни — иң кирәкле, иң урынлы, иң төгәл сүзләрне сайлап утырырга. Бу инде уйландыра торган нәрсә... Шул ук вакытта, озын язуның да үз нигезе бар.

Кин күңелле булмаса, шагыйрь юк.

Каләмгә тотынганчы, арыланырга, пакьләнергә кирәк. Намазга әзерләнгән кебек.

Нәфрәт шигырьләре дә олы мәхәббәттән генә туа. Киң мәгънәсендәге яратудан.

Шагыйрь ул — рухи донор.

Милләтен яратмаса, кеше шагыйрь була алмый.

Шагыйрь «замана баласы» да, «заман герое» да түгел. Ул — Вакыт эчендә.

Янара белү — шагыйрьнең төп шарты. Хәер, чын иҗатчы искерми дә.

Шагыйрь үлсә, һәркем бераз үлә...

Тукай кебек язарга кирәкми, аның кебек янарга кирәк...

Танылган бер шагыйрь «Мин ризамын сатылсам да, Тукай кебек була алсам...» дип язды. Ә нигә «Тукай кебек булырга» соң әле?.. Шигырьгә һәм тормышка Тукайча мөнәсәбәтен булсын! «Тукай кебек яна алсам», дисә дә, әле шигырь барып чыккан булыр иде... «Була алсам», дип әйтү белән шигырь бетте! Аннары Тукай кебек «сатылырга» да кирәкми... Бу әллә ничек яңгырый... Үз язмышың белән шагыйрь бул! Гомумән, «Мин ризамын сатылсам да» — бик тә этикасыз, ямьсез һәм мәгънәсез. Ә шигырьләрдә — этика дигән нәрсә бик мөһим!

Шагыйрьне укыйлар икән, димәк, инде аның шәкертләре бар, дигән сүз.

Шигырь язу — каләм белән җир сөрү ул.

Шагыйрь ялганлый алмый. Чөнки шигырь ул чынбарлыктан бигрәк, хакыйкатькә якынрак тора. Әгәр алар параллель яши алалар икән, бәлки шигырь дә «реаль» күренештер? Уйдырган дөньяда яшәгәнче, уйдырма дөньяда яшәвең дә артык... Чөнки кайбер сәнгать әсәрләре кеше күңелендә чын тормыштан да реальрәк булып уелып кала бит.

Надан кеше шагыйрь була алмый.

Шагыйрь ул — халыкның квинтэссенциясе.

Шигырь сере — моңда.

Шагыйрь булу өчен ышанырга кирәк!

Үз шигырен язганда татыган ләззәтен укучылар яки тыңлаучыларга җиткерә алса гына, шагыйрь бәхетле була.

Шагыйрь ачылсын өчен мохит тә зарур.

Шагыйрь бай булмый — байгыш була.

Шагыйрьнең «холкы» — аның шигырендә.

Шигырьнең «җенесе» юк. Шагыйрь дә шагыйрә дә — шигырьдә бертигез.

Яшәү — хисләр дәрьясы. Сүзләр генә габыйн өлеш...

Кайберәүләр шагыйрь турында «Шигырьләрен яратам, әмма үзен сөймим», дип тәкъбирләнәләр. Әмма бу — тар караш һәм тар күңел галәмәте. Димәк, шигырен дә «сөйми», бәлки көнләшә. Шигырь — шагыйрьнең үзе бит инде ул! Аның органик һәм рухи сингезы бөтенлеге. Аның гомумиенергиясенең та мчылары. Аның һәм рухи һәм җисми продукты, кан һәм җан температурасы, җан басымы. «Сүзе әйбәт, үзе начар» була алмый...

Шагыйрьләр ике төрле була: әдәбияттан халыкка килүчеләр һәм халыктан — әдәбиятка... Билгеле бер ноктада алар очрашалар... Икесе дә әйбәт. Бары тик кеше күңеленә барып җитсеннәр генә. Дөрес, әдәбияттан гына килгән шигырь әсәрләнләрме. Йөрәктән чыгуы кирәк.

Артык төгәллек шигырьне гадиләштерә...

Шагыйрьнең Сүзен йә зурлыйлар, йә урлыйлар. Ә үзен — күбесенчә... хурлыйлар...

Шигырь — хобби түгел. Минем өчен бик күп еллар буена шигырь язудан башка бөтен эшләр икенче дәрәҗәдәге шөгыль булып торды. Шигырь — минем тормышымның төп эше.

Сүз үзе дә фикер тудыра.

Әдәбият ул бөтен кешене дә үзен кебек дип кенә уйламас өчен дә кирәк. Кеше — чиксез вариантта... Шигырьнең дә чиге юк.

Шигърияткә «атылып» килеп кергәнче, агылып керү табигыйрәк.

Н. Чернышевский билгеләп үткәнчә, кемгә нәрсә матур булып тоела бит... Теге яки бу әдәби әсәрне күп укыйлар дигән сүз әле аның югары дәрәҗәдәге чын әсәр булуына дәлил түгел. Димәк, ул бары тик билгеле бер даирәләр аңына тизрәк барып җитә генә алган. Ә бит моның киресе дә булырга мөмкин!

Гаҗәп, минем шигырьләрем минем үземне дә тәрбияләделәр... Баштарак шагыйрь үзе «нәрсәдер» иҗат итә. Үзенең иҗат стилен барлыкка китерә. Һәм, ниһаять, шул стиль инде үзе шагыйрьне яңадан формалаштыра, камилләштерә, үзенчәлеген ача, аның иҗатын гына түгел, шәхес буларак үзен дә, яшәү һәм уйлау рәвешен дә тудыра. Нәкъ менә философиядәге «кире бәйләнеш» шикелле.

Минем шигырем — «мин» ул. Бу дөньяда шагыйрьгә «үзе» булып калырга гел комачаулыйлар. Ә үзләре «тормышта бер төрле, шигырендә — бүтән», дип гаепләргә дә күп сорамыйлар. Ә бит шагыйрь шигырендә генә булса да әнә шул «чын үзе» булып калырга омтыла да инде...

«Мастер и Маргарита»ның мәгънәсе иҗатчы һәм аны рухландырып торучы, илһамландыручы, дигәнне аңлата. Ир Шагыйрьләрнең һәрвакыт диярлек шундый героге була. Күбесенчә шулай. Ә менә Шагыйрәгә ул яктан бик авыр. Аңа моңдый бәхет бик эләкми. Чөнки ир-атлар андый турылыклы илһамчы булып бетә алмыйлар. Бу — хатын кызга. Маргаритага гына хас. Шагыйрә үзенә-үзе юаныч, илһам, терәк булса гына инде.

Шигырь — укучыны мәст итәрлек исерткеч көчкә ия булырга тиештер... Чөнки кешеләргә кайвакыт «исерү», онытылу да кирәк. Хыялданмы, шигырьдәнме, мәхәббәтәнме... Хәмер эчмичә дә исерә алу...

Кайвакыт «тел сындырып» та образлылыкка ирешеп була. Сәер нәрсә...

Һәрбер телнең үзенә бер темпы да була. Бу — милләт кайнарлыгы, милләт темпераменты белән бәйләнгән. Кызу темплы тел кайнар шигырьләр өчен әйбәт. Шул ук вакытта шагыйрьләр — милли телнең кайнарлыгын саклап торучылар алар...

Шагыйрь йоклап яткан таш кебек авыр сүзләрне дә хәрәкәткә китерә, җанландыра.

Шагыйрьләрне бераз канатландырып алу да кирәк. Гел гаеп эзләп торсалар, шагыйрь дә кырыслана, үзен яратмасалар, ул да кешеләрне яратмый башлый. Шагыйрь яратмавы куркыныч! Әгәр акынга яки чичәнгә «Ай, рәхмәт!», «Афәрин!», «Әйт шуны!» дип тормасалар, ул да туктап калырга мөмкин.

Шагыйрьне аның иҗаты һәм язмышы раслый. Теге яки бу сүзне кемнең әйтүе дә мөһим... Бер үк сүзләр, гыйбарәләр дә төрле шагыйрьдә төрлечә яңгыраш аладыр сыман. Пушкин яки Тукайның гади генә юллары да — шигырь... Нәрсә бу?! Күктән билгеләнүме әллә? Рухи энергияме? Шәхеснең «сайланган» булуымы?..

Соңгы елларда шактый мәгълүм шагыйрьләрнең дә берниндиһ шигъриятсез, тәэсирсез, хикмәтсез шигырь сыман әйберләре еш басыла башлады. Исем астында барысы да шома гына үтеп китәдер сыман. Ни акыл, ни хис, дигәндәй... Акыл сату, олысымаклану, позер булу сизгер укучының гайрәтен чигерә, сагайта, ачуын китерә...

Шәкертләр ике төрле була: берәүләр теге яки бу шагыйрьдән өйрәнәләр, әмма бу хакта беркайчан да, беркемгә дә әйтмиләр. Икенчеләре, бигрәк тә чын талантлы булып чыкса, кемнән өйрәнүен, кемне яратуын һәм кемгә охшарга тырышуын, һичшиксез, әйтми калмаячак. Чөнки ул үз йөзен габачагына шикләнми...

Бу дөньяга килеп, шагыйрь дә булып чыкмасаң, ни үкенеч...

Шигърияткә кереп китәсез икән, үзегезгә дә, шигырьгә дә хыянәт итмәгез. Ул моны кичерми!.. Талантыгыздан качмагыз, аны югалтмаска тырышыгыз һәм нинди генә шартларда да шагыйрьне якларга, сакларга әзер торыгыз! Бу — минем яшь шагыйрьләргә киңәшем. Шуны онытмагыз — Адәм балалары шигырьгә мохтаҗ.

Һәр авылның үз шагыйре булса да артык түгел. Һәр урамның, һәрбер йортның үз шагыйре булсын иде... Ниһаять, һәркем күңеле белән шагыйрь булса иде...

Әгәр шигырьгә үзеңне бөтенләен белән багышласаң, чын тормышка нәрсәң кала соң? Димәк, иҗат ул үзе — реаль тормышың булып чыга инде...

Намус — Талантның аерылгысыз юлдашы. Затлы һәм тәҗрибәле укучы аны бик тиз абайлап ала һәм кемгә ышанырга мөмкинлеген үзе хәл итә.

Шундый затлы укучы хакына гына, тирән белемле, аңлый белүче нәзакәтле һәм зәвыклы Укучы хакына гына иҗат итәргә мөмкин. Рәхмәт сиңа, акыллы һәм сизгер Укучы!

Июль, 1995 ел.

КЕШЕЛӘР, НИК ДӘШМИСЕЗ?

Шифалы суы озакка җитәрме?

Табигать бирсә, муллап бирә бит ул. Шуңа шөкер-рәхмәт кылырга һәм аның кадерен белергә генә кирәк. Бу җәһәттән, Азнакай шәһәренең «Нефтемаш» тәҗрибә заводы янындагы шифалы чишмәне дә Ходай Тәгаләнең олы бүләге дип атарга мөмкиндер. Әлеге чишмә суының җанга сихәт, йөрәккә көч бирүе һәркемгә мәгълүм.

Күптән түгел генә ул төзекләндерелде, зәвык белән эшләнгән металл рәшәткә белән уратып, түбә астына алынды, янында бер дигән чәчәкләр үсеп утыра. Чишмәгә сөзәк баскычтан төшәсең. Аңа язгы-көзге сулар, яңгыр агып төшмәсен өчен тирә-юне мәрмәр плитәләр белән түшәлгән, сандык рәвешендәге ачылмалы-ябылмалы чистарту урыны да бар. Ул биккә алынган. Аның кырыенда зур чүмеч тора. Кемнәр генә төшми аның суын алырга, гаякка таянган әби-бабайлар, ясанган-бизәнгән кызлар, егетләр, малай-шалайлар... Кайберләре хәтта жинел машина, мотоцикл, велосипед, кул арбасы белән килгәннәр.

— Бу чишмә суы бөер авыртуын басты, — дип сөйләп торды бер апа. — Аллага шөкер, бик шифалы су булып чыкты.

— Шушы суны эчә башлагач бавырым рәтләнде, — дип куәтләде аның сүзен икенче бер агай.

Әйе, алтыннарга алыштыргысыз хәзинә бу чишмә суы. Аның барлыкка килү тарихы да шактый кызыклы. Ул елларда «Нефтемаш» заводында эшләгән Дамир Йосыпов миңа түбәндәгеләрне бәян итте:

— Моннан унөч ел элек «Нефтемаш» заводының яңа корпусына нигез салганда бәреп чыкты бу чишмә. Ул урында сазлык иде, таллар үсеп утыра иде. Башта аның суын эшчеләр генә эчте. Тора-бара Азнакай халкы да килә башлады. Су бик акрын акты. Шуңа күрә анда бер-ике сәгать чират торырга туры килә иде. Чишмәне тәртипкә китерү буенча бик күп тәкъдимнәр булды. Тик аларны тормышка ашырырга алынучылар гына булмады.

1987 елның язында завод директоры В.Мәхмүтов капиталь төзелеш бүлеге хезмәткәрләре Азат Хәмитовны, Нәсимә Гайсинаны, Фәргать Гайсинны, Инна Хәкимованы һәм мине үзенең кабинетына чакырып алды да. «Ничек итсәгез итегез, тик чишмәне рәткә китерегез, материалны да, акчаны да кызганмам», — диде.

Һәм китте шуннан соң эшләр. Башта чишмә чыганагын эзләргә туры килде. Бульдозер белән җир катламын алуга, үй-үйбиш җирдән су чыга башлады. Тутыкмый торган калайдан чан ясадык та, торба чыгарып калдырып, өстенә бетон плитә салдык. Яр ишелмәсен өчен ана бетон плитәләр түшәдек. Заводны бетон койма белән әйләндереп алганда чишмәне тышкы якта калдырдык. Анда сазлык хасил булмасын өчен ветераннар кибете һәм теплица тарафына канау казырга туры килде.

Чишмә суының сыйфатын дәүләт санитария-эпидемиология үзәге тикшереп тора. 1993 елның мартында үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә суның дәүләт стандарты таләпләренә туры килүе ачыкланды. Химик күрсәткечләр буенча 1 литр эчә торган суда 1-350 миллиграмм хлоридлар булырга тиеш. Әлеге чишмә суында исә алар 9 миллиграмм тәшкил итә. Табибларның әйтүенә караганда, составында хлоридлар, тозлар аз булган мондый су бөер һәм бавыры авырткан кешеләргә аеруча файдалы. Ә йөрәк авырулы кешеләргә аны эчәргә киңәш ителми. Хлоридлар катнашмасы 350 миллиграммнан артып китсә дә суны эчәргә ярамый.

Чишмә суы, шифалы булу өстенә, гаҗәеп тәмле. Әмма аның кадерен белмиләр. Кемнәрдер андагы гөмбәчекне, урындыкларны ватып ташлаган. Будканың диварларын да сүтеп алып киткәннәр. Җәй көннәрендә кайбер адәмнәр чишмә янында колорадо коңгызларын түгеп чиләкләрен юалар. Чишмә тарафын чүп-чар басты. Ул акрынлап бәдрәфкә һәм яшьләрнең аракы эчү урынына әверелде.

Ниһаять, быел завод директоры В.Мәхмүтов, шәһәрне төзекләндерү һәм яшелләндерү предприятиесе җитәкчесе Ә.Мортазин, Ык буе табигатьне саклау инспекциясе җитәкчесе Х.Мөстәкыймов кабаттан чишмәне яңарту, төзекләндерү эшенә алындылар. Бу болгавыр һәм авыр заманда аларның мондый изге эшкә алынулары һәртөрле мактауга лаек. Чишмәне төзекләндерү өчен җәмгысе 15 миллион сум акча сарыф ителде.

Хәзер чишмә янында ике катлы шәхси йорт калкып чыкты. Анда инде канализация дә, гирән баз да булыр. Ә бу канализация шифалы чишмә юлына туры килсә ни эшләрсең?

Шәһәр эчендәге олы хәзинә – шифалы, йомшак сулы чишмәбезнең гомере кыска булмагае, дип борчылам мин. Бу нефтьчеләр төбәгендә күпме чишмәләр харап булды бит. Аларның күбесен терелтү инде һич мөмкин түгел. Булганнарын саклап кала алсак та бик җиткән инде.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай шәһәре.



ХӘТЕР КАЙТАВАЗЫ

Яшьлегемә йөгереп кайтыр идем...

Гомер уза барган саен бала чаклар — бакчага йөргән, мәктәптә укыган еллар сагындыра. Педучилищеда укыган, укыткан, университетта гыйлем эстәгән еллар да ул кадәр үк үзәкне өзми.

Заманында Чистай шәһәр партия комитетында эшләгән әтиемне Яуширмәгә авыл советы рәисе итеп билгеләгәннәр. Без шул авылда үстек. Чистайдан күченеп килгәндә олы абыем гына булган. Мин — өченче бала (миннән соң янадан алты бала туды). Хәтерлим, мин әле бакчага йөргәндә дә безнең үз йортыбыз юк иде. Берәүнең буш йортында квартирантлар булып яшәдек. Беренче сыйныфка исә мин үзебезнең өйдән киттем. Шомырт, миләш, алма агачлары үсеп утырган бик матур бакчалы бер иске йортны сатып алдык без. Аннары яңасын җиткердек.

Сугыштан соң әти белән әни мәктәптә эшли башлаганнар. Шулай итеп, безнең берничәбезне башлангыч сыйныфта әни укыткан булса, югары сыйныфларда әти һәммәбезгә дә физика, сызым, рәсем, музыка дәресләре бирде.

Ул елларда безнең өй гөрләп тора иде. Ишек-капка гел ачык булды. Уен-көлке, елаш-бүлешләр (күп балалы гаиләдә андый нәрсәләр буладыр, дип уйлыйм) белән беррәттән, өебездә һәрвакыт музыка яңгырап торды. Әти музыка уен коралларының барысында да диярлек уйный белгәнгә, баян, кыңгыраулы гармун, скрипка, курай, аккордеон, мандолина, балалайка моңнары безнең күңелләргә бала чакта ук сеңде. Шуңа күрә дә безнең һәркайсыбыз нинди дә булса уен коралында уйный белә. Кайберләребез исә, әни кебек үк, моңлы тавышка ия. Кыскасы, без җыр-музыка белән тәрбияләнеп үстек, һәм без аннсыз тормышны күз алдына да китерә алмыйбыз.

Җае туры килгән саен, мин шул чактагы тойгы-хисләрне, күренешләрне хәтеремдә яңарту һәм хыялымда гына булса да бала чакка кайту өмете белән авылыма кайтам. Ни гаҗәп, бу кайтулар миңа яңа газаплар гына өстәп җибәрә. Авыл минем белән бергә олыгая сыман (бәлки, ул чыннан да шулайдыр): үсеп утырган үләннәренә кадәр икенче, кырдагы чәчкәләр дә ят, без үскәндәгеләрнең күбесе читкә чыккан. Гөрләп торган өебез генә түгел, шаккый зур урамыбыз да буш, анда-санда ачылып киткән капкалардан кереп-чыгып йөрүче карт-карчыклар күренмәсә, бу урамда кеше яшәми, дип уйларсың. Ә инде әби-бабайлар да китеп барса, урам бөтенләй юкка чыгачак, дигән авыр тойгы уяна күңелдә. Киткәннәр урынын алырлык балалар тумый хәзер авылда. Үсеп җиткәннәре акрын-акрын гына читкә чыгып китә. Шөкер, урамыбыздагы бушап калган йортларның берсенә яшь бер гаилә килеп урнашкан. Бәлки, аларның аяклары җиңел булыр. Шулай булса, безнең урамда да бала-чага тавышы яңгырый башлар иде, дигән өмет уяна.

Инде дистә елга якын буш торган өебезгә кайту күңелдә гаҗәеп авыр кичерешләр уята. Безне җырлатып-биетеп үстергән, бишектән үк җыр-музыкага мәхәббәт тәрбияләгән, авырган чакларда, ни булды икән сиңа, багалмам, дип төннәр буе күтәреп йөргән, и-и, исән-сау кайтып җиттеңме, кызым (улым) дип, күз яшьләре аша елмаеп каршы алган әти инде дөньяда юк. Әлфия Афзалова, Илһам Шакиров, Мирей Матье җырларын тыңлый-тыңлый бергәләп идән юган, өй җыештырган, ашарга пешергән сеңелләрем дә юк анда. Капка-кураларны, бакча тирәләрен төзекләндереп, карап, һаман саен ни булса да төзеп, ясап торган, бергәләп өч-дүрт баянда өздереп уйнаган абый-энеләрем дә төрле шәһәрләрдә яшиләр. Әти бер мәрхүм булгач, әни дә, ялгыз яши алмыйча, бер сеңлемә торырга китте. Алар да олыгая. Менә шул төрле шәһәрләрдә яшәү, олыгая бару безне бер-беребездән һаман саен ерагайта сыман. Шуларны уйлап, җаным өзгәләнә.

Өй искерә, череп. Без үскәндә көчкә генә үрелеп карый алган тәрәзәләр инде җиргә якынайган. Капка кыйшайган, җиләк-җимеш бакчасында да тәртип юк. Азгын чияләр кызыл, кара карлыган куакларын басып киткәннәр. Крыжовник картайган, кура да җиләк бирми. Алмагачлар корып беткән. Исән калган берләнбер алмагач кына, без үскән елларны хәтерләтеп, күп итеп алма бирә. Кайтыгыз, ашагыз, сабый чакларыгызны искә алыгыз, дия кебек алар. Әти карап-тәрбияләп торганда чиләк-чиләк бал биргән кортлар инде күптән үлеп бетте. Башка кешене кабул итә, якын итә алмады алар. Шуларны күреп, бәгырь телгәләнә.

Сыйныфташлар белән җыелышып, бергә укыган елларны искә төшереп, туган мәктәбебездә, классыбызда утыру шатлыгыннан да мәхрүмбез. Безгә белем биргән зур агач мәктәбебезне инде күптән җимереп ыргытканнар. Таштан салынган яңасы безнеке түгел инде. Шуңа күрәдер, мәктәпне тәмамлаганга байтак еллар узса да, бергә җыелып, сөйләшеп утыра алганыбыз юк. Сыйныфташларыбызның, укытучыларыбызның кайберләре инде мәрхүм. Алар белән мин, әлбәттә, беркайчан да күрешә алмаячакмын. Исән чакта утырасы иде бер гөрләшеп!

Менә шул уйлар күңелгә һаман тынгылык бирми.

Газаплантдырса да, сагындыра, бик сагындыра туган авыл. Күңелем белән гел шунда ашкынам, балачагыма кайтасым килә. Тик моның инде мөмкин түгеллеген, шул чактагы матурлыкның, самими хисләрнең кире кайтмаячагын аңлау йөрәкне пәрә-пәрә китерә...

Флера ТАРХАНОВА.



Тәүфикъ ӘЙДИ

Тарихлардан

Соңгы вакытта Татарстан белән Төркия арасында хезмәттәшлек елдан-ел киңәя бара. Икътисад, мәгариф, мәдәният өлкәләрендә бәйләнешләребез август аенда архив тармагына да җәелде — Төркия дәүләт архивлары баш директоры Исмәт Бинарк әфәнде Татарстанга рәсми визит белән килде.

Төркия архивлары дөньядагы иң бай хәзинәләрнең берсе дип санала. XIII йөз ахырында ук бәйсез дәүләтләрен нигезләгән Госманлы төрекләре, мөстәкыйльлекләрен күз карасыдай саклаулары аркасында, дәүләт архивын да бик күптән барлыкка китергән һәм аны гасырдан гасырга баетып саклый алуга ирешкән. Госманлы дәвере архивы хәзер нигездә Истанбулның Тупкачы музеенда тупланган һәм андагы документлар саны 200 миллионга җитә.

Архивлар — милләтнең һәм дәүләтнең ышанычлы таныклыгы, ул буыннар бәйләнешен, халыкның һәм илнең үсеш үзенчәлекләрен ачык һәм төгәл чагылдыра торган көзге, иң кадерле тарихи һәм мәдәни мирас санала. Шунлыктан Төркия Җөмһүриятендә аларны саклауга, өйрәнүгә игътибар даими арта бара. Шушы максатта 1984 елда Төркия дәүләт архивларының Баш идарәсе төзелә. Бу идарә тарафыннан архивларны тулыландыру, аларны эшкәртү, классификацияләү, заманча техника кулланып исәбен алу, аларны тикшерү, бер өлешен музейларда, күргәзмәләрдә күрсәтү кагыйдәләре төзелә, архив белгечләрен әзерләү, әһәмиятле документларны һәм аларга багышланган гыйльми мәкаләләрне, монографияләрне бастырып чыгару гамәлгә ашырыла. Архивларны бер урынга туплау, архив биналарын яңарту эшләре тәртипкә салына.

Архивларның милли аңны ныгытуда, дәүләтне тотрыклы итүдә һәм көчәйтүдә, мәдәниятне үстерүдә гаять әһәмиятле урын тотуы бәхәссез. Шуңа күрә Төркия дәүләт архивлары Баш идарәсе үз эшен Көнбатыштагыча техник чараларга нигезләнеп оештырырга омтыла, халыкара корылтайларда катнаша һәм тәҗрибә уртаклаша, ике яклы килешүләр төзеп, башка илләр белән күчермәләр алмаша, Төркия дәүләт җитәкчелеген кирәкле белешмәләр, мәгълүматлар белән тәэмин итә һәм хәтта башка илләргә дә ярдәм кулын суза. Уңышлы эшләр өчен Төркия архив белгечләре алдынгы илләргә барып белемнәрен күтәрә һәм туган илләренең казанышларын халыкара җәмәгатьчелеккә танытырга тырыша.

Бу җәһәттән Төркия архивлары чын мәгънәсендә халыкара әһәмияткә ия, чөнки аларда Балкан илләренә, гарәп мәмләкәтләренә, заманында Госманлылар империясенә кергән күп кенә халыкларга кагылган, шушы империя белән икътисади, сәяси, дини, мәдәни бәйләнешләр урнаштырган байтак төбәкләр, патшалыклар хакында документлар саклана.

Төркия дәүләт архивларының әһәмияте безнең өчен аеруча зур. Казанда гасырлар буе тупланып килгән әһәмиятле документлар, барлык китапханәләр 1552 елда илбасарлар тарафыннан вәхшиләрчә юк ителгәнлектән, без озак дәвер милли тарихыбызны ышанычлы чыганакларга таянып яктыртудан мәхрүм калдык. Халкыбызның үткәне аның дошманнары тарафыннан язылган елъязмаларга, грамота һәм указларга таянып яктыртылганлыктан, без әле бүген дә чын тарихыбызны дөрес яктыртудан мәхрүм. Менә шундый шартларда Төркия архивларында сакланган Алтын Урда, Казан, Әстерхан, Себер ханлыклары дәвере документлары (ә алар бар!) безнең тарихи мирас бушлыгын шактый дәрәҗәдә тулыландыра ала.

Әйтергә кирәк, бу җәһәттән Төркия архивлар идарәсе Татарстан архивлар идарәсенә инде 1994 елда ук шактый сандагы документларның күчермәләрен бүләк итә. Алар арасында Сәлим солтанның Мәскәүгә һәм Бакчасарайга җибәргән ике хаты, Казан мөһаҗиренә ярдәм күрсәтү беркетмәсе (1863), Казаннан килгән яшьләрнең Төркия мәгариф министрлыгына җибәргән кәгазьләре (1908), Төркия тышкы эшләр министрлыгының Рәсәй мөселманнары хәлен яктырткан документлары (1883) һ.б. бар.

Исмәт әфәнде Бинарк Татарстанга менә шундый хезмәттәшлекне тагын да киңәйтү, моның өчен ике як тарафыннан рәсми килешү төзү өчен килгән. Аның белдерүенчә, Төркия архивлары хәзинәсендә татар халкына кагылган борынгы документлар да, Төркиядә яшәгән мәшһүр Йосыф Акчура, Садрый Максуди Арсал, Габделбари Баттал, Рәшит Рәхмәти Арат, Зәки Вәлиди-Туран, Хәмит Зөбәер Кошай, Әкъдәс Нигъмәт Курат, Гаяз Исхакый, Закир Кадыйри Уган һ. б. эшчәнлегенә бәйле язмалар да күп. Аларны үзара файдалы килешү нигезендә бергәләп өйрәнеп, шуның нәтиҗәсендә әле бөтенләй мәгълүм булмаган кыйммәтле табышларга юлыгу ихтималыбыз да бар.

Татарстан Җөмһүрияте Министрлар Кабинеты каршындагы Архив идарәсе мөдире Дамир Шәрәфетдинов раславынча, республикабыз архивлары хәзинәсендә 4,5 миллион документ саклана һәм аларның саны ел саен 50 меңгә артып тора. Соңгы вакытта аны тулыландыру һәм тәртипкә салу, матди базасын ныгыту, әзерлекле хезмәткәрләр белән тәэмин итү буенча байтак чара күрелгән. Архив хезмәте быелның алты аенда гына да 110 мең белешмә әзерләп биргән, биш докторлык, унсигез кандидатлык диссертациясе язылуга булышкан, «Гасырлар авазы» журналын чыгарырга керешкән, төрле җыентыклар төзүдә катнашкан, күргәзмәләр оештырган. Хәзер аның мондый эшчәнлеге Татарстаннан читтә дә танылган

Архивлар идарәбез Халыкара архивлар советының даими әгъзалыгына кабул ителгән.

Дамир Шәрәфетдинов белдергәнчә, Төркия белән уңышлы хезмәттәшлек итәр өчен безнең дә кызыклы документлар тәкъдим итәр мөмкинлегебез бар Әйтик, Госманлы солтаны вәзире Хилми пашаның Казанга килүе (1910) һич тә эзсез калмаган. Күренекле төрек язучысы Әхмәт Мидхәтнең татар каләмдәше Фатыйх Кәримигә язган хатлары (1898-99); «Вакыт» газитенә Истанбулдан килгән хатлар (XX йөз башы) һ.б. игътибарга лаек.

Исмәт Бинарк визит барышында Татарстанның мәдәни тормышы, укымышлылары, иҗат әһелләре белән танышуга да зур әһәмият бирде, Г.Камал театрында спектакль карады, радио-телевидение тапшыруларын тамаша кылды һәм тыңлады, Кырлайдагы Г.Тукай музеен, Болгардагы тарихи тыюлыкны күреп тәэсирләрен баетты. Без дә аның белән шул чакта иркенләп аралаша, үзебезне Төркия яңалыклары белән беренче кулдан сугара алдык. Бу аралашу күңелле дә, рәхәт тә булды, чөнки ул, татар кызына өйләнгәнлектән, татарча да әйбәт аңлый иде.

Исмәт бәй 1941 елда туган, Истанбул университетын тәмамлаган, китапчылык һәм архивчылык буенча Англиядә һәм Франциядә белемен киңәйткән, фәнни-тикшеренү эшләрен Финляндиядә дәвам иткән, Төркия архивлары вәкиле буларак, башка күп кенә илләрне дә гизгән. Аның библиографик күрсәткечләре, китапчылыкны, төрек китабы тарихын, төрек мәдәни учаклары үткәнен сурәтләгән, аерым шәхесләр эшчәнлеген гәүдәләндергән фәнни хезмәтләре көндәлек матбугатта да, аерым басма рәвешендә дә дөнья күргән. Әл-Фараби, Зыя Гүкалып библиографияләре, Истанбул турында әдәбият күрсәткече һ.б. Төркиядән читтә дә кызыксыну уята, менә шунлыктан И.Бинаркның кайбер хезмәтләре чит телләргә дә тәрҗемә ителгән.

Исмәт бәй бер үк вакытта Әнкара университетында архивчылык фәнен дә укыта. Исмәт Бинаркның французча һәм инглизчә иркен сөйләшүен, төрки кавемнәр әхвален аек акыл белән өйрәнүен һәм анализлавын, аларның һәркайсына дусларча булышырга тырышуын, кыскасы, тирән белемле, киң карашлы, ярдәмчел кеше булуын Казанда да күпләр искәргәндер. Шулай ук Исмәт бәйнең Төркиядә милләттәшләребез чыгарган «Казан» журналына да язышуын искәртү урынлы булыр. Ул аның 18 нче санында «Казан татарларында матбагачылык мәйданындагы хезмәтләр» мәкаләсен бастыра, 23 нче санда дөнья күргән бер рецензиясендә бер фин галименең татарлар турында нинди мәгълүматлар бирүен хәбәр итә. Исмәт бәйнең Татарстандагы кайбер мәгариф-мәдәният оешмаларына, аерым укымышлыларга Әнкарадан кыйммәтле басмаларны бүләк итеп җибәреп торуын да рәхмәт хисе белән телгә алырга кирәк.

Татарстанның табигате гүзәл, халкы матур. Татар әдәбияты, сәнгате профессиональ яктан югары, гыйльми учаклары көчле, — диде ул миңа. — Төркиянең иҗтимагый тормышында тирән эз калдырган күренекле шәхесләрнең — Төркиядән читтә туып үскән бөек галимнәрнең ни өчен безгә күбрәк Идел-Уралдан килүен мин шушында аяк баскач яхшырак аңладым. Рәхмәт сезгә Әмма... хәтерегез калмасын, мин Татарстаннан ике нәрсәгә бик нык борчылып китәм: хәмер эчү киң таралган монда. Анна-ры... ят милләт, ят дин вәкилләре белән никахлашу чамасыз күбәйгән икән. Яшисе килгән милләт бу афәтләрдән арынырга тиеш.

Дөрес сүзгә җавап юк, дигәндәй, мин бу кимчелекләребез хакында сүзне озайтырга теләмәдем. Наилә ханым Бинарк исә иренең игътибарын бүтән нәрсәләргә юнәлтте.

Дүрт ел элек Казанга кызыбыз килгәндә, долларын совет акчасына алыштыра алмый интерәгән. Шәһәрдә бер генә җирдә өйләгә ка-

ләр генә алыштыра торган булганнар. Ә хәзер кара, бик күп урында акча алыштыру кассалары эшли. Дүрт ел элек Болгарда иглизәрләр өчен затлы сервис оештырылмаган, ә хәзер күр, нинди матур чатырханәләр, ресторан корылган. Казанда күпме татар гимназияләре, мәктәпләре ачылган. Әйбәт үзгәрешләр бара Татарстанда!

— Телевидениедә җитди татарча тапшырулар юк, — дип дәвам итте Исмәт бәй. — Җыр да бию, алар да күп түгел.

— Аның каравы архивлары җитди. Әнә нинди матур журнал чыгара башлаганнар. «Гасырлар авазы» — исеме дә, җисеме дә күңелгә ятышлы.

— Анысы өметле, — дип килешә Исмәт Бинарк. — Мин татар кардәшләрнең бик озак караңгы дәвер кичерүен беләм. Иншалла, Татарстан аякка басар. Араларыбыз якынаер.

Наилә Камай кызы Бинарк — мөһаҗир милләттәшләребез арасында күпләргә билгеле зат. Ул — «Казан» журналын чыгарган кадерле ни, Мәхмәт Акиф, Габделвәһап Йортсөяр хакында мәгълүматлар бирә, Алтын Урда тарихын яктырта, Казан ханлыгына игътибар юнәлтә. А.Халиковның «Татар халкының килеп чыгышы» китабын таныта һ.б. Тематик мәкаләләре, хәбәрләре дә байтак. Шунысын да онытмыйк, «Казан» журналы җәмәгать башлангычында өч айга бер мәртәбә 64 бит күләмендә чыга, Наилә ханым ун ел буе шуны яшәтү өчен кайнарланып эшли, аны таратуга күп көчен бирә. Түләнми торган, бушлай хезмәт!



килгән бергәлек

каләм иялэребезнең берсе, аның редколлегия әгъзасы һәм иң еш язган авторларының берсе. «Казан»ның баш мөхәррире Надыйр Дәүләт булса, укучыларга милли аң кертү, аларда милли горурлык тәрбияләү буенча ул журналда Наилә Бинарктан да күбрәк, нәтиҗәлерәк эшләгән бүтән берәүне күрсәтү кыен. 23 саны чыккан (1970—1980) «Казан»да мин аның утызлап мәкаләсен барладым. М.Акъегет. Ф.Әмирхан, Г.Тукай, Г.Исхакый, Й.Акчура, С.Максуди, Г.Баттал, Р.Рәхмәти, С.Гыйффәт, Г.Инан, Сөембикә — аларның һәммәсенә махсус мәкаләләр багышлаган ул. Халык әкиятләре, мәзәкләре, җырлары, Г.Тукай, З.Нури, Ш.Гали, З.Туфайлова шигырьләре, мәкаләләре журналда төрекчәгә Наилә ханым тарафыннан тәрҗемә итеп бирелә. Ул татар укучысын кардәш төрек һәм бүтән халык галимнәре, язучылары белән таныштыруга да өлеш кертә — Әл-Бируни,

Наилә 1940 елда Кореяда туа, 1948 елда аның гаиләсе Төркиягә күчеп килә. 1963 елда ул Истанбул университетының китапханәчелек бүлеген булачак ире Исмәт белән бергә тәмамлый. Озак еллар төрек мәдәнияген өйрәнү институтында эшли. Татар мәдәни һәм ярдәмләшмә җәмгыятен яшәтүчеләрнең берсенә әйләнә. 1971—73 елларда исә аны Финляндия татар җәмгыяте балаларга татар һәм төрек телләрен укытырга чакыра.

Наилә ханым шушы дәвердә һәм бераз соңрак мөһаҗир татар балаларын укыту өчен үзе дәреслекләр язып бастырырга мәҗбүр була, «тимер пәрдә» ул чакта Казаннан дәреслекләр алдырырга мөмкинлек бирми. Әнә шулай «Ана теле һәм уку китабы» өч кисәктә (Һилсинки, 1972—73. 74, 89, 42 б.б.), «Бераз уйла, бераз көл» (Һилсинки, 1973, 135 б.), «Аталар сүзе» (Һилсинки, 1976, 111 б.) җыентыклары дөнья күрә. «Төрек култүре», «Әмәл», «Кардәш әдәбиятлар» журналларында күренекле шәхесләребезне таныту, «Төрки тел һәм әдәбият энциклопедиясе»ндә татар зыялылары һәм әдәбиятыбыз турында белешмәләр бастыру — болар белән генә әле Наилә ханымның бөтен язучылык хезмәте саналып бетми.

Ул төрек теленнән тыш, туган телең һәм инглизчәне дә яхшы белә, ике бала үстерә. Тарихи ватаны белән даими кызыксынып тора, анда сталинчылык афәте бик озакка капат җәюенә кайгыра.

— Без үскәндә Төркиядә татарның бөек уллары киң колач җәеп эшли иде, алар бик абруйлы иде, — ди Наилә ханым. — Без моның белән ифрат горурлана идек. Әмма шул мәшһүрләребезгә туган илкәйләрен кайтып күрергә насыйп булмады. Рәшит Рәхмәти, Хәмит Зөбәер абыйлар чикләрнең бер заман ачыласына да ышанмадылар. Әхмәт Тимер картайды, күзе зәгыйфьләнде, юлга чыгарга җөрьәт итми. Мин аларны бик кызганам. Ә мин, шөкер, бабаларыбыз яшәгән изге туфракка аяк баса алдым. Социализм «оҗмахы» турында күп ишеткән, күп укыганлыктан, мин Татарстанга әллә нинди шәп нәрсәләр күрермен дип килмәдем. Шуңамы, мондагы күренешләр, мондый тормыш белән танышкач, шатлыгым арткаңнан-арта бара. Шөкер, мин борчылганча начар түгел икән илкәем. Табигате бик матур, урамнары киң, чиста, суы күп. Халык матур киенә, кибетләре дә буш түгел.

Наилә ханым Истанбулдан Казанга өч сәгатьтә килүне могҗиза саный, хәзер Төркиядә укып яткан татар яшьләренең Татарстанны киләчәктә тагын да үзгәртәчәгенә, үстерәчәгенә ышана.

— Халыкка ата-бабасын таныту, балаларны милли тарих белән таныштырып тәрбияләү әһәмиятле,— ди ул. — Шөкер, хәзер шуңа яраклы китаплар, дәреслекләр дә чыга башлаган икән. Сез Исмәт әйткәннәргә үпкәләмәгез, ул бары тиз тизрәк аякка басуыгызны гына тели.

Бинарклар республикабызга рәсми кунак булып килделәр. Архив өлкәсендә Татарстан—Төркия хезмәттәшлеге килешүенә кул куелды. Безнең хезмәттәшлек тагын бер тармакта җитди дәүләтара килешү нигезендә дәвам итәчәк. Кунаклар белән очрашканда аксакал язучыбыз Әмирхан Еники: «Төрек-татар бәйләнешләренең ерактан килә торган бай үткәне бар», — диган иде. Табигый ки, аның киләчәге дә шундый булырга тиеш.



Без Төркия дәүләт архивларының генераль директоры Исмәт Бинаркның Татарстан архив идарәсенә Казан ханы Олуг Мөхәммәтнең 1427 елда Төркия солтаны Моратка язган хатын бүләк итеп алып килүе турында хәбәр иткән идек. Әлеге рәсемдә сез күргән бу хатта, борынгыдан килгән гадәт буенча, үзара илчеләр җибәрешеп, хат-сәлам алмашып, дус булып яшик, дигән теләк белдерелә. Шулай ук үз илендәге яңалыклар, шул исәптән ханлыкта булып алган ызгыш-талаштан соң, тәхетне үз кулына алуы турында, соңгы берничә елда кыш чыгар өчен копьяк тобәкләргә күчеп килеп-китеп йөрүләре хакында хәбәр ителә.

ГАЛИМ МӨНБӘРЕ

Ялгызлык исемнәре һәм безнең хәят

(Очерк-эссе)

Гомәр САТТАРОВ-МУЛИЛЛЕ,
филология фәннәре докторы, профессор, Казан дәүләт университетының татар теле кафедрасы мөдире, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе.

1. Ономастика — исем-атамалар фәне

Туган өен белмәгән,
Туган авылын белерме?
Туган авылын белмәгән,
Туган илен белерме?

(Татар халык мәкале)

Кеше өчен бу дөньяда туган йорт, әти-әни туганнар, балалар, туган җир, туган ил, халык, милләттән дә олырак төшенчәләр юктыр. Һәркемнең шушы дөньяви берәмлекләргә ихласи хөрмәтләве кемнең кем булуын бик ачык күрсәтә

Кем соң син?
Туган җир, авылын тарихын,
Нәселең агачы — шәҗәрәң,
Бабаңнар кемлеген белмәсәң,
Исемеңнең мәгънәсен төпченми,
Җисемеңнең асылына төшенми
Хак биргән гомереңне үткәрсәң —
Заяга, барсы да заяга
Гомер су-елгадай тиз ага;
Кыл гамәл, исемеңнән-җисемеңнән
Нур — ядкарь калдыр син дөньяга.

Менә шуңа туган республикабыз авылларының тарихын, атамаларының килеп чыгышын, нинди мәгънә белдерүен, татар исем-фамилияләренең барлыкка килү, формалашу һәм үсеш-кулланылыш тарихын, үзенчәлекләрен өйрәнү гуманитар фәннәр (тел белеме, ономастика, тарих, археология, география, этнология, этногенез, эстетика, этика, мифология, философия һ.б.) алдында торган бурычларның гаять мөһиме булып санала. Чөнки җирле географик объектларның атамалары-топонимия; кеше исемнәре, кушаматлар һәм фамилияләр-антропонимия, тулаем алганда, ономастика (грекча «исем кушу сәнгате» төшенчәсен белдерә торган фәнни термин) — «тел чаралары белән бәян ителгән тарих» Шунлыктан, татар халкының тарихын һәм этногенезын өйрәнү ихтыяҗы топонимиябезне, шул исәптән торак пункт атамаларын — ойконимнарыбызны махсус тикшерүне һәм антропонимиябезне (төрки яки башка чыгышлы кеше исемнәре, кушаматлар һәм фамилияләребезне) эзлекле һәм җентекле итеп өйрәнүне таләп итә.

Соңгы 25-30 ел эчендә Татарстан авылларының тарихын һәм исемнәренең килеп чыгышын фәнни нигездә, фактик материалларга таянып, тарихи-лингвистик яссылыкта өйрәнү эше шактый җанланды, тулаем алганда, татар ономастика фәне сизелерлек дәрәҗәдә үсте.

Казан университеты нәшриятында 1970 елда урыс телендә басылып чыккан «Этапы развития и очередные задачи татарской ономастики» дигән тәүге китабымда татар ономастикасы фәне үсешенең өч этабы — (X гасырдан алып, бүгенге көнгәчә вакытны үз эченә ала) бәян ителде һәм татар ономастикасы фәне алдында якын киләчәктә өйрәнелеп хәл ителергә тиешле чираттагы 20 гаять мөһим һәм әһәмиятле төп бурыч күрсәтелде. Аларның байтагы эзлекле рәвештә тормышка ашырыла килә.

1973 елда шулай ук Казан университеты нәшриятында Татарстан АССРның антропотопонимнары («Татарстан авылларының исемнәре») дигән зур күләмле монографиям басылып чыкты. Бу хезмәттә кеше исемнәре, кушаматлар һәм фамилияләргә (антропонимнарга) нигезләнеп барлыкка килгән татар авылларының кыскача тарихы, исемнәренең килеп чыгышы һәм мәгънәсе шактый җентекле һәм эзлекле итеп тикшерелде.

Төркологиядә, ономастика тармагында иң беренчеләрдән булып, 1975 елның 5 мартында «Татарстан АССРның антропотопонимиясе» дигән темага докторлык диссертациясе якладым. Анда асылның килеп чыгышы (генезисы) һәм мәгънәсе тарихи-лингвистик аспектта тикшерелеп шәрехләнгән. Чөнки, Казан лингвистика мәктәбенә нигез салучы атаклы тел галиме Н.Бодуэн-де-Куртенэ язганча, тел гыйлемендә сүзлектән башка «хәтта иң даһи теоретик нәтиҗәләргә дә фактик нигезләү җитешмәячәк. Шушы фикерне куәтләп, бөек француз язучысы Анатоль Франс сүзләре белән әйтсәк: «Исем-атамалар-сүзләр, сүзләр-сурәтләр, ә сүзлек — алфавит тәртибендә бирелгән тулы бер дөнья ул».

Шәкертем, филология фәннәре докторы, профессор Фирдәүс Гарипованың 1994 елда Татарстан китап нәшриятында «Авылларны сөям җаным-тәнем белән» дигән фәнни-популяр очерклардан торган китабы басылып чыкты. Китап милли мәктәпнең җиденче сыйныф укучыларына адресланып, Татарстандагы тарихи урыннарга, авылларга, алар янындагы урман, елга, инеш, чишмә-кизләү, тау, болын, үзән һ.б. күрү һәм өйрәнү-белү өчен экспедиция-сәфәр ясау һәм анда күргәннәр, аксакаллар сөйләгән тополегенда-риваятьләр, галимнәр әйткәннәр тәсдыйк ителү белән бергә, авторның тегe яки бу авылның тарихына, исеменең килеп чыгышына карата үз караш-фикерләре бәян ителгән. Бу хезмәттә республикабыздагы 63 татар авылының (Алат, Каракүл, Кавал, Ашыт, Чыршы, Ташсу, Җөри, Яуширмә, Байсар, Каратмән, Карагуҗа, Күгәй, Күгеш, Айдар, Казиле, Карашәм, Аю Көйдергән һ.б.) кыскача тарихы һәм исемнәренең килеп чыгышы яктыртылган. Күп кенә микротопонимнар теркәлгән һәм байтагының килеп чыгышы тиешенчә шәрехләнгән.

Әмма, авыл атамаларына урын биргәндә, автор ни өчендер алфавит тәртибен сакламаган Бу исә китап белән эш иткәндә билгеле бер кыенлык тудыра. Элгәрләр тарафыннан әйтелгән фикерләрнең чыганаклары һәр очракта да тиешенчә күрсәтелмәгән. Менә шуңа бу китапта тегe яки бу авылның тарихына, атамасының килеп чыгышына карата элек әйтелгән фикер-карашлар Ф.Гарипованың фикер-карашы булып киткән. Авторның Татарстандагы байтак кына татар авыллары исемнәренең килеп чыгышын нугайларга һәм аларның ыруг-кабилә атамаларына (этнонимнарына) кайтарып калдыру белән артык мавыгуы күзгә ташлана Мәсәлән, бу хезмәттә Байсар, Тазлар, Кариле, Карадуган, Сарман, Бадрак һ.б. авыллар атамаларының нугайларга нисбәтле рәвештә барлыкка килүе тиешенчә расланмаган, башка карашлар кирәгенчә исәпкә алынмаган яки дәлилләп кире кагылмаган.

Татар халкын формалаштыруда XY-XYI йөзләрдә нугай кабилә-кавемнәренең катнашуын һич тә инкарь итмибез Хәлбуки, Казан татарларын, гомумән, Урта Идел һәм Урал буе татарларын, этник яктан формалаштыруда арка баганасы булган болгар компоненты белән бергә Алтын Урда чорында бигрәк тә һәм соңрак та зур роль уйнаган кыпчак-татар компонентын башлыча нугайларга гына кайтарып калдыру тарихи чынбарлыкка туры килми. Төрки телләрнең кыпчак төркеменә карый торган 10 халыкның — татар, казакъ, кыргыз, башкорт, каракалпак, кумык, карачай, балкар, нугай, караимнар һәм өлешчә башка төрки тел төркеменә керә торган төрки халыкларның (үзбәк, кырым татары, гагаузлар һ.б.) этногенезында гомумкыпчак кабилә-кавемнәренең (мәсәлән, аргын, барын, ширин, кыпчак, каңглы, адай, мангыт һ.б.) катнашуы тарихи мәгълүм.

Идел-Кама болгарлары һәм аларның төп варислары — Идел-Урал татарлары шактый борыннан уртак тормыш алып барганга, аларда ыруг-кабилә атамалары күптәннән юкка чыккан Менә шуңа Татарстан туфрагындагы һәм татарлар яши торган башка төбәкләрдәге татар этнотопонимнары Идел татарлары этносында катнашкан ерак бабаларыбызның ыруг-кабилә атамаларын ачыклауда һәм татар халкының этник компонентларын тикшерүдә гаять зур әһәмияткә ия. Татарстан (киңрәк мәгънәдә Идел-Кама-Урал төбәге) этнотопонимнары һәм башлыча төрки этнонимнарга нигезләнеп барлыкка килгән татар авыллары атамаларының төрки телләрнең кыпчак төркеменә карый торган башкорт, казакъ, каракалпак, кыргыз, нугай, кырымтатар һәм башка төрки халыклар ыруг-кабилә атамалары (этнонимнары) белән параллельлеге һәм тәңгәллеге, һичшиксез, урта гасырларда Идел буе татарлары этносында төрле кыпчак кабилә-кавемнәре төркемнәренең катнашуы турында ачык сөйли. «...наряду с именем «татар» в западной части Золотой Орды существовали старые племенные названия. Этноним «кыпчак» сохраняется наряду с географическим термином «Дешт и-Кыпчак» довольно долго, но имя «кыпчак» утратило этнический смысл, обозначающий кочевую народность, стало обозначать бекский род. Нетрудно найти общие имена в родоплеменной номенклатуре ногаев XYI-XYII вв., башкир...», — дип яза Алтын Урда тарихының танылган белгече Г.А Федоров-Давыдов «Общественный строй Золотой Орды» (М., 1973) дигән хезмәтендә.

Билгеле булганча, XY гасыр — XYI гасырның яртысында башкорт җирләрендә Нугай ордасының хакимлек итүе нугай-башкорт этник катнашуларын барлыкка китергән. «Относительная быстрота и легкость ассимиляции ногайцев в башкирской среде объясняется общностью мощного кыпчакского компонентов в этническом формировании обоих народов. В составе башкир и ногайцев имеется целый ряд этнонимических параллелей, восходящих и кипчакской эпохе: кипчак, канлы, туркмен, найман, бадрак, таз, мин, кырк, миркит», — дип яза күренекле этнограф — галим Р Кузеев «Происхождение башкирского народа» (Изд. «Наука», 1974) дигән мәгълүм хезмәтендә. Менә шуңа Урта Идел — Урал татарларының тарихи күршеләре башкорт һәм нугай ыруг-кабилә атамаларының параллельлеге тегe яки бу татар этнотопонимының асылында кайсы төрки-кыпчак халкы (башкортныкымы, нугайныкымы, әллә башканыкымы) ыруг-кабилә атамасы (этнонимы) ятуын, тарихи, этнографик, генеалогик, географик һ.б. өстәмә мәгълүматлардан тыш, кистереп әйтү-раслау өчен зур кыенлык тудыра. Менә шуңа Ф Гарипованың Бадрак, Тазлар, Байсар, Карадуган һ.б. кебек татар этнотопонимнарының барлыкка килүе нугайларга нисбәтле дип каравы шактый бәхәсле. Безнең һәм башка галимнәрнең тарихи-лингвистик тикшеренүләре әлеге татар авыллары атамаларының башкорт ыруг-кабиләләре этнонимнарына нисбәтле рәвештә барлыкка килүләрен күрсәтә.

(Дәвамы бар).

Дүшәмбе

18 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

...8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.35 Мультфильм. 18.45 Балалар ... «Тамчы». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.40 «Түгәрәк өстәл». Реформалар программасы: ул булырга тиеш? 20.20 ...«Әлли-бәлли-бәү» 20.30 «Гармуннар һәм ...» Рөстәм Вәлиев уйный. 20.45 Нәфис ... «Братья Карамазовы». 1 нче серия. ...55 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

...0 «Зарядкага басыгыз!» 7 10 Мультфильм: ... 7.30 «КиноМеню». 8.00, 10.55 ... «Юл патруле» Атналык йомгак. 8.10, ...35 — «Даруханә» 8.20 «Сул аяктан!» ...(MTV) 9.20, 13.35 — «90х60х90». 9.35 Мультсериал: «Еноты». 10.00 Балалар өчен сериал: ...овый всадник» 11.10 Спорт атнасы. ...0 «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 12.10 ... фильм: «Это все о нем...» 13.20 Кино ...касы. 13.50 «Валюта бәясе». 14.00 CNN. ... яңалыклары. 14.30 Атна һәлакәтләре. ...«Планета кайтавазы». 15.30 «Фитиль». ...17.30 Нәфис фильм: «Не бойся, я с то...» 17.00 «Минем тарих». Вячеслав Стар... 19.00 «Эфирда — музыка»: «Сәяси ...» 19.30 «Видеомода». 19.50 «Кызлар ... матурлар». 20.20, 22.55 «Шәһәр» информацион программасы. 20.45 «Лариса» яңа...ры. 21.15 Телеэкспресс. 21.35 Нәфис ... премьерасы: «Прах и кровь». 22.30 ...ональ хроника тележурналы». 23.20 ... фильм: «Мои счастливые звезды» (...).

1 НЧЕ КАНАЛ

...сәгать 3 кә кадәр техник чараларга ...филактика үткәрелә.

...0, 0.45 Яңалыклар. 15.20 «Спортның җи... кесе». 16.00 Мультсериал: «Отвержен...» 16.25 «Йолдызлар сәгате». 17.00 «Шпа...». 17.05 Яшьләр сериалы: «Элен и ре...». 17.30 «Тет-а-тет» 18.00, 21.00 — «Ва...». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен ...». 20.00 «Әгәр». В.Познерның авторлык программасы. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». ... Тапшырулар программасы. 21.55 ...белән очрашу. 22.10 Телесе... «Рейли — король шпионов» 4 нче се.... 23.10 «Юрамалар» 23.30 «Футбол күзә...». 0.0 Ир-ат һәм хатын-кыз.

Төнге канал

... Сериал: «Улицы Сан-Франциско». 1.55 ...ның җиде көне. 2.25 «Җыр — 95».

«РОССИЯ»

... Эшлекле кешеләр вакыты. 8.00, 11.00, ...17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.25 ...лар сөйли». 8.30 Клип-антракт. 8.35 ...». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 Төп ... 9.05 Өй экраны. Нәфис фильм: «Суд...». 10.15 XX гасыр кадрда һәм кадр ... «Хәтерләребезгә мәңгелеккә ...». 11.05 Милиция хроникасы. 11.15 Те... 11.20 Телеспектакль: «Любителям ...». 11.45 Мульти-пульти: «Ромка, ... и Атос». 12.15, 17.20 «Яңа тармак». ... 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.05 ...шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәй...». 16.30 Мульти-пульти: «Карлсон вер...», «Во дворе». 17.50 «Минем су... А.Киселев. 18.20 Алыргамы-алмаска... 18.30 «Коткару-911». 19.25 «Сабый авы...». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Дүшәм... детектив. «Инспектор Морс» сери... нәфис фильм: «Тайна Парковки ...» (Бөекбритания). 21.40 Репортер. 22.00 ...сәгать мизгеле». А.Караулов сораула... Россия Федерациясе федераль чик буе ... директоры А.Николаев җавап бирә. ... «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». ... Төнге телесериал. Нәфис фильм: «Бер... Александр Платц».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

...сәгать 1 дән кичке сәгать 6 га кадәр ... чараларга профилактика үткәрелә.

... 15.30, 22.40 «ТВ мәгълүматлары». ... Мультфильмнар: «Серебристый коло...», «Сказание о Кудым-Оше». 13.50, 15.45 — «Музыка мизгеле». 14.00 ...ярдәм». 14.30. Телефильм: «Ману...». 15.15 «Бакчачыларга киңәшләр» 15.50 ...кино. Нәфис фильм: «Танго на Двор...площади». 17.00 Телефильм: «Вуок...». 17.10 «Блокада балалары» 17.55 «Әкият ... әкият». «Про жидкие камни». ...Җыр эшләре. 22.55 «Спорт, спорт, ...» 23.15 Музыкаль-шоу: «Телеком-...». 0.15 Тхэквондо Икенче Европа чем-...

Сишәмбе

19 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00- -8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.15 «Ералаш» киножурналы. 18.25 «Ритм. Ритмика. Актер» 19 00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет» Тапшыру анонслары. 19.35 Профсоюзлар: үзгәрешләр вакыты. 20.05 «Әлли-бәлли-бәү». 20.20 «Тукталыш» 20.35 Күп серияле нәфис фильм премьерасы: «Тарзан» 12 нче һәм 13 нче серияләр (Мексика — Канада — Франция). 21.20 «Шигърият» Мөхәммәт Мирза. 21.40 Композитор Рөстәм Яхин романслары һәм җырлары. 22.05 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7 10 Мультфильм: «Фаэтон — сын солнца» 7.30, 20.20, 23.35 — «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (18 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.20 «Сул аяктан!» (MTV). 9.15, 13.35 «90х60х90». 9.30 Мультсериал: «Еноты». 9.55 Балалар сериалы: «Неоновый всадник». . 11.00 «Юл патруле». 11.15 Атналык фаразлар. 11.40 «Даруханә». 11.55, 18.25 «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 12.15 Нәфис фильм: «И это все о нем...». 6 нчы серия. 13.25 Кино музыкасы. 13.50 «Валюта бәясе». 14.00 CNN. Бизнес яңалыклары. 14.30 «Минем кино». Лев Дуров. 15.00 «Музыка һәм матбугат». «Каләм осталары». Тамара Гвардцетели. 15.55 Кирилл Лавровның тууына 70 ел тулуга карата — Горький исемендәге Зур драма театры спектакле: «Мещане». 18.45 Сериал: «Против течения». 3 нче серия. 19.35 Мультфильм: «Чинк». 19.50 «Кызлар һәм матурлар». 20.45 «Коммерция әйләнмәсе». 21.05 Эфирда — музыка. 21.15 Телеэкспресс. 21.35 «Татсоцбанк»: читтән караш. 21.40 Электроника һәм сәнгать. 22.05, 0.00 Русия киносы көне. Нәфис фильм: «Депрессия». 1 нче һәм 2 нче серияләр.

АТНАЛЫК МАНЗАРА TV

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 1.00 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.55 «Әгәр...» В.Познерның авторлык программасы. 11.35 «Ел буе — яшелчә бакчасы». 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телефильм: «Крах инженера Гарина». 1 нче серия. 14 10 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Футбол күзәтүе». 16.00 «Кара, тыңла». 16.20 «Кактус һәм К». 16.30 «Веселая квампания» кварьетесы». 16.40 Сер итеп кенә. 17.00 Кыска яңалыклар. 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.30 «Джем». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Тема». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 «Беренче куллардан». 22.05 Клара Лучко һәм Алла Ларионова «Двенадцатая ночь» фильмында. 23.45 «Юрамалар». 0.05 Телешоу: «50 X 50».

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20:00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 «Клип-антракт». 8.35 Ритмика. 8.50 «Кирәк... кирәк...» 11.05 «Милиция хроникасы». 11.15 Телегазета. 11.20 Документаль фильмнар: «Кочелаевская палитра», «Певец России отдаленной» 11.50, 17.45 Мультсериал: «Камень сновидений» (Бөекбритания). 12.15, 16.20 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.50 «Ай тотучы».17.20 «Беркем дә онытылмаган». 17.25 «Алты сутый». 18.10 «Көтү залы».18.55 Шахмат буенча дөнья беренчелегенә. Г.Каспаров — В.Ананд. 19.10 «L» клубы. 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Нәфис фильм: «Привет, мамочка!» 22.15 Михаил Боярский доминосы. 22.45 Криминаль хәбәрләр экраны. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 Төнге телесериал. Нәфис фильм: «Берлин. Александр Платц» 8 нче серия (ФРГ).

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7 00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 — «Тәҗрибә». 8.15 «Әдәплелек». 8.45 «Оборона». 9.40 «Рекордлар». 10.00 Төш юрау. 10.48 «Кумиркордлар». 11.15 «Аукцион». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00, 15.30, 22.40 «ТВ мәгълүматлары». 13.25, 13.50 «Музыка мизгеле». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телефильм: «Мануэла». 15.15 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.40 «Көз» кинопалы. Нәфис фильм: «Приходите завтра». 17.20 «Кем сез, месье Синема?» 17.50 «Ботен Россия буйлап». 22.15 Консерватор 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 «Консерватор»га өстәмә. Нәфис фильм: «Зеркало для героя»

Чәршәмбе

20 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00- 8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.50 мультфильм. 19.00 «Татарстан» 19.30 «Телебуклет» Тапшыру анонслары. 19.35 «Куркыныч яңәшәдә булганда .» Республика медицина һәлакәтләр үзәге 19.45 «Әлли-бәлли-бәү» 19 55 Әлфия Авзалова җырлый. 20.20 Нәфис фильм: «Братья Карамазовы» 2 нче серия. 21 25 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7 10 Мультфильм: «Тир» 7 30, 20.20, 23 55 «Шәһәр» информацион программасы. 7.50 Телеэкспресс (19 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.20 «Базар» журналы. 8.50 «Йөзгә йөз белән: Сараево-Белфаст» 9.45 «Палитра. Ян Ван Эйк» 10.15 «Европа сәхнәсе» 10.45 «Гасырлар чоңгылыннан: осталар» 11.45 Мәскәү Кремлендә бер сәгать. 12.45 «Танджерин Дрим, өч фаза» 13.45 «Бүгенге Европа» 14.10 «Атна низаглары» 14.40 А.Вайда фильмы: «Сибирская леди Макбет» 16.20 Рей Брэдбери: «Гимн башланганчыга кадәр спринт» 16.50 Маҗаралы сериал: «Филипп Марлоу — частный детектив» 17.45 «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 18.00 «Юл патруле» 18.10 Майкл Джексон. 19 10 Мультфильм: «Глаша и кикимора». 19.25 «Поза» 19.50 «Кызлар һәм матурлар». 20.45 «Казан автосалоны» 21.15 Телеэкспресс. 21 35 «Үз кешеләр» 22.10 «Провер-150» депосы хатын-кызлар өчен яңа контрацептив чаралар. 22.10 Анни Жирардо «Говорите, мне интересно» комедиясендә. 0.20 «Smashing Pumpkins» группасы концерты.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә» 9.00, 12.00, 15.00, 1 05 — «Яңалыклар». 9 20 Телесериал: «Тропиканка» 10.10 «Тема». 10.50 «Хайваннар дөньясында». 11.35 Телеуен: «Мине аңла». 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телефильм: «Крах инженера Гарина». 2 нче серия. 14.10 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне». 16.00 «Күңелле ноталар» 16.20 «Читлектәге балалар». 16.30 «Первоцвет» балалар халыкара фестивале (Киев). 17.00 «Шпаргалка». 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.30 «Тип-топик» 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать» 19.35 Телеуен: «Көен таны» 20.00 Татлы хыяллар фабрикасы. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 Александр Михайлов «Похищение Савойи» маҗаралы фильмында. 23.35 «Юрамалар». 23.55 «Паузасыз» 0.20 Баскетбол. Суперлига чемпионаты. Ир-атлар. «Динамо» (Мәскәү) — «Аквариус» (Волгоград).

Төнге канал

1.25 Сериал: «Улицы Сан-Франциско». 2.15 «Спортның җиде көне».

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17 00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 Клип-антракт 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 «Төп мизгел». 9.05 «Пилигрим». Русиянең сәяхәтләр бюросы. 9.50 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 Милиция хроникасы. 11 15 «Телегазета». 11.20 А.Малинин җырлый. 11.50, 17.50 Мультсериал: «Камень сновидений» (Бөекбритания). 12.15, 17.20 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Кем ягы?» 18.15.«Өч гасыр дан». «Давыларда һәм тынлыкларда». 18.45 Шахмат буенча дөнья чемпионаты. Г.Каспаров — В.Ананд. 19.00 «Әйдәп баручы фаразы». 19.25 «Үз уены». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Өй экраны. «Телесериал: «Санта-Барбара». 21.30 «Богема».Д.Ольбрыхский. 22.40 Киноафиша. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 Био-экспресс. 23.55 Кыска метражлы нәфис фильмнар: «Один», «Никто не хотел уезжать».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 — «Тәҗрибә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 Балалар өчен. 9.20 «Гүзәллек». 9.40 «Күңел» 10.15 «Төш юрау». 10.40 «Такмаклар». 11 15 «Аукцион». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00, 15.30, 22.40 «ТВ мәгълүматлары». 13.25 Телефильм: «Военная музыка». 13.50, 17 10 — «Музыка мизгеле». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телефильм: «Мануэла». 124 нче серия. 15.20 Бакчачыларга киңәшләр. 15.40 В.Виноградов фильмнары: «Русский дом». 1 нче фильм. 17 15 Телефильм: «Неистовая Айседора». 17.45 «Әкият арты әкият». 22.25 «Хатирәләребез җырлары». Вениамин Баснер. Өченче тапшыру. 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 «Гыйбадәтханә» 23.40 Нәфис фильм «Зеркало для героя» 2 нче серия.

Пәнҗешәмбе

21 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00- 8.00 «Чулпан» информацион программасы 18 05 «Бишенче баскыч» Казан шәһәренең 13 нче балалар музыка мәктәбе хоры концерты 18 20 Мультфильмнар 18 50 «ГАИ мәгълүматлары» 19 00 «Татарстан» 19 30 «Хөкүмәт сәгате» 20 00 «Әлли-бәлли-бәү» 20 10 «Авыл» Кама Тамагы районында очрашулар 20 40 Стәрлетамак башкорт дәүләт драма театры бездә кунакта 21 10 «Җәйге бакчада» Концерт 21 45 Нәфис фильм «Братья Карамазовы» 3 нче серия. 22.55 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

6.55 «Зарядкага басыгыз!» 7 05 Мультфильм: «Волшебник Изумрудного города» 1 нче серия. 7 30, 20 20, 0.15 «Шәһәр» информацион программасы. 7 55 Телеэкспресс (20 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.20 «Сул аяктан!» (MTV). 8.55, 10.05 Балалар өчен сериал: «Неоновый всадник» 9 45, 13 35 «90х60х90» 11.00, 19.00 «Юл патруле» 11 15, 15 00 CNN «Стиль» 11 40 «Даруханә» 11 55, 18.45 «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 12.15 Нәфис фильм: «Богач, бедняк» 13 50 «Валюта бәясе» 14.00 CNN Бизнес яңалыклары. 14.30 Петр Шипотиппик «Кинескоп»ы. 15 30 Ток-шоу «Мин үзем» «Паспортка штамп нигә кирәк» 16.30 Нәфис фильм: «Вылет задерживается» 17 55 Маҗаралы сериал: «Филипп Марлоу — частный детектив» 19.10 Эфирда - музыка. 19 20 «Ушуайя» 19.40 «Заречье» банкы мәгълүмат бирә. 19 50 «Кызлар һәм матурлар» 20.45 «Коммерция әйләнмәсе» 21 05 «Казанские ведомости» нәрсә турында сөйләде» 21 15 «Телеэкспресс» 21.35 Тапшыру премьерасы: «Барытик көлке өчен генә» 22.05 «Минем пейджерым бар һәм мин тыныч» 22.10 Агна фильмы. Нәфис фильм: «Мадам Дюбарри» 0.35 Мишель Морган «Максим» комедиясендә. 2 нче серия.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә» 9.00. 12.00, 15.00, 0.45 «Яңалыклар» 9 20 Телесериал: «Тропиканка» 10.10 «Татлы хыяллар фабрикасы» 10.50 «Сәяхәтчеләр клубы» 11.35 Телеуен: «Мине аңла» 12.20 Эфирда – «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телефильм: «Крах инженера Гарина» 3 нче серия. 14.10 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне». 16.00 Мультипроллия. 16.20 «Золушкада балда» 16.40 «Тылсымлы дөнья, яки Синема» 17.00 Кыска яңалыклар. 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята». 17.30 «16 яшькә кадәр һәм өлкәнрәкләр...» 18.00, 21.00 «Вакыт» 18.20 Телесериал: «Тропиканка» 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать» 19.35 «Лотто-миллион» 20.00 «Югалтылганнарны эзләгәндә» З.Федорова. Тапшыруны Г Скороходов алып бара. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21 55 Мәскәү Кремль. 22.15 Ванесса Редгрэйв һәм Кристофер Рив «Бостонцы» тарихи драмасында. 0.25 «Юрамалар»

Төнге канал

1.05 Телесериал: «Улицы Сан-Франциско» 1.55 «Спортның җиде көне» 2.35 Джаз дөньясында.

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8.00, 11 00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр» 8.25 «Йолдызлар сөйли» 8.30 «Клип-антракт 8.35 «Ритмика» 8.50 «Кирәк.. кирәк...» 8.55 Клип-антракт О.Ходочинская. 9.00 Документаль фильм: «Время Мераба». 9.50 Телесериал: «Санта-Барбара» 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11 05 «Милиция хроникасы» 11 15 «Телегазета». 11 20 «Сезнең хокук» 11.35 «Үз-үзеңә оста» 11 50, 17 20 Мультсериал: «Камень сновидений» (Бөекбритания). 12.15 «Яңа тармак» 12.30, 14.20 «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.20 «Көн дә бәйрәм» 16.30 Яңа тармак. «Сүнгән йолдыз» 17.45 «Видеошигърият» С.Есенин. 17.55 Футбол. Россия чемпионаты. «Спартак» (Владикавказ) — «Спартак» (Мәскәү). Владикавказдан трансляция. 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара» 21 30 «Фортедан пьяноога кадәр» Ю.Мамин программасы. 22.05 «Гадәттән тыш канал» 23.30 «Вакыт елгасы» 23 35 «Автомизгел». 23.45 «Хроно. Авто һәм мотоспорт дөньясында» 0.15 «Криминаль хәбәрләр экраны»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7 00 «Хәерле иртә» 7 45, 11 45 «Тәҗрибә» 8.15 «Әдәплелек» 8.45 «Оборона» 9 15 «Гүзәллек». 9.40 «Рекордлар». 10 15 «Төш юрау». 11 15 «Аукцион». 12 15 «Спартак» 12.40 «Кунак». 13.00, 15.30, 22 40 «ТВ мәгълүматлары» 13 25 Балалар өчен телефильм: «Юлька, Васька и другие» 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телесериал: «Мануэла» 15 20 «Бакчачыларга киңәшләр» 15 40, 17 00 Музыка мизгеле. 15.45 Нәфис фильм: «Не болит голова у дятла» 17 10 Петербургта тирә-як мохитне саклау атналыгы. Документаль фильм: «Вода» 17 25 Балалар өчен телефильм: «Про ленивые колеса» 17 40 «Бөтен Россия буйлап». 22.55 «Спорт, спорт, спорт » 23 10 Бодибилдинг буенча халыкара турнир. «Россия Гран-прие»

ҖОМГА

22 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00 8.00 «Чулпан» информацион программасы 17.55 Мультфильмнар 18.35 «Биштәрне кем урлаган?» «Салават күпере» журналына биш яшь 19.00 «Татарстан» 19.30 «Видеоспорт» 19.45 Татарстан Дәүләт Советында 20.15 «Әлли-бәлли-бәү» 20.35 «Ислам чакыруы» 20.45 «Җомга көн кич белән». Альманах 21.25 «Зәй буе шомыртлары» Виталий Агапов җырлары 21.55 Барыбыз өчен дә хоккей 20.20 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Волшебник Изумрудного города» 2 нче серия 7.30. 20.20. 0.35 «Шәһәр» информацион программасы 7.55 «Телеэкспресс» (21 сентябрь тапшыруын кабатлау) 8.20 Нәфис фильм «Богач. бедняк» 9.35. 13.35 «90х60х60» 9.55 Балалар өчен сериал «Неоновый всадник» 10.50. 16.50 Юл патруле. 11.00 «Атнага бер тапкыр» юмористик программасы 11.30 «Даруханә» 11.40. 16.35 «ПОСТ – музыка яңалыклары» 13.05 Нәфис фильм «Богач. бедняк». 13.50 «Валюта бәясе» 14.00 CNN Бизнес яңалыклары. 14.30 «Нью-Йорк. Нью-Йорк» 15.00 Нәфис фильм «Игорь колеблется» 1 нче серия. 17.00 «01» журналы 17.30 «Бабиле-91» 18.30 «Барысын да белергә телим» 18.40 «Суперспорт» 19.00 Сериал премьерасы «Корабль любви» 3 нче серия 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.45 Тапшыру премьерасы «Серпент-клуб» 21.05 «Экология хәбәрчесе». 21.15 Телеэкспресс. 21.35 Сериал «Сирены» (АКШ) 22.30 Кинобестселлер «Экзорсист». 0.00 Кинокомедия «Римини. Римини» (Италия) 1.55 «Битлеклар» «Колумбия-2»дә.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә» 9.00. 12.00. 15.00. 1.55 Яңалыклар 9.20 Телесериал «Тропиканка» 10.10 «Югалтылганнары эзләгәндә» З.Федорова. 10.50 «Иртәнге йолдыз» 11.35 Телеуен «Мине аңла» 12.20 Эфирда – «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телефильм «Крах инженера Гарина» 4 нче серия 14.10 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне» 16.00 Балалар өчен телесериал «Белый клык» 16.25 «Орфей йолдызлыгы» 16.35 «Яңа чынбарлык». 17.00 «Шпаргалка» 17.05 «Рок-дәрес» 18.00. 21.00 – «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка» 19.10 «Кыргый кыр» 19.25 «Кеше һәм закон» 19.55 «Могҗизалар кыры» 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21.55 Телесериал: «Рейли – король шпионов» (Бөекбритания). 22.55 «Юрамалар». 23.15 «Караш» 0.10 Музыка күзәтүе 0.50 Теннис. Дэвис кубогы. Ярымфинал Россия һәм Франция җыелма командалары

Төнге канал

2.15 Телесериал «Улицы Сан-Франциско». 3.05 «Спортның җиде көне»

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8.00. 11.00. 17.00. 20.00, 23.00 «Хәбәрләр» 8.25 «Йолдызлар сөйли» 8.30. 11.20. 17.40 Клип-антракт 8.35 «Ритмика» 8.50 «Кирәк. кирәк...» 8.55 «Хакыйкать мизгеле» 9.50 Телесериал: «Санта-Барбара» 10.40 «Крестьян мәсьәләсе» 11.05 «Милиция хроникасы» 11.15 «Телегазета» 11.30 «Сәүдә йорты» «Ле Монти» 11.45 Мультсериал «Плюшевый кролик» 12.15 «Яңа тармак» 12.30. 14.20 «Эшлекле Россия» 16.05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.20 «Көн дә бәйрәм» 16.30 «Көнтерә» 16.50 «Ай тотучы» 17.20 «Беркем дә онытылмаган» 17.25 Шахмат буенча дөнья чемпионаты Г.Каспаров – В.Ананд. 17.45 Җомга саен Дисней Нәфис фильм «Великий Атлет» 19.25 Вертикаль «Хөкүмәтнең эш көннәре» 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 Телесериал «Санта-Барбара» 21.30 Теннис Дэвис кубогы Ярымфинал Русия – Германия. «Олимпийский» спорт комплексыннан тапшыру 22.25 Күңел ачу программасы «Шәһәрчек» 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.45 Телеэкран премьерасы Нәфис фильм «Луна-парк» (Россия Франция)

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә» 7.45. 11.45 «Тәҗрибә» 8.15 «Киноәче» 8.45 «Балалар өчен» 9.20 «Гүзәллек» 9.40 «Күңел» 10.15 «Төш юрау» 10.40 «Кумирлар» 10.45 «Такмаклар» 11.15 «Коллекционерлар» 12.10 Джаз 12.40 «Кунак» 13.00. 15.30, 22.40 «ТВ мәгълүматлары» 13.25 Телефильм «Беги. малыш беги» 13.50. 15.45. 18.55 «Музыка мизгеле» 14.00 «Ашыгыч ярдәм» 14.30 Телесериал «Мануэла» 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр» 15.50 Ура комедия! Нәфис фильм «Ключи от неба» 17.05 «Бәллүр ачкыч» Видеоклиплар фестивале 17.25 «ТВ мәгълүматлары Европа калейдоскобы»
22.25 «Алкышлап» Алена Апина 22.55 «Спорт спорт спорт...» 23.10 Чит ил киносы антологиясе Нәфис фильм «О любви» (АКШ) 0.25 Хоккей МХЛ чемпионаты «Крылья Советов» «Спартак»

ШИМБӘ

23 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00 8.00 «Чулпан» информацион программасы 19.00 «Татарстан» 19.30 «7 нче стиль». 20.00 «Әлли-бәлли-бәү» 20.20 «Мәңгелеккә күперләр» 20.45 «Әйтмә син авыр сүз...» Асаф Вәлиев концерты. 21.55 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Волшебник Изумрудного города» 7.30 «Шәһәр» информацион программасы 7.55 Телеэкспресс (22 сентябрь тапшыруын кабатлау) 8.10 «Коммерция әйләнмәсе» (19 сентябрь көнендәге тапшыруны кабатлау) 8.30. 11.30 «Эфирда музыка» 8.40 «Видеомода». 9.00 «Лариса» яңалыклары 9.30 «700 нче клуб» 10.00 «Казан автосалоны» 10.30 «Поза». 10.55 «Үз кешеләр» 11.40 «Чаплиниада» «Скиталец» 12.05 Хәрби телевидение. 12.40 «Спорт атнасы» 13.10 Мультфильм: «Следствие ведут знатоки» 14.50 Нәфис фильм «Птицы-хищники» (Италия). 16.25 Телесериал «Тропическая жара» 17.20 Телесериал «Детективы на полставки» 18.15 «Яшерен йомыш». 18.40 «Дублик» 19.00 «Исәнмесез!». 21.00 «Мавыгулар дөньясы». 21.30 Сериал. «Сирены» (АКШ). 22.30 Куркыныч фильм «Кэндимен» 0.10 Кинокомедия «Римини. Римини ~ год спустя»

1 НЧЕ КАНАЛ

7.30 «Иртә» 8.45 «Пастырь сүзе» Митрополит Кирилл 9.00. 15.00. 1.10 Яңалыклар. 9.20 «Джунглилар чакыруы» 9.50 Балаларга фильм: «Кешка и борода» 10.10 Мультфильм «Сон» 10.25 «Иртәнге почта» 11.00 «Татлы» 11.15 «Сәламәтлек». «Сезнең өчен медицина» 11.50 «Провинция Россиянең кече шәһәрләре» Ноябрьск. 12.20 «Бомонд». 12.40 Жюль Верн романы буенча фильм: «Похищенный дирижабль» 14.10 «Экслибрис» 14.25 «Көзге» 15.20 «Зур узышлар». 15.45 Мультфильм «Ракушка» 16.00 Нәфис фильм «Москва – Кассиопея» 17.20 «Хайваннар дөньясында» 18.00. 21.00 «Вакыт». 18.20 «Бәхетле очрак» 19.05 Мажаралы вакыйгалы боевик: «Телохранитель». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21.55 Телесериал: «Рейли – король шпионов». 22.55 «Брейн-ринг» 23.40 «Һәркемнең телендә». Н.Дарьялова алып бара. 0.05 Теннис. Дэвис кубогы. Ярымфинал. Русия һәм Германия җыелма комацдалары.

Төнге канал

1.30 Телесериал «Улицы Сан-Франциско». 2.20 «Кумирлар. кумирлар...» Тото Кутуньо.

«РОССИЯ»

8.00. 14.00. 20.00. 23.00 – Хәбәрләр 8.25 «Йолдызлар сөйли» 8.30 «Шөрептән башлап» 8.45 «РОСТ» компасы 9.00 «Винил джунглилары» 9.30 Пилигрим. Русиянең сәяхәтләр бюросы 10.15 «Хайваннар дөньясында» 11.10 «Ничек яшәрбез?» 11.55 А.Гурнов «Саф ишлизчә репортаж» 12.05 Көндезге сеанс Нәфис фильм «Капитан «Америка» 13.45 «Кайнар унлык» 14.20 «Де факто» 14.35 «Расследования комиссара Мегрэ» сериалыннан нәфис фильм «Комиссар Мегрэ и ленивый вор» 1 нче кисәк 15.25 «Безнең бакча» 15.55 Амика веритас Юристлар телеконкурсы 16.40 Без кем? «Курск губернасендә төре йортү мәләсиме» 17.10 «Синең мөмкинлекләрең, кеше!» 17.40 «Дөнья йолдызлары экраны» 18.10 Шахмат буенча дөнья беренчелегендә – Г.Каспаров – В.Ананд 18.25 «Русча караоке» 18.55 Теннис Дэвис кубогы Ярымфинал Русия – Германия «Олимпийский» спорт комплексыннан тапшыру 19.50 Клип-антракт 20.25 Оста фильмотекасыннан С.Бондарчук «Попрыгунья» фильмында 22.05 «Үтә яшерен» 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40 «Аваз юлы»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.30 «Христос – бөтен дөньяда» 8.00 «Хәерле иртә» 9.00 «Турыдан-туры элемтә» 10.00 Нәфис фильм «Как лисы с курами подружились» 10.25 Безнең кино Нәфис фильм «Ой, вы, гуси» 11.50 Телефильм «Забытые места» 12.10 «Рандеву» М.Шуфутинский 12.40 Ретроэкран Телефильм «Игорь Владимирович Ильинский Уроки жизни» 13.40 Теледоктор 14.00 Тест 14.15 «Тарихи альманах» 14.45 Нәфис фильм «Военно-полевой роман» 16.20 «Палитра» циклыннан телефильм «Рафаэль» (Франция) 16.55 Мультфильм «Яблоня» 17.05 Шәһәр экологиясе Түгәрәк өстәл 17.50 «Антре»
22.40 ТВ мәгълүматлары 23.00 Нәфис фильм «Последнее объятие» (АКШ)

ЯКШӘМБЕ

24 СЕНТЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 «Чулпан» информацион программасы 19.00 «ТОН» (атналык телекүзәтү) 19.35 «Автокалейдоскоп» 19.50 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 20.00 «Әлли-бәлли-бәү» 20.20 «Зәки абый» Сугыш һәм хезмәт ветераны З.Җәләлиев турында телеочерк 21.00 Р.Мингалим «Өченче бүлмәдә ят яшь» Әлмәт дәүләт драма театры спектакле 22.40 Татар романслары. 21.55 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7.00 Телеэкспресс (атналык тапшыруларны кабатлау) 8.30 «Коммерция әйләнмәсе» (21 сентябрь тапшыруын кабатлау) 8.50 «Бары тик көлке өчен генә» 9.20 «Ушуайя» 9.40 «Суперспорт» 10.00 «Серпент-клуб» 10.20 «Мавыгулар дөньясы» 10.50 «Дублик». 11.10 Мультфильмнар. 12.10 Виктор Мережко белән «Минем кино» 12.30 «Чаплиниада» «Джонни в кино». «Музыкальный бродяга» 12.55 Комедия. «Грехи Гарольда Диддлбока» (АКШ) 14.30 «Нью-Йорк, Нью-Йорк» 15.00 Телесериал: «Подводная «Одиссея» команды Кусто» «Трагедия красных лососей» 15.50 «Атна һәлакәтләре». 16.20 Нәфис фильм: «Молодая жена» 17.55 Телесериал. «Тропическая жара» 18.50 Телесериал: «Детективы на полставки». 19.45 «КиноМеню» 20.15 «Җирле вакыт» Информацион программа. 20.45 Кристин Лахти «Любовь живет» мелодрамасында». 22.30 «Исәнмесез!» (23 сентябрь тапшыруын кабатлау) 0.30 Комедия «Голая правда» (АКШ).

1 НЧЕ КАНАЛ

7.30 «Иртә» 9.00. 0.40 Яңалыклар 9.20 «Иртә таңнан». 9.50 Мультфильм: «Соловей». 10.10 «Бар да өйдә чакта» 10.45 «Бәллүр башмак». 11.30 «Россиягә хезмәт итәм». «Армия кибете» 12.00 Телесериал: «Лики Земли» 12.50 Бөтен Россия «Исәнмесез» 13.15 Композитор Александр Аверкин җырлары. 13.30 «Курчак йорты». 14.15 «Ап-ачык – акылга сыймаслык» 15.20 «Эфирда – музыка» 16.10 «Сәяхәтчеләр клубы» 16.55 Америка М.Таратута белән 17.25 Мультсериал: «Приключения капитана Врунгеля». 18.00 Вакыт 18.20 «Әйтеп торучы» 19.00 «Күзгә-күз». А.Любимов алып бара. 19.30 «Кумирлар. кумирлар...» Тамара Гвердцители 19.50 Шон Коннери «Бандиты во времени» мажаралы фильмында 22.00 «Якшәмбе» 23.05 Телесериал: «Рейли – король шпионов» 0.05 «Бер күрүдә ярату» 0.35 Теннис. Дэвис кубогы Ярымфинал. Русия һәм Германия җыелма командалары.

Төнге канал

2.00 Сериал «Улицы Сан-Франциско».

«РОССИЯ»

8.00. 14.00. 20.00. 23.00 Хәбәрләр 8.25 «Йолдызлар сөйли» 8.30 «Беренче дубль» 8.45 «Алтын ачкыч» 9.00 Сергей Есенин «Соңгы шагыйрь» 9.20 «Футболга чикләр юк» 10.05 «Хәерле иртә, Европа» «Чемпионнар өчен иртәнге аш» 10.35 «Аты, баты...» 11.05 «Консолидация» 11.10 «Рус лотосы» 11.55 Шахмат буенча дөнья беренчелегендә Г.Каспаров – В.Ананд 12.15 Көндезге сеанс Нәфис фильм. «Сентиментальное путешествие на картошку» 13.45 «Сезнең партнер «Русиянең тимер юллары» 14.20 «Кисеп бетерә алмаслык...» 14.35 «Расследования комиссара Мегрэ» сериалыннан нәфис фильм «Комиссар Мегрэ и ленивый вор» 2 нче кисәк. 15.25 Кипрас Мажейка «Параллельләр» 15.40 Тапшырулар тартмасы 15.55 «Формула-1» классында автоузышлар буенча дөнья чемпионаты Португалия Гран-прие Эшторилдан трансляция 18.00 Мультфильмнар «Чокнутый», «Новые приключения Винни Пуха» 19.00 Теннис Дэвис кубогы Ярымфинал Русия – Германия «Олимпийский» спорт комплексыннан тапшыру 20.25 Оста фильмотекасыннан С.Бондарчук фильмы «Ватерлоо» (Италия – СССР) 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40 «Ксюшада кунакта»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Бу сезнең көнегез» 7.30 «Шифалы сүз» 8.00 «Хәерле иртә» 9.00 «Турыдан-туры элемтә» 10.00 Мультфильмнар «Ценная бандероль». «Сказ о пере-богатыре» 10.25 Телеэкранда детектив Нәфис фильм «Черная кобра» (Италия) 12.00 «Якшәмбе лабиринты» 13.10 Балалар өчен нәфис фильм «Соловей» 14.30 «Карарбыз». 5 нче телеканал программасы анонслары 14.45 «Классика 5» 15.30 Депутатларга сүз бирәбез 16.00 «Страсти-мордасти» 16.15 «Алтын ачкыч» 16.25 «Кыргый аккошлар» Балалар рок-операсы 16.55 Футбол буенча Италия чемпионаты Турыдан-туры трансляция
22.10 Хоккей МХЛ чемпионаты «СКА» (СПб) «Динамо-М» (Мәскәү) 2 нче һәм 3 нче периодлар 23.15 ТВ мәгълүматлары 23.45 «Адәм һәм Хава шоусы»

R

ДҮШӘМБЕ, 18 СЕНТЯБРЬ

6.00, 19.15 Соңгы хәбәрләр 6.15 «Иртәнге дулкында» 6.53, 7.58, 20.13 Һава торышы 6.55, 7.50 – Белдерүләр 7.00 Информацион-музыкаль программа 7.45, 20.13 Тапшырулар программасы 8.00, 20.20 Радио-1 14.30 – Радио-1 «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе оркестры чыгыш ясый. (Яңа язмалар). 19.45 «Һәвәскәр башкаручылар концерты».

СИШӘМБЕ, 19 СЕНТЯБРЬ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.53, 7.58, 13.25, 20.13 – Һава торышы. 6.55, 7.50 – Белдерүләр 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.13 – Тапшырулар программасы. 8.00, 13.45, 18.30 20.20 – Радио-1. 12.25–14.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта. 12.30 Башкортстан артистлары концерты. 13.10 Республика газеталарына күзәтү 13.30 «Юллар чатында» информацион программасы. 18.00 «Яшьлек» студиясе 19.45 «Композитор З.Хәбибуллин әсәрләре».

ЧӘРШӘМБЕ, 20 СЕНТЯБРЬ

6.00, 7.00, 13.00, 19.15 – Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Татарстан дулкынында» 6.53, 7.58, 13.20, 20.38 – Һава торышы. 6.55, 7.50 – Белдерүләр. 7.15 Концерт 7.45, 12.25, 20.38 – Тапшырулар программасы 8.00, 13.25, 20.45 – Радио-1. 12.30 Концерт. «Без Татарстан җирендә яшибез». 13.05 Республика газеталарына күзәтү 19.45 Сораулар буенча концерт.

ПӘНҖЕШӘМБЕ, 21 СЕНТЯБРЬ

6.00, 7.00. 13.00, 19.15 – Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.53, 7.58, 13.20. 20.13 – Һава торышы. 6.55, 7.50 – Белдерүләр 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.13 – Тапшырулар программасы 8.00, 13.25, 19.30, 20.20 – Радио-1. 12.30 «Балалар җырлый» 13.05 Республика газеталарына күзәтү 18.05 «Бизнес клубы». 19.45 «Композитор Л.Хәйретдинова җырлары һәм инструменталь пьесалары».

ҖОМГА, 22 СЕНТЯБРЬ

6.00 «Балкыш». 6.53, 7.58, 13.25, 20.13 – Һава торышы. 6.55, 7.50 – Белдерүләр 7.00. 13.05, 19.15 – «Соңгы хәбәрләр» 7.15 Концерт 7.45, 12.25, 20.13 – Тапшырулар программасы. 8.00, 13.30, 20.20 Радио-1 12.30 Татарстанның атказанган артисты М.Сөнгатуллин концерты 13.10 Республика газеталарына күзәтү 19.45 «Кечке моңнар» Концерт

ШИМБӘ, 23 СЕНТЯБРЬ

7.00 Соңгы хәбәрләр. 7.15 Концерт 7.45, 14.30 Тапшырулар программасы 7.50 Белдерүләр 7.58. 14.30 Һава торышы 8.00, 11.00, 14.35 – Радио-1 8.15 «Сезнең хатларыгыз» 8.40 «Көмеш кыңгырау» 9.00 Татарстанның халык артисткасы В.Улик истәлегенә «Җәй үткәнс сизелми дә» 9.30 «Балкып яшәвен сөендерә» Г.Ахуновка 70 яшь 10.30 «Сәясәт һәм шәхес» 12.15 Татар халык көйләре 13.10 Яңалыклар эстафетасы 13.30 «Яшьлек» студиясе 14.00 «Көзге».

ЯКШӘМБЕ, 24 СЕНТЯБРЬ

7.02, 7.58, 13.40 – Һава торышы. 7.0 «Хәерле иртә!» 7.45, 13.40 – Тапшырулар программасы 7.50 Белдерүләр 8.0 «Идел белән Урал арасында» Алты республиканың берләштерелгән радиожурналы 9.00.16.00 Радио-1 12.45 Ял концерты 13.45 «Татарстан дулкынында» 14.25 Г.Ахунов «Хәзинә» Радиопостановка

ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ МУЗЕЕНА 100 ЕЛ



Бу көннәрдә Татарстан Республикасының берләштерелгән Дәүләт музее үзенең 100 еллык юбилеен билгеләп үтте. Музей Воскресенская урамындагы Сәүдә йорты бинасында (Ленин урамы, 2 нче йорт) урнашкан. Аны оештыруда Казан университетының күренекле галимнәре А.Штукенберг, Н.Загоскин, Н.Катанов, Н.Высоцкий кебек профессорлар күп көч куя. Төбәкне өйрәнүче энтузиастларның тырышлыгы нәтиҗәсендә Казан музее XX йөз башында ук Идел буендагы иң зур музейларның берсенә әверелә. 1890 елда Казанда уздырылган фәнни-промышленность күргәзмәсенең күп кенә экспонатлары музей фондларының нигезен тәшкил итә.

Алар арасында танылган археолог, тарихчы һәм коллекционер Андрей Лихачев туплаган экспонатлар аеруча күп була. Археология һәм этнография материаллары гына да 15 мең чамасы, тагын 20 меңнән артык акча һәм медальләр, күпсанлы китап, картиналар була. Казан галимнәре музей ачылуны шатланып каршы алалар һәм материаллар туплауда көчләрен кызганмыйлар.

100 ел эчендә музей берничә мәртәбә исемен алыштыра. 1895 елдан — Казан шәһәре фән һәм промышленность музее, 1919 елдан — губерна музее. 1921 елда аңа ТАССР Үзәк музее исеме бирелә. 1980 нче елларда республиканың музейлар челтәрен үзәкләштерү үткәрелә, һәм хәзер музей Татарстан Республикасының берләштерелгән Дәүләт музее статусын йөртә.

Безнең хәбәрчебез музейның методик-оештыру эшләре буенча генераль директор урынбасары Розалия Галиәкбәр кызы ГАРИФҖАНОВАГА берничә сорау белән мөрәҗәгать итте.

КАЗАН ХӘТЕР ЯҢАРТА

— Розалия ханым, укучыларны гаять кызыксындырган сорауларга җавап бирсәгез иде. Моннан җиде ел элек музей бинасында чыккан янгын казасы... Аның зыяны күпме булды, экспонатларның бүгенге хәле ничек һәм гаепләләр җәзасын алдымы?

— Гаепләләр бүген дә табылмаган, ә зыян әйтеп бетергесез зур булды. Җиде ел узгач та юбилеебызны музейда, якты залларда каршы ала алмадык. Ремонт һәм реставрация эшләре тагын кимендә 3-4 елга сузылыр әле. Ә экспонатларга килгәндә, аларның берсе дә әрәм булмады, чөнки безнең бинаның өске катында 26 оешма урнашкан иде, нигездә алар зыян күрде. Ике көн эчендә без бөтен материалларны эвакуацияләп, ышанычлы урыннарга урнаштырдык, алар барысы да исән-саулар, әйбәт саклананалар. Хәзер музей бинасында ремонт бара, аны үзгәртеп кору, элеккечә ике катлы итеп калдыру буенча эшлибез.

— Димәк, янгыннан соң музей, заман үзгәрешләрен тоеп, үзгәреп, яңарып, халыкка кайтачак. Анда халкыбызның үткәнен дөрес чагылдырган тарихи экспонатлар да булыр микән?

— Берләштерелгән Дәүләт музее бинасында 6 мөстәкыйль музей булачак. Музей комплексы «Кеше һәм табигать», «Археология», «Борынгы һәм урта гасырлар тарихы», «Казан ханлыгы 17 йөздә», «Этнография», «Безнең төбәк 18 - 19 йөзләрдә», «Татарстан XX йөздә» һ.б. бүлекләрдән торачак. Экспозицияләрнең дөреслеген «Иске музей», «Татарлар һәм дәүләтчелек. Идел Болгарстаннан алып бүгенгә кадәр» дигән күргәзмәләр дәлилли ала. Шулай ук татар китапларының 1100 еллык тарихын чагылдырган бүлек тә булачак. Аның концепциясен язучы Вакыйф Нуруллин төзеде.





— Розалия ханым, берләштерелгән Дәүләт музее республикадагы барча музейларны да үз канаты астына аламы?

— Безнең баш музей - корт иле кебек. Аның берсе — Татарстанның сынлы сәнгать музее күптән мөстәкыйль музей булып аерылып чыкты. Казанда гына да — 10, ә башка шәһәр һәм районнарда тагын 60 филиалыбыз бар. Дәүләт музее статусы алмаган музейларга да без һәрдаим методик ярдәм, киңәшләр, консультацияләр белән булышып торабыз. Филиалларның кайберләре юбилейлар уңаеннан (Казанда Г.Тукай, Өбрәдә С.Сәйдәшев музее һ.б.) ачылса, кайберләре җәмәгать башлангычында эшләүче мәктәп, авыл музейлары. Аларның дәүләт музее статусы алуы үзе бер куаныч, дәрәҗә түгелмени! Яңа Чишмәдә Зирекле, Балтачта Чепья, Әлмәт районында Елховой музейлары шундыйлардан. Җитәкчеләре Мидхәт Галимов, Гарифҗан Галиев, Хәлиулла Әхмәтшиннар алны-ялны белмичә, музейлары өчен җан атып йөрүче фидакарь кешеләр. Дәүләт музее — Татарстандагы барлык музейларның кыйбласы дип берничнди мактанусыз әйтергә була, чөнки ул Русиядә дә иң зур, абруйлы музейларның берсе санала.

Музейны торгызуда Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Попечительләр советы (рәисе — К.Исхаков) гаять зур ярдәм күрсәтәләр, аларга рәхмәтебезне җиткерсәгез иде.

**Әңгәмәне
Рәсимә СИБГАТУЛЛИНА
оештырды.**

● Музейның элекке рәвешенә китерелгән бинасы. Күргәзмә залларында.

ҖӘҺӘТ ӘҢГӘМӘ

Манас — безнең заман каһарманы да

Быелның август ахырларында Кыргызстан халкы һәм бөтен дөнья җәмәгатьчелеге атаклы «Манас» эпосының 1000 еллыгын билгеләп үтте. Бишкекта башланып киткән әлеге тантанада 33 төрки илдән килгән дәүләт җитәкчеләре, аерым алганда, Төркия Президенты Сөләйман Дәмирәл, Пакистанның Премьер-министры Беназир Бхутто, Әзәрбәйҗан, Төркмәнстан, Үзбәкстан һәм Казакъстан президентлары Гейдар Алиев, Сәфәрморад Ниязов, Ислам Кәримов, Нурсолтан Назарбаев, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ренат Харисов һәм галим Фоат Галимуллин катнашты. Шушы көннәрдә генә Фоат ГАЛИМУЛЛИН безнең хәбәрчебез Заһид МӘХМҮДИ белән әлеге бәйрәмнән алып кайткан тәэссоратлары белән уртаклашты.

— Фоат әфәнде, «Манас» эпосының 1000 еллыгына багышлап Кыргызстанда үткәрелгән олуг бәйрәм турында инде күп әйтелде, күп язылды. Шулай да Манас кем ул, шул турыда бераз сөйләсәгез иде?

— Манас ул — моннан мең ел элек Кыргыз дәүләтен булдыруга күп көч куйган атаклы хәрби җитәкче. Аның турында бик күп дастаннар, поэмалар, риваятьләр һәм легендалар саклана. Манас батырның хәзерге Кыргызстан тупрагындагы Талас үзәнендә барган сугышта һәлак булганлыгы билгеле. Борынгы риваятьләргә караганда, аны менә шушы үзән янындагы калкулыкка улы Симети күмдергән. Хәзер анда 1969-1970 нче елларда торгызылган гаҗәеп гүзәл архитектура һәйкәле — мавзолей тора. Әмма шуны искәртеп узарга кирәк. Күп кенә галимнәр Манас батырның улы тарафыннан җирләнүен шик астына куялар. Ник дигәндә, халыкта аны хатыны Канекәй җирләгән дигән риваять тә яшәп килә.

Бәйрәм менә шул мавзолей янында булды. Аны бер миллионга якын кеше тамаша кылды. Манас батыр һәлак булган сугышны күзаллау максаты белән театрлаштырылган тамашада 350 меңнән артык кеше һәм 3500 ат катнашты. Турысын гына әйткәндә, минем моңа кадәр андый искитмәле тамашаны күргәнем юк иде. Үземне вакыт машинасы белән шул чорга барып төшкәндәй хис иттем.

Манас батыр — кыргыз халкының горурлыгы. Һәм ул аның милли үзаңын, милли горурлыгын күтәрүдә гаять зур роль уйнады.

— Фоат әфәнде, ялгышмасам, «Манас» эпосын өйрәнүгә безнең галимнәр дә зур өлеш кертән бит...

— Әйе, әлеге эпосны өйрәнүдә, аны гыйлыландыруда татар галимнәре дә зур тырышлык күрсәткән. Алар — Хөсәен Фәезханов, Каюм Мифтахов, Мәдинә Богданова, Камил Рәхмәтуллин һ.б. Бу галимнәрнең хезмәтләре турында без Бишкекта булып узган фәнни симпозиумда сөйләдек. Анда шулай ук хәзерге галимнәрдән академик Миркасыйм Госмановның эшчәнлеге турында да сүз булды.

— Үз халкының бәйсезлеге өчен көрәшеп яу кырында башларын салган атаклы хәрби җитәкчеләр татар тарихында да бик күп. Әйтик, Идегәй, Чура, Сәет батырлар. Татарстанда да менә шундый батырлар истәлегенә, алар яшәгән чорны яктыртып, шундый зур тамашалар үткәрү максатка яраклы булыр иде, минемчә.

— Кызганычка, бездә мондый бәйрәмнәр үткәрү әлегә матур хыял гына булып кала. Алар безнең татар халкының милли үзаңын үстерүдә бер дигән чара була алыр иде. Мин ышанам, киләчәктә бездә дә шундый зур тамашалар үткәрелер әле. Үз тарихын онытмаган һәм аны ихтирам иткән халык кына бәйсез һәм мөстәкыйль дәүләт төзи ала. Без менә шуны истән чыгармасак иде.

Күктән... сыра яуса

Халык җырларының берсендә «Кабан күле спирт булып. күктән пилмән яуса иде». дигән юллар бар Әлегә күктән пилмән төшкәне булмады бугай. ә менә спирт яварга мөмкин.

Бөекбритания астрономнары галәмдә бинһая спирт парлары булуын ачыкладылар Немец журналы «П М Магацин» хәбәр итүенә караганда. бер секстиллион литр сыйдырышлы әлеге болыт үзенен үлчәме буенча кояш системасыннан да зуррак Галәти булмаган мондый «яратылыш» Бөркет. Аккош һәм Лира йолдызлыклары арасында икән

Галәмдәге «хәмер фабрикасы» астрономик житештерүчәнлеге белән аерылып тора ул бер триллион ел дәвамында җирдәге һәрбер адәм баласын көн саен бер триллион чәркә сыра белән тәэмин итә алыр иде

Үлеп сыра яратучылар яисә юктан да акча ясарга хирыс эшкуарлар табигать могҗизасының нәтиҗәсен хәзер үк татып карарга ашыкмасын әлеге «исергән» болыт безнен планетадан 10 мен яктылык елы ераклыгында урнашкан Димәк. бу очракта «Көтегез. диясе генә кала. -- чәркәләге сыраның күбеге бераз гына шиңә төшсен »

А й-һай!..

Мин исән бит әле...

И адәм гибраты. — дияр иде шагыйрь дустым Рәшит Әхмәтҗанов. бу хәбәрне укыса Күзен күргәнгә. колагын ишеткәнгә дә ышануы авыр хәзерге әкәмәт заманда «Заман» газетасының яңа санын (5 сентябрьдә чыккан) укып утырам шулай Үз күзләремә үзем ышанмыйм Хәбәрче Әхәт Йосыпов Казан урамнарының берсенә минем исемне бирергә тәкъдим итә Бәндәгезне Гаяз Исхакый. Бакый Урманче. Рөстәм Яхин кебек даһилар белән бер рәттән саный Җырда җырланганча. «башларым китте әйләнеп .» Үземне җиде кат күктә хис итә башладым. « истәлекләрен кадер белән искә алырдай» дигән җиргә житкәч кепә әйнып киттем Бәй. мин якты дөньядан киткән. ягъни үлгән булып чыгам түгелме соң?! Юкса. газета мөхәррире Муаммар Мурат белән күптән түгел генә очрашкан идек шикелле. редакция хезмәткәрләре белән дә көн саен диярлек күрешеп торабыз.

Казан урамнарын үз исемнәре белән бизәрдәй мәрхүм зыялыларыбыз миннән башка да житәрлек аныса Арабыздан вакытсыз киткән милләтпәрвәр шагыйребез Рәшит Әхмәтҗанов та лаек мондый мәртәбәгә Тик аны Татарстан бәйсезлегенә каршы көрәшүче «демократ» Рәшит Әхмәтов белән генә бутамасыннар иде — дөнья болай да буталчык.

Озын сүзнең кыскасы. мин исән. теге дөньяга китәргә дә бик җыенмыйм әле. Шуна күрә үземә Ходай тәгаләдән озын гомер гозерләп. Татарстан Президентына һәм Казан мэрына мөрәҗәгать итәсем килә Марк Твен әйтмешли. минем үлемем турында хәбәр кирәгеннән артык күпертелгән. Зинһар өчен. Казанның берәр урамына минем исемне бирми торыгыз. Минем әле яшисем килә. Мин үлгәч. үзегез карарсыз тагын

Яп-якты дөньяда яшәүче
теп-тере шагыйрь Әхмәт РӘШИТ.



● Гомбәче.

Кыз йолдызлыгы астында туганнар

КОТЛЫЙБЫЗ!

16 сентябрь

АТИЛЛА РАСИХ (РӘСҮЛЕВ Атилла Кадыйр улы) -- язучы.

17 сентябрь

АБДУЛОВ Усман Нәҗметдин улы — рәссам. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

СЕВАСТЬЯНОВ Валерий Иванович — «Татарстан» радио-телевидение компаниясе кинооператоры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

ӘДЬӘМОВА Саҗидә Сабир кызы — Казанның элекке 18 нче урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы. хезмәт ветераны.

18 сентябрь

АХУНОВ Гарифҗан Ахунҗан улы — Татарстанның халык язучысы.

ГОБӘЙДУЛЛИН Әнвәр Габдрахман улы — Г Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты. Татарстанның халык артисты.

19 сентябрь

ХӘЙРЕТДИНОВА Луиза Әхмәтҗан кызы — композитор.

ГВОЗДЬ Юрий Константинович — «Татарстан» радио-телевидение компаниясе кинооператоры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

20 сентябрь

ВӘЛИЕВ Камил Шакир улы — Әлмәт Татар дәүләт драма театры артисты, Татарстанның һәм РФнең атказанган артисты.

Бу санда Әсрар Шакирҗанов, Шамил Абдюшев, Әкрәм Шәфигуллин төшергән һәм авторларның шәхси архивыннан алынган фотолар файдаланылды.

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы Казан шәһәренең Киров районы эчке эшләр идарәсенең участок инспекторы 28 яшьлек

ХӘБИБУЛЛИН Рөстәм Гашигулла улының

хезмәт бурычын үтәгәндә җинаятьчеләр кулыннан һәлак булуы сәбәпле, туганнарының һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклаша.

Биючеләр игътибарына!

«Казан» милли мәдәният үзәге яңа оештырылачак профессиональ бию ансамбленә конкурс игълан итә. Ансамбльгә бию сәнгате белән шөгыльләнгән, бу өлкәдә тәҗрибә туплаган, буе 170 сантиметрдан ким булмаган егетләр һәм кызлар. шулай ук оркестр өчен музыкантлар кабул ителә. Эш тәртибе килешү буенча. Милли мәдәниятебезгә битараф булмаган яшьләр, рәхим итегез!

Белешмә өчен адрес һәм телефоннар:
420060, Казан, Солтангалиев мәйданы, 1 нче йорт,
«Казан» милли мәдәният үзәге, 143 нче бүлмә,
тел.: 36-78-11, 38-33-51.

Котылгысыз үлем безнең тагын бер фидакяребезне, кешелекле. олы җанлы галимә. ансамблебезнең якын дусты —

Мария Яковлевна ЖАРНИЦКАЯны алып **китте.**

Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле аның ире — **академик** Мөхәммәдъяров Шамил Фатыйх улының, **якыннарының**, туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.

ТОО «Язу» ликвидируется.
Претензии принимаются по тел.: 49-36-24.

Мәдәни ҖОМГА

Татарстан Республикас[ы]
Мәгълүмат
һәм матбугат,
Мәдәният
министрлыклары
химаясендә чыгарыл[а]

Баш мөхәррир
Зиннур
МАНСУРОВ

Баш мөхәррир урынбасарла[ры]
Газинур МОРАТ,
Миншәех ЗӘБИРОВ

Җаваплы сәркатип
Альберт САБИРОВ

Телефоннар:
32-41-79 — кабул итү бүлмәсе;
32-45-78, 32-06-76 — баш мөхәр[рир] урынбасарла[ры];
32-57-36 — җаваплы сәркатип;
32-57-76 — җаваплы сәркатип урынбасарл[ы];
32-62-79 — публицистика, очерк, сәясәт бүле[ге];
32-58-91, 32-68-22 — әдәби[ят] бү[леге];
32-60-11 — сәнгать бүлеге;
32-12-08 — тәнкыйть, фән[,] тарих бү[леге];
32-62-79 — мәдәният яңал[ыкла]ры, мәгъл[үмат,] тәрҗемә бү[леге];
32-59-55 — халык тормыш[ы,] рухияте [бүлеге];
32-69-54 — хатлар бүлеге;
32-66-28, 32-59-22 — рәсса[мнар];
32-69-26 — фотохәбәрче;
32-57-94 — бухгалтерия.

Авторлар фикере ред[акция] фикере белән муафыйк[ ]маска да мөмкин

Хатлар, кульъязмалар, [фото]графияләр, рәсемнәргә б[аш]мә бирелми һәм алар кайтарылмый

Газетада басылган язм[алар]ны, фотографияләрне ф[айда]ланганда, шулай ук өзем[тә] китергәндә, «М[әдәни] җомга»дан алынганлыг[ы күрсәтү] мәҗбүри

Реклама урнаштыру өч[ен] казлар кабул ителә

Реклама һәм белдерү[ләр] төгәллеге өчен реклама[бирү]челәр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдә[ме] рсәтергә теләүчеләр өч[ен ре]дакциянең исеп-хисап с[четы]
609403 МФО 2655
в Бауманском отд. [...]

Газета
Татарстан Республик[асы]
Мәгълүмат һәм матб[угат]
министрлыгында
428 нче таныклык б[елән]
теркәлде

Индекс — 54[...]

Редакция адрес[ы:]
420503, Казан,
Бауман урамы, 1[...]

Нәшрият адрес[ы:]
420066, Казан,
Декабристлар урам[ы ...]

Басмахана гаебе бе[лән] бәрелгән сыйфат җите[шсез]кләре уңаеннан 49-36-6[...] рлы телефон буенча ш[ы]тырга

Газета редакциянең к[омпью]тер үзәгендә эшләнде

Газетаның сатудагы бәясе килешү буенча

Татарстан газета[һәм]
журналлар нәшрия[ты]
басмаханәсе

Тираж 8000
Заказ 4457